# ШУРА

№ 30
2020



المولد النبوي الشريف

Татарстан Республикасы мөселманнарының диния нәзарәте

ДИНИ АЛЬМАНАХ

1908 елдан бирле нәшер ителә

ЭЧТӘЛЕК

Редакциядән хат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Җомга хотбәсе. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6

ВӘГАЗЬЛӘР. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Җирдәгеләргә мәрхәмәтле булу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Сынау ни сәбәпле килә? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Пәйгамбәребез – олуг үрнәк иясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Мөселманнар үрнәк булырга тиеш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Диннең кыйммәте хакында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Аллаһы Тәгаләгә шөкер итү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
Бала – җәннәт чәчәге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 42
Вакытыбызны исраф кылмыйк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
Гаиләне саклау хакында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 49
Ватанны сөю – иманнан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
Хөсетлек чире . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
«Аллаһы яхшырак белә» сүзен еш әйтәбезме? . . . . . . . . . . . . . 61
Яшерен гыйлем. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65

ФӘТВАЛАР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
Изге гамәлләр иманга керәме? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
Тәрбиягә алынган балага мирас бүлү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
Истинҗа . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
Госел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76

ҮРНӘК ЗАТЛАР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһе . . . . . . . . . . . . . . . . . . 79

«НӘРСӘ? КАЙДА? КАЙЧАН?» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84

ТАРИХ. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 89
Эстония мөселманнары: татарларның төньяк Балтыйк буе илләренә Ислам динен алып килүләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90

Эстония мөселманнары: татар сәүдәгәрләрен кемнәр дип уйлаганнар? . . . 93

МИРАС . . . 96
Иске Таш мәчет . . . 97

ТӘФСИР . . . 101
Муса галәйһиссәлам кыйссасы . . . 102
Коръән сүрәләре . . . 120

ФӘН . . . 123
Тәэмин итү . . . 124
Туганнарны тәэмин итү . . . 128

МӘҮЛИД . . . 131
Пәйгамбәрләрнең хуҗасы Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең туу кыйссасы . . . 132
Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәселе Казанда яшәгәне дөресме? . . . 141

НӘСЫЙХӘТ . . . 145
Олы гөнаһлар . . . 146

ӘДӘБИ СӘХИФӘ . . . 151
Олуг үкенеч . . . 152
Ә син ышанасыңмы? . . . 156
Кем бәхетле? . . . 159

**«ШУРА» дини альманах, №30**

*октябрь– декабрь 2020*
*сафәр –җөмәдәл-әүвәл 1442*

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ №ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы
мөселманнары Диния нәзарәте
420021 Казан, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бәясе ирекле
2013 елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга
**12+**

**БАШ РЕДАКТОР:**
Камил Искәндәр улы Сәмигуллин
Телефон: +7 (843) 237-94-53 (кабул итү бүлмәсе)

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Булат Мөбарәков
Илдус Фәиз

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**ДИЗАЙНЕРЛАР:**
Рөстәм Даутов
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Раушан Сәйфетдияров

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
Илшат Хәйретдинов

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: shura@huzur.ru
Сайт: www. huzur.ru

*Типографиянең адресы:*
*«ОТ Принт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420030, Казан шәһ., Жуковка ур., 2.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 07.10.2020
Чыгу көне: 21.10.2020

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание на татарском языке

# Редакциядән хат

## Кадерле укучылар!

«Шура» журналының әлеге 30нчы санынннан башлап вәгазьләрнең бирелү рәвеше үзгәрә.

Алар элеккегечә әзер вәгазь булып түгел, ә сөйләүчегә ярдәмлек буларак тәкъдим ителә. Биредә вәгазьнең темасы, аның эчтәлегенә караган һәм кулланып булган аятьләр, хәдисләр биреләчәк. Темасын тулысынча камил рәвештә баетып, мөселман кардәшләребезгә тәкъдим итү – вәгазь сөйләүченең үз ихтыярында кала.

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي هَدَانَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللَّهِ۞ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللهُ۞ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ۞ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللهِ۞ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ۞ دَاعِينَا إِلَى اللهِ۞ صَلَّى اللهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ۞ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ۞ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ۞ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ۞ رِضْوَانُ اللهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللهِ!۞ اِتَّقُوا اللهَ وَ أَطِيعُوهُ۞ إِنَّ اللهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ۞

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللَّهِ:

________________________________۞

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

۞ ______________________________

Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:

أَلَا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ۞ كَلَامُ اللهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللهُ تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ۞

أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللهِ الْإِسْلَامُ۞

Соңыннан кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ۞ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:

اَلْحَمْدُ لِلّٰه حَمْدَ الْكَامِلِينَ وَالصَّلَوةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِينَ وَ الْآخِرِينَ۞ مُحَمَّدٍ وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ۞ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ۞ فَقَالَ عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:

إِنَّ اللهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً۞

اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞ اَللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا بَارَكْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞

اَللَّهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ۞ سَيِّدِنَا أَبِى بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُمْ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ[1] ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاةِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وهَوَائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:

إِنَّ اللهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَائِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әмин» дип әйтә.

وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ۞ وَلَذِكْرُ اللهِ أَكْبَرُ وَاللهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ۞

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһил-ләҙии һәдәәнә лиһәәҙәә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләә ән һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләҙии каалә фии китәәбиһил- кәриими әстәгыйҙү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләә ән йәшәә-әллаһ». Нәшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһу. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин гаҙәбилләһи. Вә нәшһәдү әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыыйнәә иләл-лаһи. Салләллаһу тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдиййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мүʼминиинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъде: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә әтыыйгууһу. Иннәллаһә мәгал-ләҙиинәт-тәкау, вәл-ләҙиинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыйҙү билләһи: ______________________________________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ____________________

______________________________________________________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгеләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмүллаһил мәликил газиизил галләәми, кәмәә каалә́ллаһу тәбәәракә вә тәгаалә филкәләәми. Вә иҙәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әңсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйҙү билләһи: «Иннәд-диинә гыйңдәллаһил Исләәм».

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак, киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхаамәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәлләҙиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибраһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ҙәвил кадрил җәлиййи вәш-шәрафил галиййи сәййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гусҫмәәнә вә Галиййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәййидинәл Хәсәни вә сәййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мүʼмиништинә вәл мүʼминәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин[1]. Вәхҙүл мән хәҙәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфириинә вәл мүкыыймиинә вәл хәәдыйриинә вәл гаа-ибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгууҙү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

«Иннәллаһә йәʼмүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ҙил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәҙәккәрүүн. Вәләҙикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгүүн».

---

1 Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

# Вәгазьләр

*9 октябрь вәгазе,*

*Сафәр аеның 22 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Җирдәгеләргә мәрхәмәтле булу

Барча галәмнәрне барлыкка китереп, аларны тәрбия кылучы, безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин-мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп кылучы, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итүче Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң яхшы хәләл җефет, иң яхшы әти, иң яхшы дус, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде! Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, нык сәламәтлек насыйп итсә иде!

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

1. Вәгазьнең эчтәлегенә караган аятьләр. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

ثُمَّ كَانَ مِنَ الَّذِينَ آمَنُوا وَتَوَاصَوْا بِالصَّبْرِ وَتَوَاصَوْا بِالْمَرْحَمَةِ ﴿١٧﴾
أُولَٰئِكَ أَصْحَابُ الْمَيْمَنَةِ ﴿١٨﴾

**1) «Шуннан соң иман китергән, бер-берләрен сабырлыкка һәм [Аллаһының колларына карата] мәрхәмәтле булырга**

**өндәүчеләрдән булырга кирәк. Болар [дәфтәрләрен уң кулларына алачак] уң як кешеләре»;**

«Әл-Бәләд / Шәһәр», 90:17-18

إِنَّ رَحْمَتَ اللَّهِ قَرِيبٌ مِّنَ الْمُحْسِنِينَ ﴿٥٦﴾

**2) «Һичшиксез, Аллаһының рәхмәте [догаларын һәм бүтән гамәлләрен яхшы кылган] игелекле кешеләргә [бик] якын»;**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:56

وَابْتَغِ فِيمَا آتَاكَ اللَّهُ الدَّارَ الْآخِرَةَ ۖ وَلَا تَنسَ نَصِيبَكَ مِنَ الدُّنْيَا ۖ وَأَحْسِن كَمَا أَحْسَنَ اللَّهُ إِلَيْكَ ۖ وَلَا تَبْغِ الْفَسَادَ فِي الْأَرْضِ ۖ إِنَّ اللَّهَ لَا يُحِبُّ الْمُفْسِدِينَ ﴿٧٧﴾

**3) «Аллаһы сиңа биргән [хәзинәләр һәм киң мөмкинлекләр тулы] нәрсәләрдә соңгы йортны [аның савапларын] эзлә. Дөньяңнан да насыйбыңны онытма! Аллаһы сиңа [моның кадәр нигъмәтләр биреп] игелек кылганы кебек, син дә [Аллаһының колларына] игелек кыл. Җирдә бозыклык [һәм золым чыгару юлларын] эзләмә. Һичшиксез, Аллаһы бозыклык чыгаручыларны сөйми».**

«Әл-Касас / Кыйсса», 28:77

2. Вәгазьнең эчтәлегенә караган хәдисләр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән:

1) «Аллаһы белән ант итәм, һичшиксез, Аллаһының рәхмәте мәрхәмәтлеләргә, шәфкатьлеләргә генә ирешә»;

2) «Кем гафу итә белми, аңа карата да гафу итү юк»;

3) «Җирдәгеләргә мәрхәмәтле булыгыз, сезгә күктәгеләр (фәрештәләр) мәрхәмәтле булырлар».

* * *

Китапларда мәрхәмәт сүзенең мәгънәсе «Рахим» сүзенә охшаш мәгънәләрдә очрый. Мәрхәмәт – шәфкать, киң күңеллелек, рәхимлек, миһербанлык. Мәрхәмәт итү (кылу, күрсәтү) – кемгәдер ярдәм кулы сузу, киң күңеллелек күрсәтү, рәхимле булу. Ягъни мәрхәмәтле булу – рәхимле булу. Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы Тәгалә – «Әр-Рахим» һәм «Әл-Гафур» – «Рәхимле» һәм «Гафу итүче», Ул гафу итүгә ия, шулай ук безгә гафу итегез, дип әмер итә, дөньяда гафу итә белсәк, Ахирәттә без гафу ителербез, Аллаһы боерса. Адәм баласының, гафу итүдән «баш тартырга» хакы юк, тәкәбберлекне калдырып, Раббыбызның әмеренә буйсынсак иде.

Фәкыйрь белән мескеннең хакын чыгарсак, садака, зәкятне биреп, аларга ярдәм итсәк, Аллаһының безгә биргән рәхмәтен тараткан булырбыз, шулай ук малыбызны чистартканнан соң, рызыгыбызны арттырырга сәбәп кылган булырбыз. Аллаһының әмерләрен җиренә җиткереп үти алсак, безгә Аның рәхмәте дә ирешер. Аллаһы Тәгалә барча кылган хәерле догаларыбызны кабул кылсын. Әмин!

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Габбас хәзрәт Кадыйров,*

*МДНнең Дәгъват бүлеге җитәкчесе*

*16 октябрь вәгазе,*

*Сафәр аеның 29 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Сынау ни сәбәпле килә?

Барча галәмнәрне барлыкка китереп, аларны тәрбия кылучы, безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин-мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп кылучы, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итүче Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң яхшы хәләл җефет, иң яхшы әти, иң яхшы дус, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде! Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, нык сәламәтлек насыйп итсә иде!

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

1. Вәгазьнең эчтәлегенә караган аятьләр. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

فَإِنَّ مَعَ الْعُسْرِ يُسْرًا ﴿٥﴾ إِنَّ مَعَ الْعُسْرِ يُسْرًا ﴿٦﴾

**1) «Һичшиксез, [чиккән һәр] авырлыктан соң җиңеллек бар. Һичшиксез, авырлыктан соң җиңеллек бар»;**

«Инширах / Ачмак», 94:5-6

إِنَّ الَّذِينَ تَوَفَّاهُمُ الْمَلَائِكَةُ ظَالِمِي أَنفُسِهِمْ قَالُوا فِيمَ كُنتُمْ ۖ قَالُوا كُنَّا
مُسْتَضْعَفِينَ فِي الْأَرْضِ ۚ قَالُوا أَلَمْ تَكُنْ أَرْضُ اللَّهِ وَاسِعَةً فَتُهَاجِرُوا فِيهَا ۚ
فَأُولَٰئِكَ مَأْوَاهُمْ جَهَنَّمُ ۖ وَسَاءَتْ مَصِيرًا ﴿٩٧﴾

**2) «[Имансызларга ияреп, һиҗрәттән баш тарткан] Кешеләрнең җаннарын фәрештәләр үз-үзләренә золым итүчеләр хәлендә алыр һәм: «Сез [динегез белән бәйле гамәлләрне үтәү мәсьәләсендә] нинди хәлдә идегез?» – диярләр. Алар: «Без туфракта гаҗиз булдык [шуңа күрә динебезне ачыктан-ачык белдерергә һәм Мәккәдән һиҗрәт кылырга мөмкинлек таба алмадык]», – диярләр. [Фәрештәләр аларның ялганнарын күрсәтер өчен:] «[Исламча яшәргә мөмкинлек булмаган җирне калдырып, динегезне тыныч тота алырлык якка] Һиҗрәт кылса идегез, Аллаһының җире киң түгел идемени?» – диярләр. Аларның сыеначак урыннары – җәһәннәм. Барачак урын булачак ул никадәр дә яман!»;**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:97

ظَهَرَ الْفَسَادُ فِي الْبَرِّ وَالْبَحْرِ بِمَا كَسَبَتْ أَيْدِي النَّاسِ لِيُذِيقَهُم بَعْضَ
الَّذِي عَمِلُوا لَعَلَّهُمْ يَرْجِعُونَ

**3) «Кылган [начар] нәрсәләрнең [бөтенесенең җәзасын Ахирәттә биргәнче] бер өлешен [дөньяда ук] аларга татытыр өчен, кешеләрнең куллары казанган [начар] нәрсәләр сәбәпле корыда һәм диңгездә бозыклык барлыкка килде. Бәлки, алар [гөнаһлардан] кайтырлар»;**

«Әр-Рум / Румлылар», 30:41

تَبَارَكَ الَّذِي بِيَدِهِ الْمُلْكُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ ﴿١﴾ الَّذِي خَلَقَ الْمَوْتَ وَالْحَيَاةَ لِيَبْلُوَكُمْ أَيُّكُمْ أَحْسَنُ عَمَلًا وَهُوَ الْعَزِيزُ الْغَفُورُ ﴿٢﴾

**4) «Хөкемдарлык [кодрәт] фәрманында булган [Аллаһы] бөек, һәм Ул [һәрнәрсәгә көче җиткән] кодрәтле. Ул, сезнең кайсыгыз гамәлләренә күрә күркәмрәк булуын сынар өчен, үлемне һәм тереклекне яратты [сезнең кылачакларыгыз хакында әзәли гыйлемен уртага чыгарачак, соңыннан Үзенең гыйлеменә күрә түгел, кылганнарыгызга күрә әҗерләрегезне бирәчәк]. Ул – Бөек [Җиңелмәс], [гөнаһларны күпләп] Гафу итүче»;**

«Әл-Мүльк / Хөкемдарлык», 67:1-2

وَلَنَبْلُوَنَّكُمْ بِشَيْءٍ مِّنَ الْخَوفْ وَالْجُوعِ وَنَقْصٍ مِّنَ الأَمَوَالِ وَالأنفُسِ وَالثَّمَرَاتِ وَبَشِّرِ الصَّابِرِينَ ﴿١٥٥﴾

**5) «Без, һичшиксез, сезне бераз – курку белән, бераз – ачлык белән һәм малларыгызга, җаннарыгызга, [бакча-басуларыгызга афәтләр җибәреп] уңышларыгызга бераз зыян китерү белән сыныйбыз. [Расүлем!] [Сынауларга] Сабыр итүчеләрне [җәннәт белән] сөендер».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:155

2. Вәгазьнең эчтәлегенә караган хәдисләр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән:

1) «Мөселман кешесенә нәрсә генә килсә дә: арыганлык, борчылу, күңелсезлек, кайгы-хәсрәт, хәтта берәр үсемлекнең чәнечкесе кадалса да, Аллаһы Тәгалә аңа моның өчен берәр гөнаһын ярлыкаячак»;

2) «Кеше берәр төрле гөнаһ кылып: «Йә, Раббым, мин гөнаһлы гамәл башкардым. Мине ярлыка», – дип әйтер, Аллаһы Тәгалә аңа: «Минем колым аның гөнаһларын Белүче һәм ул гөнаһларны юкка чыгаручы Раббысы бар икәнлеген белә. Дөреслектә, Мин аның бу гөнаһын ярлыкадым», – дип җавап кайтарыр. Шуннан соң бу кеше кабаттан берәр төрле гөнаһ кылып: «Йә, Раббым, мин кабаттан гөнаһлы гамәл башкардым. Мине ярлыка», – дип әйтер, Аллаһы Тәгалә аңа: «Минем колым аның гөнаһларын Белүче һәм ул гөнаһларны юкка чыгаручы Раббысы бар икәнлеген белә. Дөреслектә, Мин аның бу гөнаһын ярлыкадым. Үзе теләгәнен башкарсын, – дип җавап кайтарыр. Шуннан соң Пәйгамбәребез бу сүзләрне өченче һәм дүртенче мәртәбә дә кабатлады»;

3) «Биш вакыт намаз, һәр җомга намазы, һәр Рамазан аенда ураза тоту шул гамәлләр арасында кылынган кечкенә гөнаһларга (зур гөнаһлардан кала) ярлыкау булып торалар»;

4) «Бервакыт Пәйгамбәребез авыр хәлле бер кеше янына килеп, аның хәле бөтенләй начар булганын күргәч: «Син догалар кылмыйсың мәллә, син Раббыңа ялвармыйсың мәллә?» – дип сорады. Теге кеше: «Әйе, кылам. Мин: «Раббым, Ахирәттә мине газаплый торган булсаң, җәзамны бу дөньяда ук бир», – дип сорыйм», – дип җавап кайтарган. Пәйгамбәребез: «Аллаһы барча кимчелекләрдән пакьтер. Дөреслектә, син моңа чыдый алмаячаксың! Нигә әле дога кылганда: «Йә, Аллаһым, бу дөньяда да, Ахирәттә дә безгә яхшы нәрсәләр бир, безне Ут газапларыннан сакла!» – дип әйтмәскә? Шуннан соң ул кеше Аллаһыга ялварып, шулай дип мөрәҗәгать итте, һәм Ул аны савыктырды»;

5) Өмме Сәләмә радыяллаһу ганһә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Әгәр дә берәр кешегә кайгы-хәсрәт килсә: «Дөреслектә, без Аллаһы Тәгаләнеке һәм Аңа гына кире кайтабыз. Ий, Аллаһым, шушы кайгым сәбәпле миңа савап ирештер һәм миңа яхшырагын әйлә», – дип дога кылса, Аллаһы Тәгалә шушы кайгысы сәбәпле аңа

әҗер-саваплар бирәчәк һәм бу кайгыга алмаш итеп нинди дә булса яхшылык җибәрәчәк», – дип әйткән сүзләрен риваять кылган.

* * *

Кеше тормышы шатлыклы һәм кайгылы вакыйгаларның алмашы белән үзенчәлекле. Галимнәр авырлыкларны берничә төрле сәбәп аркасында килә дип әйтәләр:

1. Гөнаһларга җәза итеп.
2. Сынау рәвешендә.
3. Гомер дәверендә кылган көнаһлардан пакьләнү өчен һ.б.

Авырлыкларны җиңеләйтү юллары:

1. Ярлыкау сорау.
2. Изге гамәлләр кылу.
3. Аллаһы Тәгаләгә дога кылып ялвару.

Тормыш сынаулары өметсезлек өчен сәбәп түгел, киресенчә, алар бездә сабырлык һәм максатчанлыкны үстерә. Тәүбә кылганда йөрәкләребезне сафландыра. Без шул вакытта Аллаһы Тәгаләнең янәшәдә булуын, һәм безгә бары тик игелек кенә теләгәнен тагы да катырак аңлый алабыз. Аллаһы Тәгалә шушы тормыш авырлыклары аша безгә Үзенә тагы да якынаерга насыйп әйләсә иде. Әәмин!

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып

яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Марсель хәзрәт Мингалиев,*

*МДНнең Дәгъват бүлеге белгече*

*23 октябрь вәгазе,*

*Рабигыль-әүвәл аеның 6 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Пәйгамбәребез – олуг үрнәк иясе

Барча галәмнәрне барлыкка китереп, аларны тәрбия кылучы, безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин-мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп кылучы, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итүче Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң яхшы хәләл җефет, иң яхшы әти, иң яхшы дус, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде! Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, нык сәламәтлек насыйп итсә иде!

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

1. Вәгазьнең эчтәлегенә караган аятьләр. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ ﴿٥٦﴾

**1) «Мин җеннәрне һәм кешеләрне Миңа гыйбадәт кылсыннар дип яраттым»;**

«Әз-Зарият / Таратучылар», 51:56

وَمَن يُطِعِ اللَّهَ وَالرَّسُولَ فَأُولَٰئِكَ مَعَ الَّذِينَ أَنْعَمَ اللَّهُ عَلَيْهِم مِّنَ النَّبِيِّينَ وَالصِّدِّيقِينَ وَالشُّهَدَاءِ وَالصَّالِحِينَ ۚ وَحَسُنَ أُولَٰئِكَ رَفِيقًا ﴿٦٩﴾ ذَٰلِكَ الْفَضْلُ مِنَ اللَّهِ ۚ وَكَفَىٰ بِاللَّهِ عَلِيمًا ﴿٧٠﴾

2) **«Кем дә кем Аллаһыга һәм Расүл салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә итагать итсә, әнә шулар – Аллаһы нигъмәтләндергән пәйгамбәрләр, тугрылар, шәһитләр һәм [игелек кылган] изгеләр белән бергә. Иптәш буларак алар нинди яхшы! [Итагатьлеләргә вәгъдә ителгән] Бу [әҗер кебек бер] фазыл – Аллаһыдан. [Кемнең никадәр фазыйләткә лаек булганын] Белүче буларак Аллаһы җитә»;**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:69-70

مَّنِ اهْتَدَىٰ فَإِنَّمَا يَهْتَدِي لِنَفْسِهِ ۖ وَمَن ضَلَّ فَإِنَّمَا يَضِلُّ عَلَيْهَا ۚ وَلَا تَزِرُ وَازِرَةٌ وِزْرَ أُخْرَىٰ ۗ وَمَا كُنَّا مُعَذِّبِينَ حَتَّىٰ نَبْعَثَ رَسُولًا ﴿١٥﴾

3) **«Кем дә кем туры юлдан китсә, ул үз файдасына гына һидаятькә ирешер. Кем дә кем адашса, ул үз зарарына адашыр. Бер генә [гөнаһ] йөртүче дә бүтән берәүнең йөген күтәрмәячәк. Без, бер расүл җибәрми торып, газап бирмәдек»;**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:15

وَإِنَّكَ لَعَلَىٰ خُلُقٍ عَظِيمٍ ﴿٤﴾

4) **«Һәм син, һичшиксез, югары әхлак иясе»;**

«Әл-Каләм», 68:4

وَمَا أَرْسَلْنَاكَ إِلَّا رَحْمَةً لِّلْعَالَمِينَ ﴿١٠٧﴾ قُلْ إِنَّمَا يُوحَىٰ إِلَيَّ

أَنَّمَا إِلَـٰهُكُمْ إِلَـٰهٌ وَاحِدٌ ۖ فَهَلْ أَنتُم مُّسْلِمُونَ ﴿١٠٨﴾

**5) «[Расүлем!] Без сине [җеннәр, фәрештәләр, кяфер һәм мөселман барча кешеләрне кертеп] бөтен галәмнәр өчен бер рәхмәт итеп җибәрдек. [Расүлем!] Әйт: «Миңа илаһыгызның бер генә булганы [шуңа күрә Аның гына хөкемнәренә иярелергә тиешлеге] вәхи ителде. Инде сез [бу вәхигә ияреп] мөселманнар түгелсезме?»**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:107-108

2. Вәгазьнең эчтәлегенә караган хәдис:

1) Сәхабәләр Гайшә радыяллаһу ганһәдән Расүлебезнең әхлагы турында сорагач, ул: «Аның әхлагы Коръәни Кәрим иде», – дип әйткән.

* * *

Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне безнең арадан сайлап куйды. Әмма без, мөселманнар буларак, аның турында ниләр беләбез соң? Расүлебез хакында язылган китаплар күп булса да, кайсыларын укыганыбыз бар?

Революциягә хәтле татар галимнәре тарафыннан язылган китаплар күп. Мәсәлән, Сөнгатулла Бикбулатның «Хәзрәти Мөхәммәд», Каюм Насыйриның «Мәҗмәгыль әхбар», Ризаэтдин Фәхретдиннең «Мөхәммәд» китаплары. Шулай ук гарәп шәехләре Ибне Хишәм, Рамадан Әл-Бутый һ.б. галимнәрнең хезмәтләре билгеле.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең дөньяга килүе үзе зур вакыйга һәм мөселманнар өчен Аллаһының рәхмәте. Расүлебезнең тууы һиҗри хисап буенча 11 нче рабигыльәүвәл, ә милади буенча 571 елга туры килә. Ул үзенең туган көнен билгеләп үткәнме соң? Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең

хәдисеннән билгеле булганча, ул: «Бу көндә мин туганмын, шуңа күрә бу көндә ураза тотам», – дип әйтә торган булган. Без дә бу «МәүлидӘн-Нәби» көнен билгеләп үтәбез. Быел рабигыль-әүвәл аеның 11 нче көне 28 октябрьгә туры килә. Пәйгамбәребез – олуг үрнәк иясе, шуңа да ул кылган гамәлләрне күз уңында тотып, тормышта көн саен кылына торган гамәлләребез рәтенә кертә алсак, бик бәхетле булыр идек. Аллаһы Тәгалә безне Үзенең һәм Пәйгамбәренең мәхәббәтенә лаек кылып, дөньяда кылган гыйбадәтләребезне кабул итеп, җәннәттә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән бергә булырга насыйп итсә иде.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Габбас хәзрәт Кадыйров,*

*МДНнең Дәгъват бүлеге җитәкчесе*

*30 октябрь вәгазе,*

*Рабигыль-әүвәл аеның13 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Мөселманнар үрнәк булырга тиеш

Барча галәмнәрне барлыкка китереп, аларны тәрбия кылучы, безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин-мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп кылучы, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итүче Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң яхшы хәләл җефет, иң яхшы әти, иң яхшы дус, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде! Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, нык сәламәтлек насыйп итсә иде!

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

1. Вәгазьнең эчтәлегенә караган аятьләр. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ إِنَّا خَلَقْنَاكُم مِّن ذَكَرٍ وَأُنثَىٰ وَجَعَلْنَاكُمْ شُعُوبًا وَقَبَائِلَ لِتَعَارَفُوا ۚ إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِندَ اللَّهِ أَتْقَاكُمْ ۚ إِنَّ اللَّهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ ﴿١٣﴾

**1) «Ий кешеләр! Һичшиксез, Без сезне [Адәм исемле] бер ирдән һәм [Хавва исемле] бер хатыннан яраттык. [Һәммәгезнең дә ата-анасы бер булганга күрә, нәсел-чыгыш белән мактануның**

**ни мәгънәсе бар?] Без сезне [бер-берегезгә уйламый-нитми теләсә ни сөйләр өчен түгел] танышуыгыз өчен кавемнәр һәм кабиләләр иттек. Аллаһы хозурында иң кадерлегез – [иң асыл нәселдән булганнарыгыз түгел, Аллаһы Тәгаләнең харамнарыннанан сакланган] бик тә тәкъвалык иясе булганыгыз. Һичшиксез, Аллаһы – [һәрнәрсәне] Белүче, [һәрнәрсәдән] Хәбәрдар».**

«Әл-Хүҗүрат / Бүлмәләр», 49:13

2. Вәгазьнең эчтәлегенә караган хәдисләр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән:

1) «Гәрәпнең гәрәп булмаганнан, гәрәп булмаганның гарәптән, кара тәнленең ак тәнледән, ак тәнленең кара тәнледән өстенлеге юк. Әмма Аллаһыга иң якын булучылар – ул тәкъва булучылар»;

2) Бервакыт бер сәхабә Расүлебезнең азан әйтүчесе Билял радыяллаһу ганһегә: «Кара хатынның улы», – дип әйткән. Моны Билял радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә сөйләгән. Аллаһының Расүле теге сәхабәгә ризасызлык белдереп: «Синдә әле җаһиллек калган», – дигән. Шуннан соң бу сүзләрне әйткән сәхабә үз гаебен аңлап, Билял радыяллаһу ганһедән гафу үтенгән.

* * *

Милләтләр вә диннәр арасында тынычлыкны саклау бик мөһим, чөнки мөселман кешесе башка кешеләр белән яхшы мөнәсәбәттә була икән, кешеләр дә безнең динебез хакында яхшы фикердә булырлар. Иң зур дәгъват – ул безнең үз-үзебезне тотуыбыз, әдәпле булуыбыз, изгелек эшләвебез. Диннең асылына төшенмәгән кайбер кешеләр башка милләт һәм дин кешеләренә карата дорфалык күрсәтергә дә ярый дип уйлап ялгыша. Ә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм тормышыбызга,

малыбызга, гаиләбезгә куркыныч тудырмаган кешеләр белән яхшы аралашып, аларга ярдәм итеп яшәргә куша.

Тарихыбыздан билгеле булганча, сугыш кебек бәлаләр бер милләтнең үзен башкалардан өстен куюы, юл куя, дус-тату мөнәсәбәттә яши белмәве аркасында килеп чыккан. Безнең бабаларыбыз ватаннарын, гаиләләрен яклау нияте белән Бөек Ватан сугышында катнашып, ул вакытта динсез дәүләт булса да, бүтән халыклар, диннәр, илләр чикләрен саклау өчен үз тормышларын кызганмаганнар.

Безнең илебезнең бай тарихында күп милләтләр мирасы тупланган. Һәр милләт үз мирасы, тарихы, олылыгы, үз гореф-гадәтләре белән яшәп килә. Мөселман кешесе бигрәк тә шушы мәсьәләләрдә бик җаваплы булырга тиеш, чөнки без Исламны «Сәлам», ягъни тынычлык сүзеннән ясалган дип әйтәбез. Әгәр мөселман кешесе итагатьле булып, башка милләт вә дин кешеләренә карата рәхим-шәфкатьле, мәрхәмәтле булмаса, нинди тынычлык хакында сүз бара ала?! Без гел үрнәк һәм күркәм әхлак әһелләре булырга тиеш. Бөтенебезнең дә Аллаһы каршысына басып җавап тотасыбыз бар, әгәр безнең мәгънәсезлегебез сәбәпле берәрсе динебез хакында начар фикердә булса, ни рәвешле Аллаһы Раббыбыз каршысында җавап бирербез?

Һәр халык үз дөньясы, үз гореф-гадәтләре, үзенең милли җаны белән яши. Үзен акыллы дип санаган һәр мөселман бөтен халык вә милләт әһелләрен хөрмәт итә белергә тиеш. Бу безнең башкалар каршында булган бурычыбыз. Аллаһы Раббыбыз безгә җаныбызны, тәнебезне, мал вә җирне, илне әманәт итеп бирде. Һәм без шушы әманәтне җиренә җиткереп сакларга тиешбез. Матурлыкны күрә белү – ул кешенең калебе изгелектә икәнен белдерә. Бәхетле яшик, бер-беребезне Аллаһы ризалыгы өчен хөрмәт итик, аңлыйк, яратыйк. Аллаһы ике дөнья бәхетен насыйп кылсын!

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Алмаз хәзрәт Галимҗанов,*
*Саба районы имам-мөхтәсибенең*
*яшьләр белән эшләү буенча ярдәмчесе,*
*Сатыш авылы имам-хатыйбы*

*6 ноябрь вәгазе,*

*Рабигыль-әүвәл аеның 20 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Диннең кыйммәте хакында

Барча галәмнәрне бар кылып, аларны тәрбия кылучы, безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин-мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп кылучы, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итүче Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң яхшы хәләл җефет, иң яхшы әти, иң яхшы дус, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде! Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, нык сәламәтлек насыйп итсә иде!

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

1. Вәгазьнең эчтәлегенә караган аятьләр.

Безнең тормышыбызга һәм йортыбызга Ислам дине үзеннән-үзе килмиячәк. Аның өчен әлбәттә тырышлык кую бик мөһим. Диннең кыйммәтен аңлар өчен Раббыбызга итагать кылып, Шәригать хөкемнәрен тулысынча кабул итәргә, алар буенча яшәргә кирәк.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا ادْخُلُوا فِي السِّلْمِ كَافَّةً وَلَا تَتَّبِعُوا خُطُوَاتِ الشَّيْطَانِ ۚ إِنَّهُ لَكُمْ عَدُوٌّ مُّبِينٌ ﴿٢٠٨﴾

**1) «Ий иман китерүчеләр! [Әмерләремә итагать итегез һәм] Тынычлыкка [Исламга] тулысынча керегез, [һәм дини хөкемнәр арасында аерма ясап] шәйтан юлларына иярмәгез, чөнки, шиксез, – ул сезгә ап-ачык дошман»;**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:208

نَّ الدِّينَ عِندَ اللَّهِ الْإِسْلَامُ ۗ

**2) «Һичшиксез, Аллаһы хозурында [хакыйкый һәм кабул ителгән] дин – Ислам [дине генә]»;**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:19

...فَاسْتَبِقُوا الْخَيْرَاتِ ۚ إِلَى اللَّهِ مَرْجِعُكُمْ جَمِيعًا فَيُنَبِّئُكُم بِمَا كُنتُمْ فِيهِ تَخْتَلِفُونَ ﴿٤٨﴾

**3) «Хәерле эшләрдә ярышыгыз. Һәммәгезнең дә кайтуыгыз – Аллаһыга, Ул исә сез ихтилаф иткән нәрсәләрне сезгә хәбәр итәчәк».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:48

Шушы аятькә нигезләнеп, сәхабәләрнең изге гамәлләрдә берберләре белән ярышканын беләбез. Сәхабәләргә безгә караганда дин тоту җиңел иде, чөнки аларның йөрәгендә дин, ә кулында дөнья булды. Ә безнең киресенчә йөрәгебездә дөнья, ә кулыбызда дин. Шуның өчен безгә дин тоту, изге гамәлләрдә ярышу авыр булып тоела.

2. Вәгазьнең эчтәлегенә караган хәдисләр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән:

1) «Кем иртәнге намаздан соң кояш чыкканчыга кадәр зикер әйтсә, аннан соң 2 рәкәгать намаз укыса, тулысынча хаҗ һәм гомрә кылган шикелле булыр»;

2) Бервакыт Расүли Әкрам салләллаһу галәйһи вә сәлләм, Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһенең агач үсентеләрен утыртуын күргәч: «Йә, Әбү Һөрайра, син нишлисең?» – дип сорады. Ул: «Мин үземә агач үсентеләрен утыртам», – дип җавап кайтарды. Пәйгамбәребез болай дип әйтте: «Бу үсентеләргә караганда яхшырагын күрсәтимме?» Әбү Һөрайра: «Әлбәттә, йә Расүлуллаһ!» – диде. Шуннан Расүли Әкрам салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Сүбехәәнәллааһи вәл хәмдүлилләәһи вә ләә иләәһә илләллааһү үәллааһү әкбәр! – дип әйт. Һәр сүз саен сиңа җәннәттә бер агач утыртылыр».

Аллаһы Тәгалә каршында дин кыйммәтле булып тора. Төптән уйлап карасак, дөньяда яшәр өчен күп кирәкми һәм бөтен нәрсәгә ияләшергә була. Әлбәттә, барлык кешеләр бәхетле булуларын телиләр. Ләкин кешене бәхетле итә торган бер генә юл бар, ул да булса Ислам дине.

Кешеләрнең йөрәгендә дөнья кыйммәте булганга күрә, алар шуңа ирешү өчен хыялланалар. Тәмле ризык, матур кием, җитез машина, уңайлы фатир яки шәхси йорт үзеннән-үзе барлыкка килми. Әлбәттә алар өчен вакыт биреп, тырышлык куярга кирәк. Әгәр кешеләрнең йөрәгендә дин кыйммәте булса, алар да шулай ук тырышырлар иде, чөнки Раббыбызның вәгъдәсе хак.

* * *

Безнең тормышыбызга һәм йортыбызга Ислам дине үзеннән-үзе кермәс. Аның өчен, әлбәттә, тырышлык куярга кирәк. Бәрәңге үстерер өчен дә күпме көч таләп ителә. Иң элек җир өстенә тирес таратырга, аннары җирне сукалатырга кирәк. Бәрәңгене утырту гына түгел бит әле. Башта

җирне тырмалыйбыз, аннан чүбен утыйбыз, кортын җыябыз һәм арасын сызабыз. Безнең тормышыбызга һәм йортыбызга дин килсен өчен дә шулай ук тырышлык кую бик мөһим.

Әгәр берәр кешегә фәлән җирдә эшләгән өчен 1000 сум, ә башка урында 2700 сум түлиләр дип әйтсәләр, кайсысын сайлыйбыз?! Әлбәттә, күбрәк түләгән урынны.

«Дөньяда 30 минутлык эш өчен бөтен кешегә дә фатир яисә йорт бирерлек дәүләт, оешма яки ширкәт бармы», – дип сорасалар: «Әлбәттә, юк!» – дип җавап бирерләр иде. Ләкин Юмарт, Бай һәм бирүендә чиге булмаган Аллаһы 30 минут эчендә укыла торган 12 рәкәгать «Доха» намазы өчен җәннәттә алтыннан булган сарай салып куячак.

«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим» дигән сүздә 19 хәреф бар. 19 ны 10 га тапкырласак, 190 савап булыр. Аллаһының Китабын кулыбызга тоткан өчен – савап, аңа караган өчен – савап, укыган өчен – савап, ятлаган өчен – савап, тыңлаган өчен – савап бирелә.

Бал хакында никадәр генә күп сөйләсәк тә, файдасын һәм тәмен искә алсак та, ашамыйча торып, аны белеп булмый. Шулай ук суга кермичә торып, йөзәргә өйрәнә алмыйбыз. Моннан чыгып шуны аңлыйбыз: динне аңлар өчен аның буенча яшәргә кирәк. Вәгазьне шуның белән тәмамлыйм: иң мөһиме һәр мөселманның өстендә 3 җаваплылык бар:

1. Үзеңнең динеңне белү.
2. Дин буенча яшәү.
3. Динне башкаларга җиткерү.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Ибраһим хәзрәт Шәһимәрданов,*

*МДНнең Дәгъват бүлеге белгече*

*13 ноябрь вәгазе,*

*Рабигыль-әүвәл аеның 27 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Аллаһы Тәгаләгә шөкер итү

Барча галәмнәрне барлыкка китереп, аларны тәрбия кылучы, безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин-мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп кылучы, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итүче Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң яхшы хәләл җефет, иң яхшы әти, иң яхшы дус, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде! Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, нык сәламәтлек насыйп итсә иде!

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

1. Вәгазьнең эчтәлегенә караган аятьләр. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

كَمَا أَرْسَلْنَا فِيكُمْ رَسُولاً مِّنكُمْ يَتْلُو عَلَيْكُمْ آيَاتِنَا

وَيُزَكِّيكُمْ وَيُعَلِّمُكُمُ الْكِتَابَ وَالْحِكْمَةَ وَيُعَلِّمُكُم مَّا لَمْ تَكُونُواْ تَعْلَمُونَ

**1) «Арагызга үзегездән бер пәйгамбәр җибәрдек [һәм нигъмәтебезне камил кылдык], ул сезгә аятьләребезне укый, сезне [ширек кебек гөнаһлардан] пакьли, сезгә [Коръән кебек**

**Кыяматкә кадәр саклаearnачак бөек] Китапны һәм Хикмәтне [сөннәтне һәм хөкемнәрне] өйрәтә, сез белмәгән [һәм вәхидән башка бернинди юл белән дә беленә алмаган] нәрсәләрне белдерә»;**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:151

فَاذْكُرُونِي أَذْكُرْكُمْ وَاشْكُرُواْ لِي وَلاَ تَكْفُرُونِ

**2) «Мине искә алыгыз, Мин дә сезне искә алырмын. Миңа шөкер итегез, [әмеремә буйсынмыйча, нигъмәтләремне күрмәгәндәй] Миңа карата шөкерсез булмагыз»;**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:152

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُواْ كُلُواْ مِن طَيِّبَاتِ مَا رَزَقْنَاكُمْوَاشْكُرُواْ لِلّهِ إِن كُنتُمْ
إِيَّاهُ تَعْبُدُونَ

**3) «Ий иман китерүчеләр! Без сезне ризыкландырган [хәләл һәм] пакь нәрсәләрне ашагыз һәм, әгәр инде [Аллаһының бөтен нигъмәтләрнең иясе булганына ышанып] Аңа гына гыйбадәт кыласыз икән, [сезгә шулкадәр хәләл ризык биргәне өчен] Аллаһыга шөкер кылыгыз»;**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:172

فَكُلُوا مِمَّا رَزَقَكُمُ اللَّهُ حَلَالًا طَيِّبًا وَاشْكُرُوا نِعْمَتَ اللَّهِ إِن كُنتُمْ
إِيَّاهُ تَعْبُدُونَ ﴿١١٤﴾

**4) «[Аллаһының нигъмәтләрен инкяр итеп, илчеләрен ялганчы санаучыларның башына төшкән бәлаләр сезгә дә бик ачык аңлашылганга күрә] Аллаһының сезне ризыкландырган**

**нәрсәләреннән хәләл һәм хуш булганын ашагыз, һәм әгәр сез Аңа гына гыйбадәт кыласыз икән, Аллаһының нигъмәтенә шөкер итегез»;**

«Ән-Нәхел / Бал кортлары, 16:114

إِنَّمَا تَعْبُدُونَ مِن دُونِ اللَّهِ أَوْثَانًا وَتَخْلُقُونَ إِفْكًا إِنَّ الَّذِينَ تَعْبُدُونَ مِن دُونِ اللَّهِ. لَا يَمْلِكُونَ لَكُمْ رِزْقًا فَابْتَغُوا عِندَ اللَّهِ الرِّزْقَ وَاعْبُدُوهُ وَاشْكُرُوا لَهُ إِلَيْهِ تُرْجَعُونَ

**5) «Сез, Аллаһыны калдырып, потларга табынасыз һәм ялган уйлап чыгарасыз. Һичшиксез, Аллаһыны калдырып табынган нәрсәләрегез сезгә ризык [кына да] бирә алмыйлар. Сез ризыкларны Аллаһыдан гына сорагыз, Аңа [гына] гыйбадәт кылыгыз һәм Аңа шөкер кылыгыз. [Үлемегез артыннан терелтелеп] Сез Аңа кайтарылачаксыз»;**

«Гәнкәбут / Үрмәкүч», 29:17

وَآتَاكُم مِّن كُلِّ مَا سَأَلْتُمُوهُ وَإِن تَعُدُّواْ نِعْمَتَ اللّهِ لاَ تُحْصُوهَا إِنَّ الإِنسَانَ لَظَلُومٌ كَفَّارٌ

**6) «Ул сез сораган нәрсәләрдән бөтенесен сезгә бирде. Әгәр сез Аллаһының [сезгә биргән бөтен] нигъмәтләрен саный башласагыз, аларны санап бетерә алмассыз. Һичшиксез, кеше – [үзенә бирелгән нигъмәтләр өчен шөкер кыла белмәве белән үз-үзен мәхрүмлеккә этәргән] залим, [тарлыкка төшкән чакта зарланган, муллыкта исә хакларны үтәмәгән] нигъмәт кадерен белмәүче»;**

«Ибраһим», 14:34

وَإِن تَعُدُّواْ نِعْمَةَ اللّهِ لاَ تُحْصُوهَا إِنَّ اللّهَ لَغَفُورٌ رَّحِيمٌ

**7) «Аллаһының [сезгә биргән бөтен] нигъмәтләрен саный башласагыз, аларны санап бетерә алмассыз. Һичшиксез, Аллаһы – [гөнаһларны күпләп] Гафу итүче, Рәхимле»;**

«Ән-Нәхел / Бал кортлары, 16:18

وَلَقَدْ آتَيْنَا لُقْمَانَ الْحِكْمَةَ أَنِ اشْكُرْ لِلَّهِ وَمَن يَشْكُرْفَإِنَّمَا يَشْكُرُ لِنَفْسِهِ

وَمَن كَفَرَ فَإِنَّ اللَّهَ غَنِيٌّ حَمِيدٌ

**8) «Без Локманга хикмәтне [сүздә һәм эштә урынлы өстен белемне] «Аллаһыга шөкер ит!» – дип бирдек. Кем дә кем шөкер итсә, үз файдасына шөкер иткән булыр, кем дә кем инкяр итсә, һичшиксез, Аллаһы – [беркемнең дә ярдәменә мохтаҗ булмаучы] Бай, Мактауга лаеклы»;**

«Локман», 31:12

وَوَصَّيْنَا الْإِنسَانَ بِوَالِدَيْهِ حَمَلَتْهُ أُمُّهُ وَهْنًا عَلَى وَهْنٍ وَفِصَالُهُ فِي عَامَيْنِ

أَنِ اشْكُرْ لِي وَلِوَالِدَيْكَ إِلَيَّ الْمَصِيرُ

**9) «Без кешегә ата-анасына игелек кылырга васыять иттек. Анасы аны зәгыйфьлек өстенә зәгыйфьлек белән йөрткән [бу көчсезлек чоры авырга узуы белән башланып, нифасы беткәнче дәвам итә]. Аны имүдән аеруы исә ике ел эчендә. [Боларның барысы өчен дә, иң элек, Яратучың буларак] Миңа һәм [шуннан соң барлыклар арасыннан яратылыш сәбәбең булган] ата-анаңа шөкер кыл, чөнки кайту – Миңа [булачак]»;**

«Локман», 31:14

وَوَصَّيْنَا الْإِنسَانَ بِوَالِدَيْهِ إِحْسَانًا حَمَلَتْهُ أُمُّهُ كُرْهًا وَوَضَعَتْهُ كُرْهًا وَحَمْلُهُ وَفِصَالُهُ ثَلَاثُونَ شَهْرًا حَتَّى إِذَا بَلَغَ أَشُدَّهُ وَبَلَغَ أَرْبَعِينَ سَنَةً قَالَ رَبِّ أَوْزِعْنِي أَنْ أَشْكُرَ نِعْمَتَكَ الَّتِي أَنْعَمْتَ عَلَيَّ وَعَلَى وَالِدَيَّ وَأَنْ أَعْمَلَ صَالِحًا تَرْضَاهُ وَأَصْلِحْ لِي فِي ذُرِّيَّتِي إِنِّي تُبْتُ إِلَيْكَ وَإِنِّي مِنَ الْمُسْلِمِينَ

**10) «Без кешегә ата-анасына игелек күрсәтүне әмер иттек. Анасы аны мәшәкать белән [тугыз ай карынында] йөртте һәм аны авырлык белән тудырды. Аны йөртүе һәм [имчәктән] аеруы – утыз ай. Нәтиҗәдә, ул [бала яшәп] куәтле чагына ирешкәч һәм [шуннан соң] кырык яшенә җиткәч: «Ий Раббым! Миңа һәм ата-анама биргән [сансыз] нигъмәтеңә шөкер итүемне, Син разый булган изге гамәлләр эшләвемне миңа күндер. Минем өчен минем [үземнән соңгы] нәселемне изгеләрдән кыл. Һичшиксез, мин Сиңа тәүбә иттем һәм мин [гамәлләрен сиңа тапшырган] мөселманнарданмын».**

«Әхкаф / Комлык», 46:15

2. Вәгазьнең эчтәлегенә караган хәдисләр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән:

1) «Сездән югары булганнарга түгел, ә сездән түбән булучыларга карагыз. Бу сезгә Аллаһының нигъмәтләрен ким итеп күрмәүдә ярдәм итәчәк»;

2) «Кем иртә белән иминлектә, саулыкта, бер көнлек ризыгы булган халәттә йокыдан уянса, ул җир йөзенең бөтен байлыгына ия кеше кебек булыр».

* * *

Кешенең шөкер кылуын өч төргә бүлеп була:

- Белем. Кеше әйләнә-тирәсен өйрәнеп, тикшереп һәм чагыштырып, һәрбер әйбернең чын Яратучысы һәм Хак Хуҗасы Аллаһы Тәгалә икәнен аңлаган хәлдә бирелгән һәрбер нигъмәт өчен фәкать бер Раббысына шөкер итә.
- Шатлык. Имам Газали хәзрәтләре моны түбәндәгечә аңлата:

Әгәр юлга чыгарга торган кешегә мәрхәмәтле патша ат бүләк итсә, адәм баласы өч төрле шатлык хисен кичерә:

1. Ия булган атка сөенә. Әлеге очракта аның шатлыгы патша белән бәйле түгел.
2. Кеше, патша аны хөрмәт итеп кыйммәтле бүләк биргәне өчен шатлана. Әгәр ул атны үзе сатып алса, шатлыгы моның хәтле булмас иде. Бу шатлык бары тик Аллаһы Тәгаләдән куркуларын күрсәтеп, безгә дә савап булмасмы икән дип, рәхмәтен көтеп торучыларның хәленә охшаш.
3. Кеше, җәяү түгел, ә атка атланып барып, файдалы бер сәяхәт кыла алачагы өчен, бу хәлдә үз дәүләтенә һәм милләтенә күбрәк файда китерә алачагы өчен шатлана. Ягъни, Аллаһының колы, бирелгән нигъмәтләрдән файдаланып, Аллаһы Тәгалә юлында хезмәт итәргә тырыша, һәм моның белән Яратучысына тагын да якыная. Мондый шатлык хак булып, безнең рәхмәтебезне белдерә торган тагы бер чара булып тора.

Аятьләрдән күренгәнчә, Аллаһы Тәгалә адәм баласына башта Раббысына, аннары инде ата-анасына шөкер итәргә куша, чөнки баланы дөньяга Аллаһының рәхмәте белән әти-әнисе тудыра, аның йөреп китүенә һәм үсеп җитүенә дә алар сәбәпче була. Бу зур кыйммәткә ия булган мөһим мәсьәлә. Әмма Аллаһы Тәгаләнең мәрхәмәте, шәфкате боларның барысыннан да күпкә өстен. Кайчан да булса кеше Раббысына кире кайтарылачак һәм моннан котылу юлы юк. Шуңа күрә Раббыбыз каршысына

барачагыбызны онытмыйк, хәерле гамәлләребезне арттырыйк, һәрчак шөкердә булыйк.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*

*МДНнең Дәгъват бүлеге белгече,*

*«Саләх» мәчете имам-хатыйбы*

*20 ноябрь вәгазе,*

*Рабигыль-ахыр аеның 5 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Бала – җәннәт чәчәге

Барча галәмнәрне барлыкка китереп, аларны тәрбия кылучы, безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин-мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп кылучы, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итүче Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң яхшы хәләл җефет, иң яхшы әти, иң яхшы дус, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде! Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, нык сәламәтлек насыйп итсә иде!

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

1. Вәгазьнең эчтәлегенә караган аятьләр. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا قُوا أَنفُسَكُمْ وَأَهْلِيكُمْ نَارًا وَقُودُهَا النَّاسُ وَالْحِجَارَةُ عَلَيْهَا مَلَائِكَةٌ غِلَاظٌ شِدَادٌ لَّا يَعْصُونَ اللَّهَ مَا أَمَرَهُمْ وَيَفْعَلُونَ مَا يُؤْمَرُونَ ﴿٦﴾

**1) «Ий иман китерүчеләр! [Әмерләрне тотып, тыюлардан тыелып] Үз-үзләрегезне һәм гаиләләрегезне уттан саклагыз, [башка**

**утларның ягулыгы утын булса] аның ягулыгы [кяфер] кешеләр һәм [бик тиз кабынып, бик күп яндыра торган күкерт] ташлар»;**

«Тәхрим / Тыю», 66:6

وَإِذْ قَالَ لُقْمَانُ لِابْنِهِ وَهُوَ يَعِظُهُ يَا بُنَيَّ لَا تُشْرِكْ بِاللَّهِ ۖ إِنَّ الشِّرْكَ لَظُلْمٌ عَظِيمٌ ﴿١٣﴾

**2) «Менә Локман улына вәгазьләп әйтте: «Ий улым! [Бернәрсәне дә] Аллаһыга ширек кушма. Һичшиксез, ширек – бик зур золым».**

«Локман», 31:13

2. Вәгазьнең эчтәлегенә караган хәдисләр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән:

1) «Балаларыгызга кадер-хөрмәт күрсәтегез, аларны асыл кешеләр итеп тәрбияләгез»;

2) «Кеше өч кыз бала тудырып тәрбияләсә, аларны тормышка чыгарса һәм аларга игелек кылуны дәвам итсә, ул кешенең җәннәттә урыны бар»;

3) «Һичбер ата баласына затлы әдәп һәм тәрбиядән башка файдалырак нәрсә бирә алмас».

* * *

Ата-ананың балаларына карата булган вазифалары:

1. Балага Ислам диненә муафыйк булган күркәм исем кушу.

Аллаһы каршында иң матур исем «Габд» сүзеннән башлана. Мисал өчен: Габдулла, Габдрахман, Габдрахим, Габдессәлам. Аннары Мөхәммәд исеме. Шуннан пәйгамбәрләрнең, сәхабәләрнең исемнәре. Һәм татар халкына хас, күркәм, мәгънәле булган исемнәр.

Балага иң элек азан ишеттерергә кирәк. Азан укып, баланың уң колагына исем кушабыз. Аннары, камәт төшереп, баланың сул колагына исем әйтелә.

2. Сөннәтләү.

Гадәттә ир баланы җиде көннән соң сөннәткә утыртырга кирәк. Беренчедән, бу Ислам дине символы. Икенчедән, Ибраһим галәйһиссәламнең юлына иярү (Ибраһим галәйһиссәлам 80 яшендә сөннәткә утыртыла). Өченчедән, мөселман булуның билгесе. Дүртенчедән, бу Аллаһы һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең әмерләренә буйсыну. Бишенчедән, табиблар да моны хуплый, чөнки бу – чисталык, пакьлек.

3. Хәләл ризык.

Баланы әнисе ике елга кадәр имезә. Баланы имезгән чакта: «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим», – дип әйтергә кирәк. Аннары хәләл ризык ашату зарур. Хәләл ризыкның файдасы: ризык чиста, бәрәкәтле була, изге эшләргә көч һәм куәт бирә, Аллаһының ризалыгына ирешелә, кылган догалар кабул ителә.

4. Дин гыйлеме.

Әлбәттә, балаларыбыз бакчада, мәктәптә, югары уку йортларында белем алалар. Әмма аларны иң элек дин гыйлеменә өйрәтергә кирәк. Баланың теле ачыла башлагач, башта «Аллаһы», «Ләә иләәһә илләллаһ Мүхәммәдүр-расүлүллаһ» сүзләренә өйрәтергә хаклыбыз.

5. Һөнәргә өйрәтү.

Бөтен пәйгамбәрләр галәйһимуссәлам нинди дә булса һөнәргә ия булганнар. Баланың нәрсәгә сәләте булса, шуны үстерергә һәм куәтләргә кирәк. Һәр һөнәр кирәкле.

6. Балигълыкка ирешкәч, баланы өйләндерү яки кияүгә бирү.

Әлбәттә, монда да әти-әни катнашырга тиеш. Иң элек балага бу эшнең нинди җитди булуын аңлатырга кирәк. Элек әби-бабаларыбыз җиде буынга кадәр тикшергәннәр.

Бала тәрбияне иң элек ана карынында булганда, аннары әти-әнидән ала. Ул дөрес тәрбия алса, кайда гына булмасын, туры юлны сайлаячак һәм кешеләрнең начар йогынтысыннан имин булачак.

Аллаһы Тәгалә безгә балаларыбызны дөрес тәрбияләргә насыйп итсен. Аларның игелеген күреп, ике дөньяның рәхәтенә, ике дөнья бәхетенә ирешергә насыйп булсын. Әмин.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Ибраһим хәзрәт Шәһимәрданов,*

*МДНнең Дәгъват бүлеге белгече*

*27 ноябрь вәгазе,*

*Рабигыль-ахыр аеның 12 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Вакытыбызны исраф кылмыйк

Барча галәмнәрне барлыкка китереп, аларны тәрбия кылучы, безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин-мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп кылучы, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итүче Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң яхшы хәләл җефет, иң яхшы әти, иң яхшы дус, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде! Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, нык сәламәтлек насыйп итсә иде!

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

1. Вәгазьнең темасына караган аятьләр. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

إِنَّ الْمُبَذِّرِينَ كَانُوا إِخْوَانَ الشَّيَاطِينِ ۖ وَكَانَ الشَّيْطَانُ لِرَبِّهِ كَفُورًا ﴿٢٧﴾

**1) «[Малларын харам юлда сарыф итеп һәм заруriяттән тыш урыннарда әрәм-шәрәм итеп] Исраф итүче кешеләр – шәйтаннарның кардәшләре [кебек бик начар бер хәлдәләр]. Шәйтан исә – Раббысына карата инкярчы»;**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:27

وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ ﴿٥٦﴾

**2) «Мин җеннәрне һәм кешеләрне Миңа гыйбадәт кылсыннар дип яраттым».**

«Әз-Зарият / Таратучылар», 51:56

2. Вәгазьнең эчтәлегенә караган хәдисләр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән:

1) «Кеше ике нигъмәтнең кадерен белми: берсе – сәламәтлек, икенчесе – буш вакыт».

2) «Биш нәрсә килгәнче, биш төрле әйбернең кадерен бел. Картлык килгәнче, яшьлегеңнең кадерен бел. Авыру килгәнче, сәламәтлегеңнең кадерен бел. Фәкыйрьлек килгәнче, байлыгыңның кадерен бел. Мәшәкатьләр килгәнче, вакытыңның кадерен бел. Үлемеңнән әүвәл яшәвеңнең кадерен бел».

* * *

Исраф – бушка уздырылган, туздырылган дигән сүз. Һәм бу төшенчә матди әйберләргә генә кагылмый. Мәгънәсез үткәрелгән вакыт, гөнаһка әрәм ителгән сәламәтлек, Раббыбызны зикер итмичә үткәрелгән гомер – барысы да исраф, ягъни гөнаһ. Яшь чакта исраф ителгән әйберләр сизелми. Әти-әниләр гел балаларын: «Компьютерда, телефонда утырма, вакытыңны әрәм итмә!» – дип ачулана. Ә баланың шуңа ачуы килә: әллә нинди сәбәпләр таба, аклана. «Мин бит озак утырмыйм, мин менә бер-ике сүз генә яздым, мин файдалы әйберләр карыйм», – дип әйтә.

Без еш кына үз-үзебезне алдыйбыз. Мин яхшы әти, мин яхшы ир, дип уйлыйбыз. Үзебезне тәкъва мөселман дип атыйбыз. Ә чынлыкта, тикшереп карасак, без әти буларак та, ир буларак та, хезмәткәр буларак та түбән дәрәҗәдә икәнлегебез ачыклана. Безнең бердәнбер осталыгыбыз – телефонда утыру. Бу бит иң җиңеле. Лайк куеп, комментарий язу күп көч тә,

тырышлык та, акыл да таләп итми. Күбебез шушы җиңел юлны сайлый һәм гомеренең күп өлешен бушка сарыф итә. Аллаһы Тәгалә безне мондый тормыштан сакласын иде.

Игътибар итсәгез, бер сәгать телефон янында утыру сизелми дә үтеп китә. Ә кулга Коръән алып, 5 минут утырсак, инде бик зур эш эшләгән кебек булабыз, арабыз, чөнки билгеле булганча, безнең нәфесебез бар. Һәрберебез янында котыртып утыручы шәйтан бар. Ул безнең игътибарны башкага җәлеп итү, уңга-сулга кертеп җибәрү, Аллаһы Тәгаләдән ераклаштыру өчен кулыннан килгәннең барысын да эшли. Шуңа күрә 5 минут Коръән уку безнең өчен бик авыр, катлаулы кебек тоела. Ә сәгатьләр буе телефон экранына төбәлеп утыру җиңел дә, рәхәт тә, чөнки бу Аллаһы юлы түгел, бу шәйтан юлы.

Бүген күпләрнең социаль челтәрләрдә, компьютер уеннарында утыруы – ул бәйлелек. Аннан котылу өчен безгә Аллаһы Тәгаләгә якынаерга, вакытыбызны дөрес бүләргә кирәк. Үзебезне мөселман буларак, белгеч буларак, ир буларак, ата кеше буларак үстереп, вакытыбызны исраф кылмыйча яшәсәк иде.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рөстәм хәзрәт Хәйруллин,*

*«Гаилә» мәчете имам-хатыйбы*

*4 декабрь вәгазе,*

*Рабигыль-ахыр аеның 19 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Гаиләне саклау хакында

Барча галәмнәрне барлыкка китереп, аларны тәрбия кылучы, безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин-мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп кылучы, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итүче Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң яхшы хәләл җефет, иң яхшы әти, иң яхшы дус, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде! Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, нык сәламәтлек насыйп итсә иде!

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

1. Вәгазьнең эчтәлегенә караган аятьләр. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا قُوا أَنفُسَكُمْ وَأَهْلِيكُمْ نَارًا وَقُودُهَا النَّاسُ وَالْحِجَارَةُ عَلَيْهَا مَلَائِكَةٌ غِلَاظٌ شِدَادٌ لَّا يَعْصُونَ اللَّهَ مَا أَمَرَهُمْ وَيَفْعَلُونَ مَا يُؤْمَرُونَ ﴿٦﴾

**1) «Ий иман китерүчеләр! [Әмерләрне тотып, тыюлардан тыелып] Үз-үзләрегезне һәм гаиләләрегезне уттан саклагыз, [башка**

**утларның ягулыгы утын булса] аның ягулыгы [кяфер] кешеләр һәм [бик тиз кабынып, бик күп яндыра торган күкерт] ташлар».**

«Тәхрим / Тыю», 66:6

2. Вәгазьнең эчтәлегенә караган хәдисләр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән:

1. «Булачак хатыныгызда дүрт нәрсәгә игътибар итегез: байлыгына, нәселенә, матурлыгына һәм диндә булуына. Диндә булганына ирешергә тырыш, юкса оттырырсың!»

2. «Һәрберегез көтүче һәм һәрберегез үз көтүе өчен җаваплы булачак. Имам (җитәкче) – көтүче, ул үзенең халкы өчен җавап бирер. Ир – үз гаиләсендә көтүче, шул хакта җавап бирер. Хатын – өендә көтүче, шул хакта җавап бирер»;

3. «Өйләнешегез, күбәегез, Кыямәт көнендә мин башка өммәтләр алдында сезнең белән горурланачакмын».

* * *

Гаилә нык булсын өчен алты ысул бар:

1) Шуны әйтергә була: дөньяда «идеал» кеше юк. Моның белән без барыбыз да килешә алабыз. Бүлмәдә ут яктысы булсын өчен плюс кына җитми, минус та кирәк. Димәк, монда Раббыбызның хикмәте бар.

2) Ни өчен Аллаһы Тәгалә безне ике күзле итеп яраткан? Уң күзебез белән кешенең фәкать яхшы якларын күрер, ә сул күзебез белән үзебезнең кимчелекләребезгә карап, аларны төзәтер өчен. Шулай булдыру өчен һәркайсыбыз тырышлык куярга тиешле.

3) Һәркайсыбызга «адвокат» булып якларга, ә үзебез өчен «прокурор» булырга. Әлбәттә бу авыр нәрсә. Кешене гаепләргә, үзебезне акларга җиңел. Безгә охшамаган нәрсәләр күп. Әгәр берәүгә имән бармагы белән төртеп: «Ул фәлән, ул төгән», – дип кимчелекләрен санасак, калган өч

бармак үзебезгә караганын күрербез. Бу: «Үзеңә кара һәм үзеңне бел!» – дигәнне аңлата.

4) Дөнья – мәшәкать йорты һәм тормышта төрле хәлләр килеп чыгарга мөмкин. Шуның өчен кешеләр бер-берләренә юл бирергә тиеш. Әгәр тар юлда машиналар бер-берсенә юл бирмәсәләр, алар һәлакәткә юлыгачаклар. Шулай ук ир белән хатын үзара килешмәсәләр, аңлашмасалар, ачуланышуга, сугышуга, хәтта Аллаһы сакласын, аерылуга җитәргә мөмкиннәр.

5) Бер-беребезгә матур сүзләр әйтү тиеш. Мәсәлән, кадерлем, сөеклем, дип дәшүдә телебезне кызганмаска кирәк. Бу сүзләрне әйтер өчен күп көч һәм акча түләү кирәкми. Гаиләдә ир белән хатын үзара игътибарлы булса, бер-берләренә җылы сүз әйтеп яшәсә, бу гаиләнең ныгуына, мәхәббәтнең артуына сәбәп булачак.

6) Әгәр ир белән хатын икесе дә иманлы һәм диндә булсалар, бу гаилә иншә Аллаһ нык булачак.

«Тәрбия» сүзе шәхси үрнәк дигәнне аңлата. Шуның өчен ата һәм ана үзләре дә диндә булып, үз балаларына үрнәк күрсәтеп, аларга дин гыйлемен ирештерергә тиешләр.

Аллаһы Тәгалә барлык гаиләләргә һидаять, нык иман, тынычлык, иминлек биреп, сабырлык һәм ризалыкта, үзара күркәм мөнәсәбәттә булырга һәм бер-берсен саклап, яклап, кадерләп, аңлашып яшәргә, ике як әти-әниләрне, туганнарны тигез күреп, башкаларга үрнәк гаилә булып яшәргә насыйп итсен. Әәмин.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының

саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Ибраһим хәзрәт Шәһимәрданов,*

*МДНнең Дәгъват бүлеге белгече*

*11 декабрь вәгазе,*

*Рабигыль-ахыр аеның 26 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Ватанны сөю – иманнан

Барча галәмнәрне барлыкка китереп, аларны тәрбия кылучы, безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин-мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп кылучы, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итүче Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң яхшы хәләл җефет, иң яхшы әти, иң яхшы дус, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде! Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, нык сәламәтлек насыйп итсә иде!

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

1. Вәгазьнең эчтәлегенә караган аятьләр.

Мөселман кешесе Ватанын яратырга, аны кайгыртып яшәргә тиеш, чөнки кеше үзенең бүгенге көне белән генә түгел, ә киләчәген дә уйлап гомер итә. Барыбыз да белә: канәгатьсезлек күрсәтеп, шөкерсезлек белдереп кенә уңышка ирешеп булмый. Тормышны яхшы якка үзгәртеп өчен үзебездән тырышлык кую мөһим. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

لَهُ مُعَقِّبَاتٌ مِّن بَيْنِ يَدَيْهِ وَمِنْ خَلْفِهِ يَحْفَظُونَهُ مِنْ أَمْرِ اللَّهِ ۗ إِنَّ اللَّهَ لَا يُغَيِّرُ مَا بِقَوْمٍ حَتَّىٰ يُغَيِّرُوا مَا بِأَنفُسِهِمْ ۗ وَإِذَا أَرَادَ اللَّهُ بِقَوْمٍ سُوءًا فَلَا مَرَدَّ لَهُ ۚ وَمَا لَهُم مِّن دُونِهِ مِن وَالٍ ﴿١١﴾

**1) «Һичшиксез, алар [кешеләр] үз нәфесләрендә булганны алмаштырмый торып, Аллаһы кешеләрдә булганны алмаштырмый. Әмма Аллаһы бер кавемгә [газап] яманлык [килүен] теләсә, аны бернәрсә дә кире бора алмас. Алар [башларына газап килү тәкъдир ителгәннәр] өчен Аннан [Аллаһы Тәгаләдән] башка бер хөкемдар да юк»;**

«Рәгыд / Күк күкрәү», 13:11

Аллаһы Тәгалә галимнәр, казыйлар һәм идарәчеләргә буйсынырга куша. Пәйгамбәребезнең хәдисләрендә дә: «Мөселманга ошаса да, ошамаса да үз идарәчесенә буйсыну тиеш», – дигән. Шул ук вакытта Сөннәтебез Аллаһы Тәгалә әмерләрен үтәмәүдә буйсыну ярамый, бары хәерледә генә буйсынырга тиешле дип өйрәтә. Идарәчеләргә буйсынып без иминлекне, татулыкны саклыйбыз, үз ватаныбызга мәхәббәтебезне белдереп, аны яхшыртуда үз өлешебезне кертәбез.

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا أَطِيعُوا اللَّهَ وَأَطِيعُوا الرَّسُولَ وَأُولِي الْأَمْرِ مِنكُمْ ۖ ﴿٥٩﴾

**2) «Ий иман китерүчеләр! Аллаһыга итагать итегез, Расүлгә һәм арагыздан булган җитәкчеләрегезгә итагать итегез».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:59

2. Вәгазьнең эчтәлегенә караган хәдисләр.

Без Аллаһының нигъмәтләрен күреп, алар өчен рәхмәтле булып яшәргә өйрәнсәк иде. Илләребез, көннәребез тыныч, имин булып тор-

ганда, җитеш тормышта яшәгәндә һаман зарланып, ризасызлык белдереп тору мөселман кешесенең эше түгел.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән:

1) «Әгәр кеше иртүк сау-сәламәт булып уянса һәм аның ашар ризыгы, кияр киеме булса – ул иң бай кеше инде».

* * *

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормыш юлына күз салганда, тагын бер әһәмиятле вакыйгага игътибар итсәк иде: динебез ачыктан-ачык тарала башлагач, Аллаһы Расүлен һәм аның сәхабәләрен бөек Мәккә шәһәрендә кысрыклый башлыйлар һәм ул үзенең тарафдарлары белән Мәдинә шәһәренә һиҗрәт кылырга мәҗбүр була. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм юлга чыккач, туып үскән Мәккә шәһәренә карап, юксынып: «Әгәр, Аллаһымнан әмер булмаса, мин сине калдырмас идем, йә газиз Мәккәм!» – дип әйткәнен беләбез. Динебез тарихында бәян ителгән бу вакыйга адәм баласының тормышында туган иле, җире гаять зур роль уйнаганын күрсәтә. Үзең яшәгән җирлекне: авылны, шәһәрне, илне ярату гына бер хәл, без аның камил, күркәм, имин булуы, бу мохиттә җәмгыятьтә тәртип, дисциплина хакимлек итүе өчен үзебездән нинди өлеш кертә алабыз соң? Һәм нининдидер өлеш кертә алсак та, аны эшләр өчен нинди омтылышлар ясыйбыз? Менә моның хакында уйлансак иде, мөхтәрәм дин кардәшләрем!

Мөселман кешесе һәрнәрсәнең хикмәтен күрергә, һәрнәрсәне хәерлегә юрарга омтылып яши. Бу тормышта, җәмгыятебездә барган теләсә нинди үзгәрештә Кодрәт иясенең бер хикмәте, Аның гыйлеме барлыгын таный.

Аллаһы Тәгалә һәрберебезнең күңеленә дә туры юлны – һидаятьне салып, бу тормышта җәмгыятебез өчен дә, кешеләр өчен дә файдалы булып яшәүләребезне насыйп итсен иде.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*«Хозур» редакциясе*

*18 декабрь вәгазе,*

*Җөмәдәл-әүвәл аеның 3 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Хөсетлек чире

Барча галәмнәрне барлыкка китереп, аларны тәрбия кылучы, безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин-мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп кылучы, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итүче Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң яхшы хәләл җефет, иң яхшы әти, иң яхшы дус, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде! Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, нык сәламәтлек насыйп итсә иде!

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

1. Вәгазьнең эчтәлегенә караган аятьләр. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

أَمْ يَحْسُدُونَ النَّاسَ عَلَىٰ مَا آتَاهُمُ اللَّهُ مِن فَضْلِهِ ۖ فَقَدْ آتَيْنَا آلَ إِبْرَاهِيمَ
الْكِتَابَ وَالْحِكْمَةَ وَآتَيْنَاهُم مُّلْكًا عَظِيمًا ﴿٥٤﴾

**1) «Әллә соң алар Аллаһы Үзенең фазылыннан [Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм сәхабәләре кебек] кешеләргә биргән [пәйгамбәрлек, Китап һәм өстенлек кебек] нәрсәләрдән**

**көнләшәләрме? Без бит Ибраһим гаиләсенә Китап [Тәүрат, Инҗил һәм Зәбур] вә хикмәт биргән идек, аларга [Йосыф, Давыд һәм Сөләйман галәйһимуссәламгә зур хакимлек тә биргән идек]»;**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:54

أَهُمْ يَقْسِمُونَ رَحْمَتَ رَبِّكَ ۚ نَحْنُ قَسَمْنَا بَيْنَهُم مَّعِيشَتَهُمْ فِي الْحَيَاةِ الدُّنْيَا ۚ وَرَفَعْنَا بَعْضَهُمْ فَوْقَ بَعْضٍ دَرَجَاتٍ لِّيَتَّخِذَ بَعْضُهُم بَعْضًا سُخْرِيًّا ۗ وَرَحْمَتُ رَبِّكَ خَيْرٌ مِّمَّا يَجْمَعُونَ ﴿٣٢﴾

**2) «Раббыңның рәхмәтен әллә алар бүләләрме? Дөнья тормышында ризыкларын араларында Без бүлгәләдек һәм берәүләре икенчеләрен хезмәтче итеп алсыннар дип, Без аларның кайберләрен [байлык ягыннан] кайберләреннән дәрәҗәләрдә күтәрдек».**

«Әз-Зухруф / Зиннәтләнү», 43:32

2. Вәгазьнең эчтәлегенә караган хәдисләр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән:

1) «Дөреслектә, тәндә бер ит кисәге бардыр. Әгәр ул яраклы хәлгә килсә, бөтен тән дә яраклы хәлгә килер. Әгәр ул бозылса, бөтен тән дә бозылыр»;

2) «Кеше хакында начар уйлаудан сакланыгыз. Начар уйлар – иң ялган сүзләрдер. Бер-берегезне тикшереп йөрмәгез, бер-берегезгә җасуслык кылмагыз (ягъни бер-берегез артыннан шпионлык кылып йөрмәгез). Бер-берегездән көнләшмәгез. Бер-берегезгә нәфрәтле булмагыз. Бер-берегезгә борылып ташлап китмәгез. Әй Аллаһы коллары! Бер-берегезгә туганнар булыгыз!»;

3) «Сезгә кадәр яшәгәннәрнең чирләре сезгә әкренләп килеп җитә: ул ике чир хөсетлек һәм нәфрәт (бер-береңне күрә алмау). Һәм бу чирләр – кыручылар булып торалардыр. Ләкин алар чәчне кырмыйлар, ә динне кыралардыр»;

4) «Көнчелектән сакланыгыз. Дөреслектә, утынны янгын ашаган кебек, көнчелек тә изгелекләрне ашыйдыр»;

5) «Ике кешегә генә көнләшеп була: беренчесе әгәр Аллаһы аңа гыйлем-хикмәт биреп, ул шул хикмәт белән гамәл кылып, башкаларны гыйлемгә өйрәтсә. Ә икенчесе исә, әгәр Аллаһы Тәгалә берәр кешегә күп байлык биреп, ул кеше байлыгын бары тик хаклык юлында сарыф итсә».

* * *

Хөсетлек бик борынгы чир. Хөсетлекнең ахыры – Аллаһы Тәгаләгә көферлек, ә башы – яхшылыкны, нигъмәтне теләмәү. Хәтта, галимнәр: «Көнчелек Аллаһыга каршы чыккан беренче гөнаһ», – дип әйттеләр. Һәм бу чыннан да шулай. Хөсетлек чире кешене зур авырлыкларга китерә, аның тормыш ямен бетерә, гөнаһлар, бозыклыклар дөньясына этәрә. Бу чир нинди генә йөрәккә кермәсен, шул йөрәкне боза. Хәзерге хәлен дә, киләчәктә булачагын да мөшкел хәлдә калдыра. Иблис Аллаһыга якын булганнардан соң да, җәннәттә яшәгәннән соң да ләгънәт кылынды һәм җиргә сөрелде. Сәбәбе – көнчелек белән тәкәбберлек иде. Адәм галәйһиссәламнең улы Кабил көнчелеге сәбәпле бертуганы Һабилне үтерде. Пәйгамбәрләр, илчеләр халыкларына килгәндә аларга каршы чыгучылар, имансызлык башлыклары көнчелекләре сәбәпле пәйгамбәрләргә дошман булдылар.

Хәтта мөселманнар арасында булган матур гына намаз, уразалар тоткан җирдән кинәт дошманлашып, төрле сүзләр таратып, вөҗдан пычратучыларның сәбәбе көнчелек иде.

Әйе, көнче кеше Кыямәт көнендә зур хәсрәткә очрар, изгелекләрен югалтып бетерер.

Мөхтәрәм җәмәгать, көнләшүдән сакланыгыз! Әгәр хөсетлек чире үтеп керсә, беркемне дә кызганып тормый. Олы яшькә җиткән өлкән кешене дә, зур гыйлем алган галимне дә, зур дәрәҗәгә ирешкә хөрмәтле кешене дә, наданлыкта булган гади кешене дә үзенә буйсындыра.

Хөсетлектән саклану юллары:

1. Аллаһының гаделлегенә, хикмәтенә ышану.

2. Аллаһы биргәнгә шөкер кылу, канәгать булу.

3. Көнчелек хисләреннән котылу өчен Аллаһыга дога кылу.

Раббыбыз безне хөсетлек чиреннән сакласын! Бәла-казалардан имин кылсын! Шәйтан коткыларыннан безне ерак кылсын! Әмин!

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Сәлимҗан хәзрәт Домнин,*

*Кабан арты мәчете имамы*

*25 декабрь вәгазе,*

*Җөмәдәл-әүвәл аеның 10 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# «Аллаһы яхшырак белә» сүзен еш әйтәбезме?

Барча галәмнәрне барлыкка китереп, аларны тәрбия кылучы, безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин-мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп кылучы, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итүче Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң яхшы хәләл җефет, иң яхшы әти, иң яхшы дус, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде! Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, нык сәламәтлек насыйп итсә иде!

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

1. Вәгазьнең эчтәлегенә караган аятьләр. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَإِذْ قَالَ رَبُّكَ لِلْمَلَائِكَةِ إِنِّي جَاعِلٌ فِي الْأَرْضِ خَلِيفَةً ۖ قَالُوا أَتَجْعَلُ فِيهَا مَن يُفْسِدُ فِيهَا وَيَسْفِكُ الدِّمَاءَ وَنَحْنُ نُسَبِّحُ بِحَمْدِكَ وَنُقَدِّسُ لَكَ ۖ قَالَ إِنِّي أَعْلَمُ مَا لَا تَعْلَمُونَ ﴿٣٠﴾

1) **«Менә Раббың фәрештәләргә: «Һичшиксез, Мин җирдә хәлифә [итеп Адәмне [галәйһиссәлам] яратачакмын!» – дип әйткәч, алар [каршы төшү максаты белән түгел, ә хикмәтен белер өчен]: «Әллә җирдә бозыклык кылучыны һәм кан коючыны яратачаксыңмы? Без бит һәрвакыт Сиңа мактау белән тәсбих әйтәбез, [Затыңның бөтен кимчелекләрдән пакь булуын танып] олылыйбыз», – диделәр. Ул: «Һичшиксез, Мин сез белмәгәннәрне беләм!» – диде»;**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:30

قُلْنَا اهْبِطُوا مِنْهَا جَمِيعًا ۖ فَإِمَّا يَأْتِيَنَّكُم مِّنِّي هُدًى فَمَن تَبِعَ هُدَايَ فَلَا خَوْفٌ عَلَيْهِمْ وَلَا هُمْ يَحْزَنُونَ ﴿٣٨﴾

2) **«Без әйттек: «Барыгыз бергә моннан төшегез! Әгәр Миннән сезгә һидаять килсә, кемнәр Минем һидаятемә иярә, шуларга бернинди курку да булмас, алар хәсрәт тә чикмәс».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:38

2. Вәгазьнең эчтәлегенә караган хәдисләр:

1) Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә берәр кеше турында начар сүз сөйли башласалар, ул: «Сез җитмеш сәбәп табып булса да, ул кешене акларга тырышыгыз», – дип әйтә торган булган.

* * *

Бөтен гыйлем – Аллаһы Тәгаләдә. Адәм баласы, күпме генә гыйлем алса да, нинди генә тоемлау сәләтенә ия булса да – беркайчан да Раббысы белгәнне белә, аңлый алмас. Чын дөреслекне белми торып, үзеңне дә, башкаларны да бутарга ярамый. Шуңа күрә мөселман кешесе: «Аллаһы

Тәгалә яхшырак белә» сүзенең асыл мәгънәсен дөрес аңларга һәм шушы гыйбарәне онытмаска тиеш.

Шуңа күрә без, берәрсе килеп, берәүне яманлый тотынса, без иң элек гайбәт таратуны туктатып: «Аллаһы Тәгалә яхшырак белүчедер», – дип әйтик.

Бер бик яхшы гыйбарәне ишеткәнегез бардыр инде: «Әгәр дә кемнеңдер ни өчен шулай эшләгәнен аңларга теләсәң, аның аяк киемнәрен киеп, ул үткән юлны үтеп кара». Кайвакыт киләләр дә: «Хәзрәт, менә мин 100% беләм аның шулай икәнен. Ул чыннан да шулай эшләде», – дип сөйли башлыйлар. Юк, җәмәгать, белмисез! Үз-үзегезне дә, башкаларны да алдамагыз! Йөз процентка белүче бары тик Аллаһы Тәгалә генә. Һәм Кичерүче дә бары тик Ул гына. Кемдер гөнаһлы икән – бәлки тәүбә иткәндер. Раббыбыз аны кичергәндер. Ә без гайбәтебез өчен гөнаһ җыеп утырабыз.

Дин сорауларына җавап биргәндә дә галим булмаган кеше өчен иң хәерле җавап: «Аллаһы яхшырак белә» дигән сүзләр. Гыйлем иясе түгелсең икән: «Белмим», – дип әйтүнең ояты юк. Гөнаһысы да юк. Коръәни-Кәримебез, Сөннәтебез, дүрт мәзһәб галимнәре бар. Алардан соң килгән зур галимнәребез бар. Без шуларның фикеренә итагать итүчеләр. «Фатиха» сүрәсен хатасыз укый белмәгән килеш фәтва чыгару – үзе гөнаһ. Зур галимнәребез, җавапларын төгәлләгәннән соң: «Аллаһы яхшырак белә», – дигәндә, безгә: «Мин шулай икәнен төп-төгәл беләм», – дип әйтергә оят булырга тиеш.

Нинди генә эшкә тотынсак та, Аллаһы Тәгаләдән хәерлесен сорыйк. Һәм Аллаһыдан да яхшырак Белүче юк һәм булмаячак икәнен онытмыйк.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рөстәм хәзрәт Хәйруллин,*

*«Гаилә» мәчете имам-хатыйбы*

*1 гыйнвар вәгазе,*

*Җөмәдәл-әүвәл аеның 17 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Яшерен гыйлем

Барча галәмнәрне барлыкка китереп, аларны тәрбия кылучы, безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин-мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп кылучы, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итүче Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң яхшы хәләл җефет, иң яхшы әти, иң яхшы дус, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде! Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, нык сәламәтлек насыйп итсә иде!

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

1. Вәгазьнең эчтәлегенә караган аятьләр. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَعِندَهُ مَفَاتِحُ الْغَيْبِ لَا يَعْلَمُهَا إِلَّا هُوَ ۚ وَيَعْلَمُ مَا فِي الْبَرِّ وَالْبَحْرِ ۚ وَمَا تَسْقُطُ مِن وَرَقَةٍ إِلَّا يَعْلَمُهَا وَلَا حَبَّةٍ فِي ظُلُمَاتِ الْأَرْضِ وَلَا رَطْبٍ وَلَا يَابِسٍ إِلَّا فِي كِتَابٍ مُّبِينٍ ﴿٥٩﴾

**1) «Гаиб ачкычлары – Анда гына ки, Аннан башка боларны беркем дә белми. Корыда һәм диңгездә булганны Ул гына белә. Ул**

**белмичә бер генә яфрак та төшми. Җир караңгылыкларындагы орлык бөртеге дә, яшь яки коры һәрнәрсә дә – ап-ачык бер китапта [Ләүхүл-Мәхфүздә теркәлгән]»;**

«Әнгәм / Терлек», 6:59

إِنَّ اللَّهَ عِندَهُ عِلْمُ السَّاعَةِ وَيُنَزِّلُ الْغَيْثَ وَيَعْلَمُ مَا فِي الْأَرْحَامِ ۖ وَمَا تَدْرِي نَفْسٌ مَّاذَا تَكْسِبُ غَدًا ۖ وَمَا تَدْرِي نَفْسٌ بِأَيِّ أَرْضٍ تَمُوتُ ۚ إِنَّ اللَّهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ ﴿٣٤﴾

**2) «Һичшиксез, Сәгатьнең [кайчанлыгының] белеме Аллаһы Үзендә, яңгырны [тәкъдир иткән вакытында] Ул яудыра, карыннарда ни булганын Ул белә. [Бүген нәрсә кылганыгызны һәркем белсә дә] Иртәгә [начарлыктан һәм яхшылыктан, зарардан һәм файдадан] нәрсә казаначагын беркем дә белми, [хәтта эшләргә ниятләгән эшенең киресен эшләргә мәҗбүр булалар, һәркем туган җирен белсә дә] беркем дә кайда үләчәген белми. Һичшиксез, Аллаһы – [һәрнәрсәне] Белүче, [һәрнәрсәдән] Хәбәрдар»;**

«Локман», 31:34

قُلْ إِنَّمَا الْعِلْمُ عِندَ اللَّهِ وَإِنَّمَا أَنَا نَذِيرٌ مُّبِينٌ ﴿٢٦﴾

**3) «Әйт: «Гыйлем тик Аллаһыда гына. Мин исә [Аның миңа белдергәннәрен] аңлатучы кисәтүчемен»;**

«Мүлек / Патшалык», 67:26

إِنَّهُمْ يَرَوْنَهُ بَعِيدًا ﴿٦﴾ وَنَرَاهُ قَرِيبًا ﴿٧﴾

**4) «Һичшиксез, алар аны [Коръәни Кәрим хәбәр иткән газапны] бик ерак дип күрәләр. Әмма Без аны бик якын күрәбез»;**

«Мәгариҗ / Дәрәҗә», 70:6-7

وَيَقُولُونَ مَتَىٰ هَٰذَا الْوَعْدُ إِن كُنتُمْ صَادِقِينَ ﴿٤٨﴾ مَا يَنظُرُونَ إِلَّا صَيْحَةً وَاحِدَةً تَأْخُذُهُمْ وَهُمْ يَخِصِّمُونَ ﴿٤٩﴾ فَلَا يَسْتَطِيعُونَ تَوْصِيَةً وَلَا إِلَىٰ أَهْلِهِمْ يَرْجِعُونَ ﴿٥٠﴾

**5) «Алар [сиңа һәм сәхабәләреңә]: «Әгәр, чыннан да, дөресен сөйлисез икән, ул [Кыямәт кубачагы турында] вәгъдә кайчан [булачак] соң?» – диләр. Алар бер-берләре белән сүз көрәштереп торган чакта, [сурга беренче мәртәбә өрелү белән] аларны тотып алачак көчле тавыш [белән һәлак ителүләрен] генә көтәләр. Алар васыять кылырлык хәлдә дә булмаячаклар, [өйләреннән ерак булсалар исә] гаиләләренә дә кайта алмаячаклар».**

«Йәсин», 36:48-50

2. Вәгазьнең эчтәлегенә караган хәдисләр:

1) Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килеп Кыямәт турында сорагач, ул ике бармагын күрсәткән һәм: «Кыямәт сәгате ике бармак кебек якындыр», – дип әйткән;

2) Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Кыямәт галәмәтләре килмичә, Кыямәт җитмәс»;

3) «Кыямәт алдыннан, бер елыгыз бер ай, бер аегыз бер атна, бер атнагыз бер көн, бер көнегез бер сәгать, бер сәгатегез бер мизгел кебек узар»;

4) «Кол ана, кол хатын үзенә хуҗа тудырыр»;

5) «Аллаһыдан башка һичкем белмәгән биш яшерен гыйлем бар. Кыямәтнең кайчан җитәчәген бер кеше белә алмас, аналарның карын-

нарында нәрсә бар икәнен берәү дә белә алмас. Кайчан яңгыр явачагын, кеше иртәгә нәрсә эшләячәген беркем белә алмас. Ничек, кайчан үләчәген кеше белмәс».

* * *

Көннәрдән беркөнне Мәлик бине Әнәс исемле зур бер галим, төшендә Газраил галәйһиссәламне күргән. Мәлик бине Әнәс аннан: «Йә Газраил, минем ничә ел гомерем калды?» – дип сораган. Газраил галәйһиссәлам биш бармагын күрсәткән дә, шуның белән юкка чыккан. Шуннан соң бу кеше Газраил галәйһиссәлам күрсәткән шушы биш бармакның нәрсә аңлатканын белергә теләп баш ватып утырган. Биш елмы, биш көнме, биш аймы, дип уйлаган. Зур галим булса да, барыбер төшенә алмаган. Төшне юраучы кешегә мөрәҗәгать итеп: «Менә шундый төш күрдем, нәрсәне аңлата икән ул?» – дип сораган. Ә төш юраучы: «Белүемчә, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләнең «Гыйльмүл гаиб» дип атала торган гыйлеме бар. Аны Аллаһыдан башка һичкем белми. Ә биш бармак – биш төрле яшерен гыйлемне аңлата. Аны Аллаһыдан кала сихерче дә, күрәзәче дә, җен дә, адәм дә – берсе дә белә алмый», – дип җавап кайтарган.

Кешеләр һәрвакыт Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына барып, Кыямәт турында сорый торган булганнар. Әмма моны сорауның кирәге юк, чөнки һәр кешенең үлеме җитү белән, аның Кыямәте җитә дә инде. Кешенең үлем сәгате җитте исә, шуның белән аның өчен Кыямәт тә җитте. Пәйгамбәребездән дә бу турыда сорагач, ул: «Бу гыйлем Аллаһыга гына хастыр, мин моның турыда бер әйбер дә белмим. Мин фәкать сезне җәннәт белән шатландыручы, җәһәннәм белән куркытучы, Кыямәт турында хәбәр бирүче генә. Бүтән гыйлем миндә юк», – дип әйтә торган булган. Икенче бер риваять буенча, Расүлебездән Кыямәт турында соралгач, ул ике бармагын күрсәтеп: «Кыямәт сәгате ике бармак кебек якындыр», – дип әйткән.

Мөхтәрәм җәмәгать! Шунысын белү мөһим: Аллаһының әмере булмаса, агачта бер яфрак та селкенми. Кап-караңгы төндә кара җирдә яткан орлыкның кая икәнен Аллаһы Тәгалә генә белә. Без беребез дә белә алмыйбыз. Җир йөзендә булган барлык әйберләрне дә, бөтенесен дә Аллаһы Тәгалә генә Белүче. Бу турыда «Ләүхүл-Мәхфүз (Язмыш тактасы)» китабында теркәлгән.

Йә Раббым! Шушы сөйләгәннәребез белән гамәл кылып, Синең ризалыгыңа ирешергә һәм мөэмин халәтебездә фани дөньяга күчәргә насыйп итсәң иде.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*
*МДНнең Дәгъват бүлеге белгече,*
*«Саләх» мәчете имам-хатыйбы*

# Фәтвалар

# Изге гамәлләр иманга керәме?

**Сорау: Әссәләмү галәйкүм! Изге гамәлләр иманга керәме? Намаз укымаган, ураза тотмаган кеше иманлы саналамы?**

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм! Әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать карашынча, иман – ул Аллаһы Тәгаләдән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аша китерелгәннәргә калеб белән ышану дигән сүз. Кайбер галимнәр калеб белән ышануга тел белән тәсдыйкъ итүне дә өстиләр.

Кешенең гамәлләре иманга керми. Имам Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи «Васыя»сендә болай дип әйтә:

«Гамәл – ул иман түгел, ә иман – гамәл түгел».

Галимнәр бертавыштан «гамәл» дигәндә Аллаһы Тәгалә кушкан гыйбадәтләрне (намаз, ураза) һәм Ул тыйган гамәлләрдән (шәраб эчү, зина кылу) ерак булуны күздә тоталар.

Элеккеге галимнәр иманга калеб белән ышануны да, тел белән раслауны да һәм Ислам баганаларында булган гамәлләрне кылуны да керткәннәр. Бу билгеләмә буенча гыйбадәт кылмаган кеше иманлы булмый дип аңлау тиешлеме? Юкса ул бит иманның бер өлешен төшереп калдырган була? Хариҗилар, могътәзили кебек секталар шулай уйлый да һәм намаз укымаган, ураза тотмаган кешене кяфер дип саный.

Әһле Сөннәт галимнәре һәм элекке чор галимнәр гамәлләр камил, тулы иманның бер өлеше булуына басым ясаганнар. Иманның камиллегенә гыйбадәтләр аша ирешү белән килешәбез.

Безнең галимнәр гамәлләрнең иманның бер өлеше булмавын 3 төрле алым белән дәлилилиләр:

1. Иман һәм гамәл сүзләре Коръәндә еш кына «һәм» теркәгече белән кулланыла, ә гарәп , татар һәм рус телләрендә алар икесе бер әйбер дигән сүз түгел. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Иман китерүчеләрне һәм [намаз, ураза, хаҗ, зәкят кебек Китап белән сөннәткә муафыйк] изге гамәлләр кылучыларны, аларга [сарайлары һәм агачлары] асларыннан елгалар аккан җәннәтләр белән сөендер. [Җәннәт бакчаларыннан] Нинди дә булса җимешләр бирелгән саен, алар: «Бу нәрсә безгә элек тә [дөньяда] бирелгән иде бит инде!» – диярләр. Ул [ризыклар] аларга [төсе һәм шәкеле белән генә] бер-берсенә охшаган [ләкин тәме, ләззәте белән бик нык аерыла торган] итеп бирелгән иде. Аларга анда – [хәез һәм нифас кебек матди нәҗесләрдән, бигрәк тә көнләшү, бозыклык кебек рухи кимчелекләрдән] пакь хатыннар [алар дөнья хатыннарыннан һәм хуриләрдән булыр]. Һәм алар анда мәңге калачак»;**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:25

2. Коръәндә иман изге гамәлләрнең кабул булуына бер шарт буларак искә алына. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

**«[Игелекләр кылып, яман эшләрдән ерак торган] Игелек иясе буларак үзен Аллаһыга тапшырган һәм [ялган диннәрне ташлап, хакыйкатькә юнәлгән] хәниф Ибраһим [галәйһиссәлам] диненә ияргән кешедән дә дин ягыннан яхшырак кем була ала? Аллаһы Ибраһимны [галәйһиссәлам] Үзенең дусты итте»;**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:125

3. Аллаһы Тәгалә кайбер гамәлләрне кылмаучы мөселманнарны иманлы саный:

**«Әгәр мөэминнәрдән ике төркем бер-берләре белән сугышсалар, [нәсыйхәт биреп, булса, Аллаһының хөкеменә чакырып] аларны татулаштырыгыз. Әгәр дә берсе икенчесенә карата бозыклык кылса, ул бозыклык кылучы белән Аллаһының әмеренә [һәм хөкеменә] кайтканчы сугышыгыз. Әгәр дә [сезнең белән**

**сугышуга бара алмыйча, Аллаһының әмеренә] кайтса, [сугышны туктату белән генә канәгатьләнмичә] гаделлек белән араларын татулаштырыгыз. [Кыласы һәм кире кагасы һәр очракта] Гадел булыгыз. Һичшиксез, Аллаһы гадел булганнарны сөя».**

«Әл-Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:9

Димәк, гамәлләр иманга керми, әмма иманның камиллегенә тәэсир итә. Камил иман гамәлләрсез булмый.

# Тәрбиягә алынган балага мирас бүлү

**Сорау: Әссәләмү галәйкүм! Уллыкка алу процедурасын төгәлләгән очракта, паспортка язылган балалар үги әниләре үлеменнән соң мираска ия була аламы?**

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм! Мирас бүлгәндә, Ислам буенча бары кан туганнар гына исәпкә алына. Димәк, тәрбиягә алынган балалар, кыз булсынмы, малай булсынмы, ата-ананың үз баласына әверелми. Шунлыктан, мирас бүлгәндә, аларга өлеш тими.

Әмма, мирас бүлгәннән соң, варислар тәрбиягә алынган ир яисә кыз туганнарына үз теләкләре белән өлеш чыгара ала. Аллаһы Тәгалә бу турыда Коръәндә аять тә китерә:

وَإِذَا حَضَرَ الْقِسْمَةَ أُولُو الْقُرْبَىٰ وَالْيَتَامَىٰ وَالْمَسَاكِينُ فَارْزُقُوهُم مِّنْهُ وَقُولُوا لَهُمْ قَوْلًا مَّعْرُوفًا ﴿٨﴾

**«[Мирас] Бүлешкәндә [шәригатьтә билгеләнгәнчә, мирастан өлеше булмаган] туганнар, ятимнәр һәм ярлылар шаһит булганда, аларга да аннан [ни дә булса] бирегез һәм аларга [артыгын бирә алмаган өчен, бәрәкәт догалары кушып йомшак] яхшы сүз әйтегез [ул сүзләр битәрләү һәм рәнҗетүгә кайтып калмасын]».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:8

*Булат хәзрәт Мөбарәков,*

*ТҖ МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе*

# Истинҗа

**С: Бәдрәфкә кергәндә ничек керергә кирәк?**

**Җ:** Бәдрәфкә кергәндә сул аяк белән атлап керергә, чыкканда уң аяк белән атлап чыгарга кирәк була.

**С: Хаҗәтне үтәгәндә нинди эшләр мәкруһ була?**

**Җ:** Кыйблага таба йөз яки арка белән тору, үз гаурәтеңә яки нәҗесеңә карау. Ачык җирдә булганда, кояшка яки айга таба йөз яки арка белән тору. Истибраны һәм истинҗаны уң кул белән һәм пакь сөяк, печән, кәгазь кебек нәрсәләр белән кылу. Бу югарыдагы күрсәтелгән эшләр барысы да мәкруһ була.

**С: Истибраны нинди нәрсәләр белән кылырга ярый?**

**Җ:** Таш, туфрак, ком, көл, агач, киез, мамык, чүпрәк кебек нәрсәләр белән кылу тиеш була (бүген боларның барысын да махсус бәдрәф кәгазе алыштыра, гигиена ягыннан да киңәш ителә). Ләкин су белән истинҗа кылу иң яхшысы санала.

# Госел

**С: Госел нәрсә ул?**

**Җ:** Пакь, чиста су белән коену һәм тәнне тулысынча пакьләү, юып чыгу.

**С: Госел ничек үтәлергә тиеш?**

**Җ:** Госел алу тәртибе:

1. Истинҗа кылып, гаурәтләрне пакьләргә кирәк.

2. Беләзекләргә кадәр ике кулны юарга тиешле.

3. Тәһарәт алырга кирәк, тик бу очракта аяклар юылмый, ахырга калдырыла.

4. Тәннең һәр җиренә су коеп, тидереп чыгарга кирәк.

5. Тәннең һәр җиренә бер кат су тигәч, куллар җиткәнчә, тәннең һәр җирен ышкып чыгарга кирәк.

6. Тәннең һәр җиренә икенче кат су коеп тидереп чыгарга кирәк.

7. Тәннең һәр җиренә өченче кат су коеп тидереп чыгарга кирәк.

8. Тубыкларга кадәр ике аякны юарга кирәк.

**С: Бу госел белән намаз уку дөрес буламы?**

**Җ:** Дөрес була, намаз өчен тагын өстәмә тәһарәт алып тору кирәкми.

**С: Госелнең ничә фарызы бар?**

**Җ:** Госелнең фарызлары өчәү:

1. Авыз эчен юу (чайкау).

2. Борын эчен юу.

3. Тәннең һәр җиренә су тидереп чыгу.

**С: Госелдә тәннең аз гына өлешенә су тими калса, госел тулы, камил буламы?**

**Җ:** Тәннең бармак очы кадәр җиренә су тими калса да, госел камил, тулы булмый. Шуның өчен чәч, кашлар, мыек, сакал кебек төкләргә һәм төкләрнең үскән җирләренә, шулай ук кендек эченә, истинҗа урынына, тырнак асларына, йөзекләр астына су тидерү, ул җирләрне чылатырга ти-

ешле. Ләкин хатын-кызларның чәч төпләренә генә су тисә дә, җитәрлек була, бөтенләй чәч бөртекләрен чылатмасалар да ярый.

**С: Госелнең ничә сөннәте бар?**

**Җ:** Госелнең ун сөннәте бар:

1. Гаурәтләрне юу.

2. Тәннең нәҗес тигән җирләрен юу.

3. Беләзекләргә кадәр кулларны юу.

4. Тәһарәт алу.

5. Иң беренче булып башны, аннан соң башка җирләрне юу.

6. Башта тәннең уң ягын, аннан соң сул ягын юу.

7. Беренче тапкыр тәнгә су коеп чылатканнан соң, тәнне кул җиткән өлешенә кадәр ышкып чыгу.

8. Тәннең һәр җиренә өчәр тапкыр су тидерү.

9. Суны күп түгеп, исраф итүдән саклану.

10. Госел коенган вакытта кыйблага арка белән тору.

**С: Госел нинди очракларда алына?**

**Җ:** Госелне алырга тиеш иткән өч сәбәп бар:

1. Җөнебле булу (җөнебле булуның өч сәбәбе бар: 1) ләззәт белән гаурәттән мәни килү; 2) якынлык кылу; 3) йоклаган вакытта төшләнеп мәни килү).

2. Хатын-кызларның хәез, айлык күремнәре тәмамлану.

3. Хатын-кызларның нифас, ягъни бала тапканнан соң килә торган кан килүе тәмамлану.

*«Мохтасар гыйлем хәл» китабыннан*

# Үрнәк затлар

# Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһе

Үз исеме – Әбү Габдулла Әз-Зөбәер бине Гәввам бине Хөвәйлид бине Әсәд бине Габделгоззә бине Кусай Әл-Корайши.

## Тууы

Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһе 594 елда Мәккә шәһәрендә дөньяга килгән.

## Исеме, нәселе

Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһенең нәсел чылбыры Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәселе белән тоташкан. Әтисе – Гәввам бине Хөвәйлид Корәеш кабиләсеннән, Хәдичә бине Хөвәйлид белән бертуган. Әнисе – Сафия бинте Габделмотталиб Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әтисе белән бертуган була.

Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһе җәннәт белән шатландырылган ун сәхабәнең берсе, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янындагы алты киңәшче арасында булган.

## Сыйфатлары

Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһе озын буйлы, кыска сакаллы, зәңгәр күзле кеше булган. Пакь күңелле, ачык йөзле, эшлеклелеге, мәрхәмәтлелеге белән аерылып торган.

Аның ярдәмчел булуыннан бөтен Мәдинә халкы, бигрәк тә фәкыйрьләр һәм ятимнәр канәгать булган. Хәзрәти Зөбәер бине Гәввам: «Минем янәшәдәгеләр хәерчелектән интеккәндә, минем муллыкта

яшәвемнән нинди мәгънә?» – дип бик еш кабатлаган. Шуңа да аның бөтен уйлары һәм гамәлләре башкаларга ярдәм итүдән гыйбарәт булган.

## Һиҗрәт кылуы

Беренче мөселманнар кебек үк, Зөбәер бине Гәввамга да авыр сынаулар аша үтәргә туры килгән. Алар кебек ул да диненә тугры булып, бу сынауларга нык торган. Иң элек Хәбәшигә (Эфиопия), соңыннан Мәдинәгә һиҗрәт кылган. Үзен һәм динен саклауда аңа күп көч һәм корал да кулланырга туры килгән. Бервакыт Зөбәер бине Гәввам Мәккәдә үз өендә булганда, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм кяферләр кулыннан киткән дип ишеткәч, күлмәген дә кимичә, кулына кылычын алып урамга йөгереп чыккан. Юлында ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне очраткан. Аллаһының Расүленә булган вакыйгаларны сөйләгән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аннан нәрсә эшләргә карар кылуын сораган. Зөбәер бине Гәввам: «Йә Аллаһының Расүле! Мин үзем үлгәнчегә кадәр барлык дошманнарны да юк итәр идем», – дип җавап кайтарган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аның бу җавабыннан бик канәгать калган һәм дога кылган.

## Ислам динен кабул итүе

Зөбәер бине Гәввам 16 яшендә, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе аша Ислам динен кабул итә. Моның өчен Мәккә мөшрикләре аны кыерсыталар. Ләкин шуңа да карамастан, яшьли көчле булып, дөреслеккә омтылуы белән ул үзен һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне якларга тырышкан.

Һиҗрәт кылганнан соң да, Зөбәер бине Гәввам Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм яныннан китмәгән. Бәдер, Өхед, Хөдәйбия сугышларында җаны-тәне белән көрәшкән. Үзенең кылычы белән бик

оста куллана торган булган. Тирә-яктагылар нинди яхшы кылыч дип гаҗәпләнә торган булганнар. Зөбәер бине Гәввам үзе исә: «Хикмәт кылычта түгел, батыр йөрәктә», – дип әйтә торган булган. Хәзрәти Зөбәернең кылычы чыннан да бик зиннәтле булган. Ул кыйммәтле ташлар белән бизәлгән һәм аның хакы өч мең дирһәм торган.

Зөбәер бине Гәввам Хандакъ сугышында Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең кушуы буенча дошман ягына барып, алар турында мәгълүмат туплап кайткан. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Һәрбер пәйгамбәрнең ышанычлы дусты һәм ярдәмчесе була. Миндә андый кеше – Зөбәер», – дип әйткән.

Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһе Ислам диненә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм вафат булгач та, Әбү Бәкер һәм Гомәр радыяллаһу ганһүмәләр хәлифәлек кылган вакытта  да ярдәм иткән.

## Юмартлыгы

Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһе бөтен малларын ятимнәр һәм мохтаҗлар өчен сарыф кыла торган булган. Ышанычлы кеше икәнен белеп, Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһегә сәхабәләр үз малларын әманәт итеп саклауга тапшырганнар.

Зөбәер бине Гәввам үзе исә: «Мин сезнең малыгызны әманәт итеп ала алмыйм, чөнки аның бозылуыннан куркам, шуның өчен малыгызны мин сездән бурычка алган кебек калдырыгыз, соңыннан алырсыз», – дип әйтә торган булган. Бигрәк тә Госман бине Гаффан, Габдрахман бине Гауф, Габдулла бине Мәсгуд радыяллаһу ганһүмнәр кебек олуг сәхабәләр аңа ышанычларын белдергәннәр.

## Байлыгы

Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһе байлыгы белән дә аерылып торган. Сәхабәләр арасында аның маллары, йортлары, кол хезмәтчеләре, чәчүлек кырлары белән берсе дә тиңләшерлек булмаган.

Сәүдә эшләрен дә хәзрәти Зөбәер бине Гәввам бик оста башкарган, төрле илләрдә сәүдәгәрлек иткән. Мәдинәдә – 11, Басрада – 2, Куфа һәм Мисырда берәр йортлары булган.

Хәзрәти Зөбәернең мал җыю максаты – аларны соңыннан мохтаҗларга, Аллаһы юлында тарату булган. Аның үзеннән: «Син бу байлыкны ничек җыя алдың?» – дип сорый торган булганнар. Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһе: «Мин беркайчан да беркемне алдамадым. Ялган юл белән сәүдә кылмадым. Сыйфатсыз товар белән эш итмәдем, бозылган әйберне сатмадым. Аз керем булуын белеп тә, күбрәк сатарга тырыша идем. Шуның белән малларымны арттырдым», – дип җавап кайтарган.

Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһе Ислам дине һәм мөселманнар өчен дә күп изгелекләр башкарырга тырышкан. Берьюлы ул 600 мең дирһәм садака бирсә, икенче вакытта 180 мең дирһәм тапшырган.

Бер риваятьтә китерелә: Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһенең мең колы булган. Алар хуҗасына ел саен бик зур табыш китергәннәр. Әмма хәзрәти Зөбәер шул табыштан бер дирһәмне дә үзенә тотмаган, барлык табышны да мохтаҗларга тараткан. Үзе үлгәннән соң да мирас малының $^1/_3$ өлешен мөселманнарга һәм мөселман оешмаларына васыять итеп калдырган.

## Вафаты

Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһе 656 елда (36 нчы һиҗри елда), 63 яшендә Гамре бине Җәрмүз тарафыннан үтерелә. Ул дүртенче хәлифә

булган Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһегә каршы чыгудан баш тарткан һәм Могавия бине Әби Суфиян гаскәрен ташлап киткән. Басрадан Мәдинәгә кайтыр юлда Гамре бине Җәрмүз аны куып тоткан һәм кылычы белән җәзалаган.

Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһегә Гали кәррамәллаһу вәҗһәһу җеназа намазы укыган. Хәзрәти Зөбәер бине Гәввам Басра янында дәфен кылынган.

# «Нәрсә? Кайда? Кайчан?»

# Июль

БИАда беренче 23 ислам фәннәре магистрлары укып чыкты. Аларга тантаналы рәвештә дипломнар тапшырылды. Магистр дипломнарының ияләре арасында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Буа районы имам-мөхтәсибе Илмир хәзрәт Хәсәнов та бар иде. Магистр диссертациясен Камил хәзрәт гарәп телендә «Зәйнулла ишан Рәсүлевнең дини карашлары: «Рисалә Хидрия» җыентыгына таянып» дигән темага яклады. Аның фәнни җитәкчесе – Казан ислам университетының гарәп теле һәм гуманитар фәннәр кафедрасы җитәкчесе, доцент Габдулла хәзрәт Әдһәмов булды.

РИИ һәм БИА ректорлары Мөхәммәд V университеты (Әбү-Даби шәһәре) белән хезмәттәшлек турында килешүләр имзалады. Килешүләр студентлар һәм укытучылар алмашу, уртак фәнни-дини тикшеренүләр, тел өйрәнү курсларын оештыру һ.б. буенча багланышлар алып барырга мөмкинлек бирәчәк.

Нәзарәткә төбәкләрдәге милләттәшләр өчен Коръәннең татарчага тәрҗемәләренең махсус тиражы кайтты. «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә» басмасының махсус чыгарылышы 40 000 данә гомуми тираж белән бастырылды. Аларны Рәсәйнең татарлар күпләп яшәгән төбәкләргә чыгып, тәкъдим итәргә ниятләнә.

Нәзарәттә мәетләр җирләү хезмәте эшли башлады. Әлеге хезмәт мөэмин-мөселманнарга булышу максатыннан булдырылды: биредә белгечләр халыкка тәүлек буена консультацияләр бирә, мәетне юу һәм озату мәсьәләләре буенча Казан имамнарын оештырып җибәрә, хәнәфи мәзһәбе буенча җеназа үткәрергә ярдәм итә. Ритуаль эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен, мөфтият карамагындагы хезмәттә ләхет һәм баш такталары (обелиск), кәфенлекләр, шулай ук кәфенлек җыелмасы җитештерү өчен цех булдырылды. Әлеге хезмәт тәүлек буе 8 (843) 203-57-07 телефоны буенча эшли.

# Август

Татарстанда коронавирус шартларында Корбан гаете уздырылды. Республикада махсус оештырылган 33 урында барлыгы 7827 мал (шулардан 7799 сарык һәм 28 сыер) чалынды. Шул ук вакытта, халык арасында уздырылган сораштыру нәтиҗәләре буенча, Татарстанның шәхси цехларында һәм шәхси хуҗалыкларда, ким дигәндә, тагын 27 152 мал-туар корбанга чалынды (шулардан 26 977 сарык һәм 175 сыер). Шулай итеп, 2020 елда республикада 34 979 хайван суелды (шулардан 34 776 сарык һәм 203 сыер). Мохтаҗларга исә Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фондыннан 3,5 тонна корбан ите тапшырылды. Мохтаҗлар өчен корбан итләренең аерым партиясен Халыкара Ислам бизнесы ассоциациясе (МАИБ) китерде: барлыгы 2,3 тонна күләмендәге ит (70 сарык һәм 4 сыер) Казанның сукбайлар өчен приют ихтыяҗлары өчен тотылды.

Нәзарәт Татарстанда Коръәннең 10 кыйраәте буенча белгечләр әзерләү өчен махсус төркем туплады. Дәресләргә барлык таләпләргә җавап биргән 12 хафиз сайлап алынды. Алар Коръәнне тулысы белән ятлаучылар һәм гарәп телен яхшы үзләштерүчеләр. Ун кыйраәтне өйрәнү дәресләрен алучы хафизлар арасында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да бар. Дәресләрне Казан ислам университетының Коръән-хафизлар әзерләү үзәге мөгаллиме, Татарстандагы бердәнбер ун кыйраәт белгече Раушан хәзрәт Йосыпов алып бара. Дәресләрдә «Шатыбия» китабының Казан басмасы файдаланыла. Ул Казанда 1907 елда Муса Бигиев тарафыннан басмага әзерләнә һәм бертуган Кәримовлар типографиясендә басыла. Әлеге китапның репринт басмасы укучылар өчен махсус рәвештә нәзарәтнең «Хозур» нәшриятында янәдән бастырылды.

# Сентябрь

Яңа уку елында Болгар ислам академиясенә Татарстан имам-мөгаллимнәре арасыннан 6 магистрант һәм 7 докторант укырга керде. Шул ук вакытта биредә, докторантура программасы буенча ике еллык укуларны тәмамлап, 9 докторант докторлык диссертацияләре уңышлы якланды. Алар арасында – Казан ислам университетының гарәп теле һәм гуманитар фәннәр кафедрасы өлкән мөгаллиме Алмаз Сафин. Аның докторлык диссертациясе «Мөхәммәдсадыйк хәзрәт Иманколыйның тәфсире «Тәсһил әл-бәйән фи тәфсир әл-Куръән» һәм аның ислам тәгълиматында алган урыны» темасына багышланды. Диссертация советының тавыш бирүе нәтиҗәсендә кандидатларның барысына да ислам фәннәре докторы дәрәҗәсе бирелде.

Алабугада «Ихсан» урта гомуми белем бирү мәктәбе» хосусый белем бирү учреждениесе ачылды. Әлеге белем бирү учреждениесен гамәлгә куючы – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте. Ул Алабуга мөхтәсибәте тырышлыгы белән ачылган һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан бирелгән лицензиягә ия. Биредә белем алучылар, мәктәп фәннәрен үзләштерүдән тыш, өстәмә белем бирү һәм сыйныфтан тыш эш кысаларында әдәп-әхлак дәресләрен дә ала. Дини әхлак һәм әдәп дәресләре мәктәп янәшәсендә урнашкан «Шатлык» мәчетендә татар телендә дүшәмбедән шимбәгә кадәр бер сәгать күләмендә алып барылачак. Моннан тыш, «Ихсан» мәктәбе полилингваль юнәлештә эшләячәк, биредә укучылар татар, рус, инглиз, гарәп телләрен үзләштерәчәк. Мәктәптә көненә өч тапкыр хәләл туклану, озынайтылган көн режимы каралган, спорт залы, ашханә IT-сыйныф бар.

Кукмара районының Мәчкәрә авылында республикакүләм «III Мәчкәрә укулары» фәнни-гамәли конференциясе узды. Бу елны укуларның темасы туган тел, татарның дини һәм милли үзенчәлекләрен саклап калуга багышланды, шуңа да «Милләтнең нигезе – дин һәм тел» дип исемләнде.

Конференциянең эшчәнлегендә күренекле дин һәм гыйлем әһелләре катнашты. Очрашу гадәт буенча бай тарихи һәм дини мираска ия булган Мәчкәрә авылында узды. Конференция Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мәдрәсәсе җитәкчесе Ильяс хәзрәт Җиһаншин башлангычы белән уздырыла. Аны оештыручылар – Диния нәзарәте һәм Кукмара мөхтәсибәте һәм Бөтендөнья татарлар конгрессы.

Казанның «Рәшидә» мәгариф үзәгендә Коръән тәфсирләренең татар традицияләре темасына багышланган фәнни-гамәли конференция узды. Конференция XX гасырның күренекле татар кадимчеләреннән саналган дин эшлеклесе, «Тәсһил әл-бәйән фи тәфсир әл-Куръән» («Коръән тәфсирен аңлатуны җиңеләйтү») тәфсире авторы Мөхәммәдсадыйк хәзрәт Иманколыйның (1870-1932) тууына 150 ел тулуга багышланды.

Татарстанда Диния Нәзарәте башлангычы белән гошер садакасы җыю буенча кампания игълан ителде. Традицион акция мохтаҗлар өчен азык-төлекләтә ярдәм күрсәтүгә юнәлтелгән һәм ел саен республиканың барлык мөхтәсибәтләрендә уздырылды. Былтыр татарстанлыларның активлыгы нәтиҗәсендә республика мөхтәсибәтләрендә азкеремле гаиләләр өчен 1109,5 тонна яшелчә һәм җиләк-җимеш җыеп таратылды.

«Хозур» нәшрияты легендар «Алты Бармак»китабын рус телендә бастырды. Муинуддин Мөхәммәд Әмин Хиравиның «Алты Бармак. Высочайшие достоинства Мухаммада (да благословит его Аллах и приветствует) и его пророческий путь» китабы тәүге тапкыр рус теленә тәрҗемә ителде. Әлеге китап XX гасыр башында татар имамнары арасында гына түгел, бөтен татар дөньясында киң таралган була. Ул һәрбер татар гаиләсендә өстәл китабы булып хезмәт иткән. Шуңа өстәп, мәдрәсәләрдә Аллаһы Расүленең тормыш юлы буенча уку әсбабы итеп тә кулланылган. «Алты Бармак»та Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең һәрьяклап тормыш юлы ачыла. Шулай ук китапта башка пәйгамбәрләр һәм илчеләр турында да тәфсилләп мәгълүмат бирелә.

# Тарих

# Эстония мөселманнары: татарларның төньяк Балтыйк буе илләренә Ислам динен алып килүләре

Бер уйлап караганда, Ислам дине һәм әлеге кечкенә ил арасында бернинди дә уртаклык юк сыман. Чынлыкта исә, Эстония һәм ислам илләре арасында күптәннән килгән элемтә барлыгын күрәбез. Нәкъ менә мөселманнар беренче тапкыр Җир йөзе картасында Эстония җирләрен билгеләгән. Гарәп географы Мөхәммәд Әл-Идриси (тулы исеме: Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Мөхәммәд Әл-Идриси, 1110-1166) Көнбатыш Аурупа, Төньяк Африка һәм Кече Азия буйлап сәяхәт кылган.

Ул, Сицилия патшасы Роджер II исеменнән, дөнья картасын сызып, аларда күрсәтелгән илләрнең географиясе һәм тарихы турында аңлатмалар биргән. Әлеге хезмәт «Әл-Китаб Әр-Руджжари» яки «Роджер китабы» дип атала. Биредә автор Эстония һәм Таллин (элеккеге исемнәре Колывань/Колуван, Ревель) турында мәгълүмат биргән.

Картаның тасвирламасында болай дип язылган: «Анхель – бик матур һәм чәчәк ата торган шәһәр. Ул Астланда җирләренеке. Аның шәһәрләренә тагын Колуван шәһәре дә керә. Калкансыман кыяфәттә булган әлеге шәһәр зур түгел. Халкы җир эшкәртүчеләр, аларның керемнәре аз, әмма терлекләре күп. Ул Анхельдән көньяк-көнчыгышка таба алты көн ераклыгындагы җирдә тора. Һәм, әгәр дә яр буйлап барсаң, Анхельдән 50 миль ераклыгында Берну елгасы тамагы урнашкан».

Астланда җирләре – ул Эстония, Колуван-Таллин, Берну-Пярну елгасы. Ә Анхель дигәндә, бүгенге көнге Эстониянең Ханила шәһәре күз алдында тотыла. Тарихи яктан караганда, Эстониягә Ислам динен, борынгы бабалары 922 елдан динне кабул иткән Идел болгарларыннан булган, татар халкы алып килгән. Ливон сугышы (1558–1583) вакытында, элеккеге

Казан һәм Әстерхан ханлыкларыннан булган Касыйм татарлары, хәзерге Эстония территориясендә рус гаскәрләре белән берлектә сугышырга мәҗбүр булганнар.

Татарлар еш кына әлеге территориягә ия булган Швеция ягына күченгәннәр. Соңрак бер өлеше Эстония районнарының яр буендагы урыннарыннан җирләр алган. Алга таба биредәге халык белән кушылып, аларга охшый башлаганнар.

Беренче эре ислам җәмәгатьчелеге, озак вакыт Рәсәй белән Швеция арасында дәвам иткән, Төньяк сугышыннан (1700-1721) соң оешкан. 1721 елдагы тынычлык килешүе нәтиҗәсендә Рәсәй империясенә Эстония һәм Латвия да кушыла. Рус гаскәрләре сафларында татар-мөселманнар да сугыша һәм алга таба биредә яшәргә кала.

Ул вакытларда армия хезмәте 25 елны тәшкил иткән. Күпләр үзләре белән гаиләләрен алып килгән, ә хезмәтләре төгәлләнгәннән соң бу җирләрдә бөтенләйгә яшәргә калган. Шул рәвешле, Эстониядә, ә барыннан да бигрәк Таллинда (ул вакытта Ревель дип аталган) мөселманнар тотрыклы рәвештә яши башлаган. Һәм Эстониядә нәкъ менә хәрби татар-мөселманнар беренче мөселман җәмәгатьчелегенә нигез салган.

Төньяк сугышы тәмамланганнан соң татарлар торак биналары өчен җир ала башлый. Алар тыгызлап урнашырга тырышканнар. Бу урыннарны Таллин халкы татар кварталы дип атый башлый. Иң баштан, XVIII гасырда әлеге районда татар гарнизоннарының казармалары урнашкан була. Ә бистәнең казарма урнашкан үзәк урамы Татари (Татар урамы) дип атала башлый.

Бу атама бүгенге көндә дә сакланып калган. Таллинда үзенең шәхси урамы булуы белән беркем дә: даниялеләр дә, шведлылар да, немец халкы да мактана алмый. Гәрчә алар шәһәрнең барлыкка килүе һәм үсеше өчен үз өлешләрен кертсәләр дә. Ә менә мондый хокукка ия булган татар халкының ике урамы булган: Татари һәм Уус-Татари урамнары.




Хәзер бу урын Татари микрорайоны дип атала һәм ул шәһәрнең үзәк районында урнашкан. Инде XIX гасырның азагына әлеге район шәһәрнең иң дәрәҗәле районнарының берсенә әйләнә. Бүгенге көндә Татари микрорайонында нык тормышлы шәһәр кешеләре яши. Шулай ук биредә мөһим объектлар: Эстон музыка һәм театр академиясе, «Космос» кинотеатры һәм Эстониядә АКШ илчелеге урнашкан.

# Эстония мөселманнары: татар сәүдәгәрләрен кемнәр дип уйлаганнар?



**Таллиндагы татар урамы**

Алдагы теманы дәвам иттереп, мәкалә XIX гасырда Эстониядәге татарлар тормышын яктыртуга багышлана.

Алдан билгеләп үткәнчә, 1721 елда Рәсәй белән Швеция арасында дәвам иткән Төньяк сугышыннан соң Ништад Тынычлык килешүе төзелә. Бу килешү нигезендә Эстония Рәсәй империясе составына керә. Яңа территория Эстляндия губерниясе дип атала башлый.

Таллинда (Ревель) Төньяк сугышы тәмамланганнан соң казармаларда хәрби татарларны фатирларга урнаштыру башлана. Соңрак казармадан ерак булмаган урында кайбер отставкадагы татарлар торак йортлар төзер өчен җир биләмәләре ала башлый. Бу район Татар бистәсе исемен

ала. XIX гасырда бистәнең үзәк урамы Татари – Татар урамы дип атала башлый. Бу исем бүгенге көнгә кадәр сакланып калган.

XIX гасырда ислам динен тотучы хәрбиләргә үзләренең имамнары булган гыйбадәт йортларына ия булу хокукын биргәннәр. Алдан имамнарны солдатларның үз араларыннан сайлап куйсалар, соңрак рәсми рәвештә Өфедә, Ырынбур Диния нәзарәте җыелышында билгеләп куя башлыйлар. Алар җомга һәм бәйрәм намазларын үткәрергә, мәрхүм булган мөселманнарны озатуны оештырырга һәм шулай ук башка дини ихтыяҗларны – метрика кенәгәләренә беркетеп бару мәсьәләләрен (бала туу, никахлар, үлем) канәгатьләндерергә тиеш була.

Татарларның күпчелеге Рәсәй Диңгез Флоты составына керә. Мәсәлән, Ласнамяэ Эстония хәрби-диңгезе шәһәрчегендә мөселманнарның үзләренең гыйбадәт йортлары була. Моннан тыш, мөселманнарны Таллинга һәм Палдискига авыр эшләр башкарырга җибәрә башлыйлар. Бик еш болар патша хакимиятенә каршы баш күтәргән башкорт һәм татар халкы була. Палдискидагы сөргендә башкорт батыры Салават Юлаев һәм аның әтисе Юлай Азналин гомерләренең соңгы көннәрен үткәрә.

Архивтагы чыганаклар буенча, 1834 ел белән 1862 еллар арасында Таллинда даими рәвештә 50 кеше яшәгән һәм аларның күпчелеге татар кешеләре булган. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: бу халык санын алу вакытында хәрби хезмәттә булучылар исәпкә алынмаган, шуның өчен чынлыкта мөселманнарның саны күбрәк булган. Аларның җирле халыкның кызларын кияүгә алу очракла-



**Нижгар татарлары**




ры да очрый. Таллин шәһәре архивында 1838 елда татар-мөселман кешеләре белән эстонияле хатын-кызлары арасында ике, ә 1842 елда бер никах беркетелгәне билгеле.

Татарлар тагы да күпләп Эстониягә, крепостной хокук кире кагылганнан соң, 1861 елда килә башлый. Бу вакыйгадан соң крестьян татарларының бер өлеше сәүдә белән шөгыльләнә һәм сәяхәт кылып йөрүче кайбер татарлар Эстониягә килә. Алар арбаларга утырып сәяхәт кылган рәвештә сәүдә эшләрен алып бара. Шуңа күрә дә бу татарларны ялгышып, сукбай чегәннәр дип уйлыйлар.

Соңрак дөнья гизеп йөрүче бу сәүдәгәрләр Эстониядә төпләнеп, анда үзләренең кечкенә генә кибетләрен ачып җибәрә. Бу кибетләргә килүчеләр, гадәттә, татарлар һәм калган мөселманнар була. Күпчелеген Нижгар губерниясе (хәзерге Нижгар өлкәсенең Кызыл Октябрь районы) Сергач өязенең Куй Суы (Овечий овраг) авылыннан чыккан кешеләр тәшкил итә.

Нижгар өлкәсе Кызыл Октябрь районының Куй Суы (Овечий овраг) авылына кергәндә. Нигездә, әлеге татар авылларыннан чыгучылар Таллинда сәүдә эшләре белән шөгыльләнә башлый.

*Мөхсин Нурулла язмасы,*

*islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә*

# Мирас

# Иске Таш мәчет

Яңа Татар бистәсе Казанның картасында 1749 елгы көчле янгыннан соң барлыкка килгән. Шәһәрнең күп районнары кебек үк Иске Татар бистәсе дә бу янгыннан газап чиккән. Лука Конашевич исемле рухани бу хәлне үз мәнфәгатьләрендә кулланырга теләгән. Ул янгын хәрабәләре урынына чукындырылган татарлар өчен семинария төзетә башлый. Семинария мөселманнарның җирләре белән чиктәш булган. Бу хәл мөселманнарга ошамаган. Шуңа да алар шәһәр хакимлегенә үзләрен семинариядән ераграк күчерүләрен сорап үтенеч язуы белән чыкканнар. Озакламый үтенечләрен канәгатьләндерергә дигән җавап алганнар. Мөселманнар өчен Яңа Татар бистәсе территориясе бүлеп бирелгән. Мөселманнар христианнар белән күршедәш булмасыннар өчен бу җирләрдән «Поповка» дип аталган тулы бер авылны күчергәннәр. Ә Лука Конашевичны мөселманнар белән христианнар арасында дошманлык хисен таратмасын өчен, Елизавета патшабикә махсус указ белән Казаннан читкә җибәргән.

Яңа бистәгә, нигездә, гади халык: эшчеләр, һөнәрчеләр күченгән. Алар үзләренә кечкенә агач йортлар һәм мәчетләр төзегәннәр. Укымышлылар, сәүдәгәрләр исә Иске Татар бистәсендә калуны кулайрак күргәннәр. Архитектура һәйкәле буларак әһәмиятлелеге ягыннан Яңа Татар бистәсе Иске Татар бистәсеннән күпкә калыша. Алай да Яңа Татар бистәсендә күренекле биналар бар. Ике таш мәчет әнә шундыйлар мисалыннан. Аларның берсе – Иске Таш мәчет.

Иске Таш мәчетне кайчагында «Тугызынчы җәмигъ мәчет» дип тә атыйлар.

Яңа Татар бистәсенең беренче мәхәлләсе белән берүк вакытта икенче мәхәллә дә барлыкка килгән. Әлеге мәхәллә бистәнең көнчыгыш ягындагы Эш урамының, төньяк яктагы Камил Ягъкуб урамының, көнбатыштагы

Татарстан һәм көньяктагы Меховщиклар урамы мөселманнарын берләштерә. Шулай ук монда XIX гасырда агач мәчет булган. Шул мәчет урынына 1802 елда Малмыж өязенең беренче гильдия сәүдәгәре Габдулла Үтәмешев ике катлы мәчет (хәзерге М. Гафури урамы, 34а бинасы) төзетә.

Габдулла Габделсәлам улы Үтәмешев (1832 елда вафат) – атаклы сәүдәгәрләр нәселенә нигез салучы, чыгышы белән Вятка губернасы Малмыж өязенең Мәчкәрә авылыннан (Татарстанның хәзерге Кукмара районына керә). Ул Рәсәйнең күп кенә татар авылларында дистәләрчә мәчет төзетә, дин мәсьәләләре буенча берничә китап яза, чорының укымышлы кешесе буларак абруй казана. Күренекле галимебез Ш. Мәрҗани сүзләреннән күренгәнчә, Габдулла Үтәмешев түбәндәге сыйфатларга ия булган: «Беркем үзенең байлыгы һәм юмартлыгы белән дә аның белән тиңләшә алмаган. Шуның өстенә ул тәкъвалыгы, мәгариф һәм фән сөюче булуы белән аерылып торган».

Габдулла Үтәмешевнең хатыны – күренекле фикер иясе һәм дин белгече Габденнасыйр Курсавиның бертуган сеңлесе була. Уллары: Исмәгыйль – күренекле дин белгече, Ибраһим һәм Исхак – бистәдә үз эшләрен җәелдергән күренекле сәүдәгәрләр. Мөхәммәдгариф исемле оныгы бистәдә «Утямышев и Ко» дип аталган Казан мануфактурасына нигез салган, XX гасыр башында бәз буйый торган фабрика һәм Казандагы иң эре сәнәгать оешмасы саналган сабын кайнату эшчәнлеген башлап җибәргән. Исмәгыйль исемле оныкчыгы шәһәр Думасы әгъзасы булган.

Риваятьләрдән күренгәнчә, Иске Таш мәчет 1552 елда Казанны Явыз Иван гаскәрләреннән саклаган солдатларның туганнар каберлеге өстенә төзелгән. Элегрәк бу урында таш торган һәм мәчетнең исеме дә шуңа бәйле дип фаразлана.

Бу мәчетнең тарихына бәйле икенче риваять тә бар. Бу риваятьтән аңлашылганча, мәчет урынында Пугачев восстаниясендә актив катнашкан Яңа Татар бистәсе кешеләре күмелгән. Бинаны төзегән вакытта

төзүчеләр Казанның җимерелгән борынгы бер мәчетенең ташын кулланганнар дигән риваять тә бар. Ләкин ул урында археологик казу эшләре үткәрелмәгәнгә бу фикерне төгәл дип әйтеп булмый.

1830-1840 елларда мәчетнең архитектурасына кайбер үзгәрешләр кертелгән һәм киңәйтелгән (архитекторы А. К. Шмидт).

Мәхәлләнең иң тәүге имамнарының берсе булып Фазыл Сәйфетдинов (1812 елда вафат) билгеләнә. Аның урынына 1813 елда Талкыш авылы (Татарстанның хәзерге Чистай районына керә) кешесе Әмирхан бине Габделмәннан (1828 елда вафат) килә. Ул Сасна һәм Мәчкәрә авылларының мәдрәсәләрендә укый, шулай ук Бохарада да белем ала; Казанга күчеп килгәнче Казан өязе авылларында мулла булып тора. Әмирхан хәзрәтнең вафатыннан соң мәхәллә башлыгы итеп Ф. Сәйфетдиновның улы Мөхәммәтвафа (1848 елда вафат) билгеләнә. Ул бу хезмәттә 1838 елга кадәр – Оренбургтагы Диния нәзарәтенең казые булып сайлану сәбәпле Казаннан киткәнче эшли. 1838-1848 елларда имам вазифаларын Байморат Мөхәррәмов башкара. Чыгышы белән ул Олы Мәңгәр авылында (Татарстанның хәзерге Әтнә районына керә) яшәүче өченче гильдия сәүдәгәре гаиләсеннән була, үзе дә эшкуарлык белән шөгыльләнә, Печән базарында сәүдә итә, мәхәлләдә мәдрәсә тота, әсәрләр яза. Соңгылары, Ш. Мәрҗани бәяләве буенча, мәгънә тирәнлегенә һәм әһәмияткә ия булмый. 1847 елда мәчетнең имам-хатыйбы итеп Әмирхан бине Габделмәннанның улы Хөсәен (1816-1893) сайлана. Ул Чистай, Казан, Мәчкәрә һәм Бохара мәдрәсәләрендә белем ала, заманының атаклы галиме булып җитешә. Хөсәен хәзрәт, күп кенә тарихи чыганакларны өйрәнеп, төрки халыклар тарихы буенча хезмәтләр яза.

Аның «Тәварихе Болгария» (1883) һәм «Бөек шәҗәрә, яки нәселләр бәяны» (1884) кебек әсәрләре бүген дә әһәмиятләрен югалтмадылар. 1889 елда Х. Әмирхан рухани хезмәтен калдыра. Аның урынына бер-бер артлы уллары Мөхәммәтнәҗип (1859-1921) һәм Мөхәммәтзариф (1853-

1921) Әмирхановлар билгеләнәләр. Мөхәммәтнәҗип имам булып озак эшләми, Чистайга китеп, андагы Беренче җәмигъ мәчетен җитәкли; Мөхәммәтзариф 1875 елдан мәхәлләнең икенче мулла вазифаларын башкара һәм тиздән Казан мөселманнарының абруйлы җитәкчесенә әверелә. Ул мәдрәсәләрдә алдынгы ысуллар белән укыту хакында дәреслекләр иҗат итә. Иске Таш мәчеттә аңа ярдәмче итеп 1893 елда Казанның мактаулы гражданы Мөхәммәтсадыйк Шаһиәхмәт улы Иманколов (1870-1932) сайлана. Соңгысы исә 1886-1893 елларда Бохарада укып кайта, Казанда дини эчтәлекле шигырьләр авторы буларак таныла. Мөхәммәтзариф Әмирхан гаиләсендә танылган татар әдибе Фатих Әмирхан дөньяга килә.

Казанның Олы һәм Кече Сембер урамнарының шактый өлешен биләгән тугызынчы мәхәллә шәһәрдә иң олысы була. XX гасыр башында аның карамагында ир-ат затыннан 1260 кеше исәпләнә. Мәхәллә халкын нигездә гади халык тәшкил иткән, чөнки Яңа Татар бистәсе шәһәрнең һөнәри үзәге булган. Әгәр чагыштырып карасак, Мәрҗани мәчетенең мәхәлләсендә бары тик 300-400 кеше генә исәпләнгән. Мәчет каршында заманында мөселманнарның уку йорты буларак танылган «Әмирхания» мәдрәсәсе эшләгән. Ел саен анда 80ләп шәкерт укыган. XIX гасыр ахырында атаклы татар әдибе һәм җәмәгать эшлеклесе Г. Исхакый анда дәресләр биргән.

Совет заманында мәчет ябыла. Аның бинасында мәктәп эшли башлый. Мәчет янында зуррак мәктәп төзелгәч, ул мәктәп складлары булдырылып кулланыла. Бары тик 1994 елда гына мәчет яңадан мөселманнарга кайтарыла.

*«Татарстан Җөмһүрияте: татар халкының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре» китабыннан, «Фест» нәшрияты, 1995 ел*

# Тәфсир

# Муса галәйһиссәлам кыйссасы

## «Фиргавенгә бар – ул рөхсәт ителгәннәрнең чиген үтеп китте»

Фиргавен һәм аның халкы имансызлык һәм явызлыкта үҗәтлек күрсәтеп тормыш иткәндә, кешеләрне золым һәм явызлыктан аралап алу, Аннан башка чын илаһ юклыгын исләренә төшерү, Исраил угыллары коллыктан азат итү, аларны хак дингә күндерү өчен Аллаһы Тәгалә Муса галәйһиссәламгә пәйгамбәрлек ирештерә. Ул аңа болай дип әйтә:

اذْهَبْ إِلَىٰ فِرْعَوْنَ إِنَّهُ طَغَىٰ ﴿٢٤﴾

**«[Менә бу ике могҗиза белән] Фиргавенгә бар [да, аны Миңа коллыкка дәгъват ит]. Һичшиксез, ул [үзен Раббы дәрәҗәсенә куеп] азынды».**

«Та Һа», 20:24

Муса галәйһиссәлам пәйгамбәр итеп бар халыкка җибәрелсә дә, аңа иң элек фиргавенгә барырга дигән әмер бирелгән була, чөнки ул үз халкының башлыгы, әгәр дә ул иманга килсә, бар халык та иманга килергә тиеш була.

Фиргавенгә барганчы Муса галәйһиссәлам Аллаһыдан үзенең бертуган абыйсы Һарунны ярдәмче иптәш итеп бергә җибәрүен сорый.

Ике бертуган арасында иң тәкъвалысы Муса галәйһиссәлам була. Абыйсы энесенә дөнья мәшәкатьләрендә ярдәмче, теләсә нинди дөнья байлыкларына ирешкәндә арадашчы була ала, тик бернинди туган да беркемгә дә пәйгамбәр булырга ярдәм итә алмый. Шулай да Муса галәйһиссәлам шуны сорап дога кыла һәм ул дога кабул ителеп, аның бертуганына пәйгамбәрлек ирештерелә.

Доганың кабул ителүе һәм Һарун галәйһиссәламгә пәйгамбәрлек ирештерелүе турында Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

قَالَ قَدْ أُوتِيتَ سُؤْلَكَ يَا مُوسَىٰ ﴿٣٦﴾

**«Ий Муса! Сораганнарың сиңа бирелде инде»;**

«Та Һа», 20:36

وَاصْطَنَعْتُكَ لِنَفْسِي ﴿٤١﴾ اذْهَبْ أَنتَ وَأَخُوكَ بِآيَاتِي وَلَا تَنِيَا فِي ذِكْرِي ﴿٤٢﴾

**«Мин сине Үзем өчен сайладым. Син һәм кардәшең [сезгә бирелгән могҗиза һәм] аятьләрем белән барыгыз. Әмма зикерем хосусында йомшаклык күрсәтмәгез».**

«Та Һа», 20:41-42

Аллаһы Тәгаләнең шул әмерен үтәп, Муса галәйһиссәлам һәм Һарун галәйһиссәлам фиргавен сараена бара. Ишек шакыган вакытта сарай әһелләре кәеф-сафа корып, күңел ачып яткан була. Муса галәйһиссәлам һәм Һарун галәйһиссәламне фиргавен янына алып керәләр.

Муса галәйһиссәлам: «Ий фиргавен! Хактыр ки, мин – дөньялар Раббысының сиңа җибәрелгән расүлемен. Иманга кил, хак юлга кер һәм котылып кал! Әгәр дә иманга килмәсәң, Исраил угылларын булса да азат ит. Һәм миңа алар белән Фәләстыйнга, аларның ата-бабалары җиренә кире кайтырга рөхсәт ит, аларга явызлык кылма!» – дип әйтә.

Ул тагын үзенең пәйгамбәрлеген раслый торган могҗизалар белән килүен дә әйтә. Моңа җавап итеп фиргавен: «Әгәр дә син могҗизалар белән килгәнсең икән, аларны күрсәт», – ди.

Шуннан соң Муса галәйһиссәлам кулындагы таякны идәнгә ташлый. Ул таяк бик зур еланга әйләнә, моны барысы да күрә. Елан бик зур ерткыч

хайванга яки аждаһага охшаган була. Таякның Муса галәйһиссәлам кулы белән тоткан урыны ул аждаһаның ялына әйләнә, ә ул ялның һәр кылы – сөңге кадәр иде. Бу ерткыч – буаз дөя зурлыгында булып, бик зур ташларны да кабып йотарлык хәлдә була. Елан авызын ачкан вакытта башының ас өлеше сарай идәненә тиеп торса, өске өлеше – түшәмгә тия яза. Аны күргәч, кешеләрнең коты оча, алар куркып чыгып чабалар. Берничә кеше тапталып үлә. Шулай ук фиргавен үзе дә бик нык куркуга кала. Аннары Изге Китабыбызда:

وَنَزَعَ يَدَهُۥ فَإِذَا هِيَ بَيْضَآءُ لِلنَّٰظِرِينَ ﴿٣٣﴾

**«Янә кулын [куеныннан] чыгарды, кинәт ул караучылар өчен [гадәттән тыш нурлар чәчеп, күзләрне камаштырган һәм офыкны каплаган] ап-ак иде»,** – дип әйтелә.

«Әш-Шүгәра / Шагыйрьләр», 26:33

Муса галәйһиссәлам кулын култык астыннан тартып чыгаргач аның бу кулы бер нур сибеп, барысын да яктыртып тора башлый. Бу яктылыктан кешеләрнең күзләре камаша. Фиргавен һәм аның якыннары нык куркуга калалар, алар Муса галәйһиссәламне ялганчы дип атыйлар һәм сихерчелектә гаеплиләр:

قَالَ لِلْمَلَإِ حَوْلَهُۥٓ إِنَّ هَٰذَا لَسَٰحِرٌ عَلِيمٌ ﴿٣٤﴾ يُرِيدُ أَن يُخْرِجَكُم مِّنْ أَرْضِكُم بِسِحْرِهِۦ فَمَاذَا تَأْمُرُونَ ﴿٣٥﴾

**«Һичшиксез, бу – [сихер гыйлемендә иң югары ноктага ирешкән] бик белемле сихерче. Ул сезне [Мисырда яшәп яткан] туфрагыгыздан сихере белән чыгарырга тели. [Аңа карата ничек кылануым кирәклеге хакында миңа] Нәрсә әмер итәсез?»**

«Әш-Шүгәра / Шагыйрьләр», 26:34-35

## Муса галәйһиссәламнең сихерчеләр белән очрашуы

Фиргавен Муса галәйһиссәламне сихерчелектә гаепләп, шул ук коралны – сихерне кулланып аны җиңмәкче була. Муса галәйһиссәламнең кешеләр арасында абруен төшереп, үз хакимлеген ныгыту өчен фиргавен Мисырның бар сихерчеләрен җыярга әмер бирә. Моның өчен илнең бар тарафларына сөрәнчеләр җибәрелә.

Игъланны ишеткәч, Мисырның бар җирләреннән дә башкалага сихер белән эш итә белүчеләр җыела. Иң оста, иң булдыклы сихерчеләрнең барысын да җыялар.

Башкалада өч мең тирәсе тылсымчы җыела. Икенче бер риваятьтә унбиш меңгә кадәр диелә. Ничек кенә булмасын, аларның тулы бер гаскәре җыелды дип әйтергә була.

فَلَمَّا جَاءَ السَّحَرَةُ قَالُوا لِفِرْعَوْنَ أَئِنَّ لَنَا لَأَجْرًا إِن كُنَّا نَحْنُ الْغَالِبِينَ ﴿٤١﴾
قَالَ نَعَمْ وَإِنَّكُمْ إِذًا لَّمِنَ الْمُقَرَّبِينَ ﴿٤٢﴾

**«Сихерчеләр фиргавенгә килгәч: «Әгәр дә без җиңүчеләр булсак, безгә бер түләү булырмы?» – диделәр. Ул: «Әйе! Ул тәкъдирдә сез [түләү алу белән генә калмыйча, хозурыма иң алдан кергән һәм иң соңыннан чыккан] якын ителгәннәрдән булачаксыз», – диде».**

«Әш-Шүгәра / Шагыйрьләр», 26:41-42

Аннан алдарак, кемгә каршы ярыш булачагын белү өчен, сихерчеләр Муса галәйһиссәлам белән очрашалар. Муса галәйһиссәлам:

– Мин сихерче түгел, ә Аллаһының Расүле. Мин сезне иман китерергә өндим, – дип аларны хак дингә чакыра.

Аңа җавап итеп сихерчеләр болай дип әйтә:

– Синең пәйгамбәрме әллә сихерчеме икәнлегеңне без очрашуда белербез. Әгәр дә син үзең әйткән кеше булсаң – яхшы, ә әгәр дә бу алай булмаса, син безнең ни эшләгәнне күрерсең әле.

Очрашу көне килеп җитә. Кешеләр төркем-төркем булып шәһәр читендәге зур кырга агылалар. Фиргавен өчен тәхет эшләп куелган була, ул шул тәхетеннән тамашаны манзара кыла. Сихерчеләр бауларын, арканнарын, тиредән эшләнгән юан каеш бәйләрен тотып үзләренең осталыкларын күрсәтергә әзерләнәләр. Аларның эче куыш һәм анда терекөмеш тутырылган таяклары да була.

Менә инде барысы да көткән кеше үзе килеп җитә. Муса галәйһиссәламнең кулында таяк була, аның янәшәсенә Һарун галәйһиссәлам дә килә. Алар унбиш мең сихерчегә икәү генә каршы торалар, ләкин алар икесе дә Аллаһы бәндәләре була.

Әлбәттә, мондый хәл сихерчеләргә нык тәэсир итә. Әгәр нур сибә алучы бу кешенең максаты акча, җәмгыятьтә тоткан урын, хакимлек булса, ул фиргавен янына килеп аның белән килешеп үзе теләгәнне бик җиңел ала алган булыр иде, фиргавенгә бу кадәр халыкка акча түләп торырга туры килмәс иде, димәк, бу кеше дөнья байлыкларына омтылмый, дип аек акыл белән фикерлиләр алар. Аннан тыш, ул фиргавеннең үзе белән үк алышка чыккан икән, мондый алыш буш һәм нигезсез түгел инде. Ә бит фиргавен зур хакимлеккә ия, аның каршында бар кешеләр дә калтырап торалар, дигән уйлар да башларына килә башлый. Шулай итеп, сихерчеләр: «Ярышны башлыйк, бу кешенең чынлап та кем икәнлеген шунда күрербез», – диләр.

Сихерчеләр болай дип әйтәләр:

قَالُوا يَا مُوسَىٰٓ إِمَّآ أَن تُلْقِيَ وَإِمَّآ أَن نَّكُونَ أَوَّلَ مَنْ أَلْقَىٰ ﴿٦٥﴾

**«Ий Муса, әүвәл син ташлыйсыңмы таягыңны яки әүвәл без ташлыйкмы?»**

«Та Һа», 20:65

Ә Муса галәйһиссәлам:

قَالَ بَلْ أَلْقُوا ۖ فَإِذَا حِبَالُهُمْ وَعِصِيُّهُمْ يُخَيَّلُ إِلَيْهِ مِن سِحْرِهِمْ أَنَّهَا تَسْعَىٰ ﴿٦٦﴾

**«Юк, [мин алдан ыргытмыйм] сез ыргытыгыз», – диде. [Алар һөнәрләрен күрсәткәч] Сихерләре сәбәпле [гүя] җепләре вә таяклары аңа [чын еланнар булып] хәрәкәтләнгән кебек күренде».**

«Та Һа», 20:66

Муса галәйһиссәлам: «Таякларыгызны сез ташлагыз», – дигәч, сихерчеләр үзләре әзерләп килгән әйберләрен җиргә ташлыйлар. Аларның тиредән эшләнеп тышы майланган баулары кояшта ялтырый башлый, эченә терекөмеш тутырылган таяклары хәрәкәтләнә башлаган кебек тоела. Халыкка хәрәкәтләнеп, шуышып йөргән меңләгән еланнар белән бар кыр тулган кебек күренә башлый. Ярышны карарга килгән кешеләрнең коты алына. Моны күргәч Муса галәйһиссәламне дә эчтән курку биләп ала:

فَأَوْجَسَ فِي نَفْسِهِ خِيفَةً مُّوسَىٰ ﴿٦٧﴾ قُلْنَا لَا تَخَفْ إِنَّكَ أَنتَ الْأَعْلَىٰ ﴿٦٨﴾

**«Муса күңелендә бер курку сизде. Без әйттек: «[Аларның сиңа бер зарар китерәчәге яки кешеләрнең шикләнеп сиңа иярмәячәкләре кебек уйларга бирелеп] Курыкма! Һичшиксез, син өстен чыгачаксың».**

«Та Һа», 20:67-68

Муса галәйһиссәлам: «Кешеләр могҗизаны күргәч, аның мөмкинлекләрен арттырып кабул итәрләр һәм иманга килмәсләр», – дип курка.

Аллаһы Тәгалә аның бу сүзләренә каршы Муса галәйһиссәламгә болай дип әйтә:

وَأَلْقِ مَا فِي يَمِينِكَ تَلْقَفْ مَا صَنَعُوا ۖ إِنَّمَا صَنَعُوا كَيْدُ سَاحِرٍ ۖ وَلَا يُفْلِحُ السَّاحِرُ حَيْثُ أَتَىٰ ﴿٦٩﴾

**«[Алар күрсәткән моның кадәр бауларны, арканнарны һәм шуышкан елан шикелле күренгән терекөмешле буялган әйберләрне һич игътибарга алма!] Уң кулыңдагыны [кечкенә булып күренгән таягыңны җиргә] ташла, алар ясаган нәрсәләрнең бөтенесен [Минем кодрәтем белән] йотып бетерсен. Алар ясаган ул әйберләр, һичшиксез, сихерче хәйләсе. Сихерче исә кая барса [һәм ни кылса] да, уңышка ирешмәс».**

«Та Һа», 20:69

Муса галәйһиссәламнең җиргә ташланган таягы исә бик зур еланга әйләнә, ул аждаһа сихерчеләрнең җиргә ташлаган бар әйберләрен дә кабып йота. Тузан суыргыч келәмдәге бар тузанны суырып бетергән кебек, ярыш оештырылган кыр да бер мизгелдә бар сихердән арынып кала.

## Сихерчеләрнең дине һәм аларның һәлак булуы

Муса галәйһиссәламнең могҗизасын күргәч, сихерчеләр башларын җиргә орып болай дип әйтәләр:

آمَنَّا بِرَبِّ هَارُونَ وَمُوسَىٰ ﴿٧٠﴾

**«Без Һарун белән Мусаның Раббысына иман китердек».**

«Та Һа», 20:70

Ә фиргавеннең моңа бик ачуы чыга һәм:

قَالَ آمَنتُمْ لَهُ قَبْلَ أَنْ آذَنَ لَكُمْ ۖ إِنَّهُ لَكَبِيرُكُمُ الَّذِي عَلَّمَكُمُ السِّحْرَ ۖ فَلَأُقَطِّعَنَّ أَيْدِيَكُمْ وَأَرْجُلَكُم مِّنْ خِلَافٍ وَلَأُصَلِّبَنَّكُمْ فِي جُذُوعِ النَّخْلِ وَلَتَعْلَمُنَّ أَيُّنَا أَشَدُّ عَذَابًا وَأَبْقَىٰ ﴿٧١﴾

**«[Димәк] Мин сезгә рөхсәт бирүдән алда сез аңа иман китердегез! Һичшиксез, ул [Муса] – сезгә бу сихерне өйрәткән сезнең башлыгыгыз. [Сез бу эшне үзара аңлашып, аннан кечерәк сихерләр ясадыгыз, ул исә, сездән өстенлеген күрсәтеп, сезне җинде] Мин сезнең кулларыгызны һәм аякларыгызны [уң кул, сул аяк шәкелендә] чалыштырып чабып өзәчәкмен, шуннан соң сезне хөрмә кәүсәсенә кагып куячакмын. Менә шулвакыт кайсыбызның [минемме, Мусаның илаһыныңмы] көчлерәк һәм дәвамлырак икәнен белерсез»,** – дип әйтә.

«Та Һа», 20:71

Ләкин иман китергән сихерчеләр бу янауларга һич тә игътибар итмиләр һәм фиргавенгә болай дип әйтәләр:

قَالُوا لَن نُّؤْثِرَكَ عَلَىٰ مَا جَاءَنَا مِنَ الْبَيِّنَاتِ وَالَّذِي فَطَرَنَا ۖ فَاقْضِ مَا أَنتَ قَاضٍ ۖ إِنَّمَا تَقْضِي هَٰذِهِ الْحَيَاةَ الدُّنْيَا ﴿٧٢﴾ إِنَّا آمَنَّا بِرَبِّنَا لِيَغْفِرَ لَنَا خَطَايَانَا وَمَا أَكْرَهْتَنَا عَلَيْهِ مِنَ السِّحْرِ ۗ وَاللَّهُ خَيْرٌ وَأَبْقَىٰ ﴿٧٣﴾

**«Әйттеләр: «Безгә килгән ачык могҗизаларга һәм безне юктан бар кылган Ул Затка каршы сине сайламаячакбыз. Син карар биргән нәрсәңә хөкем ит. Син дөнья тормышында гына хөкем итәсең. [Синең көчең бу фани дөньяда гына бар, бик тиздән ул юкка чыгачак] Һичшиксез, без хаталарыбызны һәм синең безне көчләп кылдырган сихерчелегең өчен безне гафу итсен дип,**

**Раббыбызга иман китердек. Аллаһы яхшырак, [савап ягыннан да, газап ягыннан да] дәвамлырак».**

«Та Һа», 20:72-73

Кан коюдан беркайчан да чирканмаган фиргавен, сихерчеләрнең кул-аякларын чабып өзәргә һәм аларны тәрегә кадакларга боера. Бу сихерчеләрнең исламдагы хәле, чыннан да, гаҗәеп. Әле иртән генә алар имансыз иделәр, ә кичкә инде исламның шәһитләре булалар. Бер көннән азрак кына мөэмин булып яшәсәләр дә, алар иманда камиллеккә ирешеп, үз тормышларын дин юлында корбан итәләр.

Муса галәйһиссәлам халкы фиргавеннең сихерчеләр белән ни кылганын, аларның кул-аякларын чабып өзеп, тәрегә кадаклап үтерергә боерганын күргәч, ул безнең белән дә шуны эшләргә мөмкин бит дип куркуга кала. Муса галәйһиссәлам аларга:

قَالَ مُوسَىٰ لِقَوْمِهِ اسْتَعِينُوا بِاللَّهِ وَاصْبِرُوا ۖ إِنَّ الْأَرْضَ لِلَّهِ يُورِثُهَا مَن يَشَاءُ مِنْ عِبَادِهِ ۖ وَالْعَاقِبَةُ لِلْمُتَّقِينَ ﴿١٢٨﴾

**«Аллаһыдан ярдәм сорагыз һәм [дошманнарыгызның җәфалавына һәм үзегез хакында ишеткән нигезсез сүзләргә карата] сабыр булыгыз. Һичшиксез, [бөтен] җир [йөзе] Аллаһыныкы гына. Ул колларыннан теләгәннәрен аңа варис итәр. [Хәерле] Ахыр исә тәкъва ияләренә [булачак, шуңа күрә фиргавеннең уйдырып сөйләгәннәренә ышанмагыз, ул әйткәнчә булмас, Аллаһы боерганча булыр]».**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:128

## Фиргавен һәм аның халкына галәмәт итеп җибәрелгән афәтләр

Иманга килсеннәр өчен Аллаһы Тәгалә фиргавен һәм аның халкына бер-бер артлы төрле афәтләр җибәрә. Башта сигез көн буе бертуктамый яңгыр коя. Беркем дә өеннән чыга алмый. Су шулкадәр күтәрелә ки, хәтта кешеләр өйләрендә муеннан суга батып йөрергә мәҗбүр булалар. Ләкин Исраил угылларының өйләренә су кагылмый. Шулай итеп җиде көн буе Мисыр диңгез кебек була.

Тулысынча суга батудан куркып, фиргавен халкы Муса галәйһиссәламгә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була. Алар:

– Раббыңа дога кыл безне бу афәттән коткарсын, шунда без иман китерербез, – дип әйтәләр.

Муса галәйһиссәлам дога кыла һәм бу афәт бетерелә. Тик бу вакыйгадан соң үсемлекләр шаулап үсә башлый. Моңа кадәр андый бәрәкәтне күрмәгән халык иманга килүдән баш тарта:

– Без курыккан афәт куркыныч булмаган икән, киресенчә, бәрәкәт китерде, – диләр.

Шуннан соң Аллаһы Тәгалә аларга саранча өере җибәрә. Саранчалар өере бөтен уңышны ашап бетерә яза, кешеләрнең өйләренә кереп тула. Мондый казага тарыган фиргавен халкы, шул ук сүзләр белән, Муса галәйһиссәламгә тагын мөрәҗәгать итә:

– Раббыңа дога укы, безне бу афәттән коткарсын, шунда без иман китерербез, – дип әйтәләр.

Муса галәйһиссәлам дога кылгач, Аллаһы Тәгалә җибәргән җил бөтен саранчаны диңгезгә алып китә. Калган уңышның аларга яшәргә җиткәнен күргәч, фиргавен халкы:

– Уңышның калганы безгә җитәчәк, – дип иман китерүдән тагын баш тарта.

Шуннан соң Аллаһы Тәгалә аларга бет һәм башка бөҗәкләр җибәрә. Бу бөҗәкләр уңышның саранчалардан калган өлешен ашап бетерә башлыйлар, бетләр кешеләрне тешләп каннарын эчәләр. Шунда кешеләр өченче тапкыр Муса галәйһиссәламгә киләләр һәм аларны бу бәладән коткаруын сорап, иман китерергә вәгъдә итәләр. Аллаһы Тәгалә аларны бу бәла-казалардан да азат итә. Ләкин бу кешеләрне тагын иманга китерми:

– Хәзер инде синең сихерче булуыңда безнең бернинди дә шигебез калмады, – дип әйтәләр.

Болардан соң кара болыт килеп, ул болыттан җиргә күл бакалары һәм гөберле бакалар ява башлый. Алар кешеләрнең башларына төшә, өйләренә кереп тула, бөтен җир бакалар белән түшәлеп бетә. Бар ризык һәм су савытлары да бакалар белән тулган була. Бераз вакыттан соң бөтен җир бакаларның үле гәүдәләре белән түшәлә, алардан сасы ис таралып, суларга һава калмый. Кыптыйлар тагын Муса галәйһиссәламгә килеп, ярдәм сорап ялвара башлыйлар. Муса галәйһиссәлам иманга килергә дип алардан ныклы вәгъдә алып, Аллаһыга ялварып дога кыла. Әлеге дога аркасында фиргавен халкы бу бәлаләрдән дә азат ителә. Аллаһы Тәгалә җибәргән яңгыр бөтен бакаларны да диңгезгә юып төшерә.

Әмма фиргавен халкы бу юлы да иманга килми. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә яңа афәт җибәрә. Ул – канлы су була. Елгалардагы, чишмә-инешләрдәге сулар, аларның бар эчемлекләре канга әйләнә. Вәгъдәсен күп тапкырлар бозган бу халык тагын Муса галәйһиссәламгә килә, аларны бу бәладан коткаруны сорап, елый-елый ялвара. Муса галәйһиссәламнең догасы аркасында алар бу афәттән дә азат ителәләр.

Бу афәтләрнең һәрберсе Муса галәйһиссәламнең хаклыгын раслый торган ачык галәмәт була. Фиргавен халкы туктаусыз һәлакәткә баруын һәм аннан котылу өчен тиз арада иман китерергә кирәклеген аңлаткан гыйбрәтле бу галәмәтләр Аллаһының кодрәте белән башкарыла. Ләкин,

шуңа да карамастан, бу халык тәкәбберләнә, иманга килми. Һәм алар һәр очракта да вәгъдәләрен бозалар, сүзләрендә тормыйлар.

Менә никадәр әхлаксыз була бу халык. Аллаһыга һәм Аның расүленә биргән вәгъдәләрен берничә тапкыр бозганнары өчен бу халык юкка чыгуга дучар була.

## Исраил угылларының Мисырдан китүе

Аллаһы Тәгалә Муса галәйһиссәлам һәм аның халкын фиргавен золымыннан тулысынча азат итәргә карар иткәч, вәхи вакытында аңа болай дип әйтә:

وَأَوْحَيْنَا إِلَىٰ مُوسَىٰ أَنْ أَسْرِ بِعِبَادِي إِنَّكُم مُّتَّبَعُونَ ﴿٥٢﴾

**«Без Муса галәйһиссәламгә: «[Сиңа иман китергән] Колларымны төнлә йөрт [Мисырдан алып кит!] Һичшиксез, [фиргавен һәм аның гаскәрләре] сезнең эзегезгә төшәчәкләр», – дип вәхи иттек».**

«Әш-Шүгәра / Шагыйрьләр», 26:52

Муса галәйһиссәлам Исраил угылларына кыптыйлардан, туй үткәрәбез дигән сылтау белән, зәркән (ювелир) әйберләр алып торырга әмер бирә. Аннары, беркемгә дә әйтми, төн караңгылыгында Мисырдан чыгып китәргә куша. Аннан тыш, ул өйләрдә янып торган лампалар калдырырга һәм өйнең хуҗасы чыгып киткәне аңлашылсын өчен аларның ишекләрендә кан белән тамга куярга да куша.

Һәм менә, картлар һәм балаларны исәпләмәгәндә, алты йөз егерме мең санлы Исраил угылы юлга чыга. Һарун галәйһиссәлам алдан, ә Муса галәйһиссәлам – иң соңгы кеше булып бара.

## Фиргавеннең үлеме

Әлбәттә, Исраил угылларының китүе билгеле булгач, фиргавен шундук гаскәр җыя һәм алар артыннан куып китә. Фиргавен һәм аның баш вәзире Хаман җиде йөз меңлек гаскәрнең башында тора. Һәр яугирнең башында махсус баш киеме (шлем), кулларында сөңге була. Кояш чыкканда фиргавен үзенең гаскәрләре белән Муса галәйһиссәлам халкы янына килеп җитә. Фиргавенгә Исраил угылларының саны аз кебек тоела һәм ул болай дип әйтә:

إِنَّ هَٰٓؤُلَآءِ لَشِرْذِمَةٌ قَلِيلُونَ ﴿٥٤﴾

**«Һичшиксез, алар бит аз санлы бер көтү генә».**

«Әш-Шүгәра / Шагыйрьләр», 26:54

Ә Муса галәйһиссәлам халкы фиргавенне һәм аның гаскәрләрен күргәч, зур куркуга төшә, чөнки алар диңгез буена килеп җиткән була һәм чигенергә урыннары калмый. Коты очкан халык Муса галәйһиссәламгә болай дип әйтә:

– Ий Муса! Алар безне куып җитеп баралар. Без бүген һәлак булачакбыз. Әгәр дә без диңгезгә керсәк, һичшиксез батып үләчәкбез. Безнең артта фиргавен гаскәрләре тора, әгәр алар безне куып җитсәләр, барыбызны да үтерәчәкләр. Ий Муса! Безгә нишләргә? Әгәр дә безгә һәлак булырга язган икән, безне Мисырдан алып чыкмаска кирәк иде, анда һәлак булуыбыз яхшырак булыр иде.

Аларга җавап итеп Муса галәйһиссәлам болай дип әйтә:

قَالَ كَلَّآ ۖ إِنَّ مَعِيَ رَبِّي سَيَهْدِينِ ﴿٦٢﴾

**«Ул [Аллаһының вәгъдәсенә ышанып]: «Юк! [Алар безне һич тота алмаслар! Аллаһы хакында начар уйламагыз!] Һичшиксез,**

**Раббым минем белән бергә, Ул [котылуыбыз өчен] миңа юл күрсәтәчәк!»** – диде.

«Әш-Шүгәра / Шагыйрьләр», 26:62

Аннары Аллаһы Тәгалә Муса галәйһиссәламгә:

...اضْرِب بِّعَصَاكَ الْبَحْرَ ۖ

**«Таягың белән диңгезгә сук!»** – дип әмер биргән.

«Әш-Шүгәра / Шагыйрьләр», 26:63

Муса галәйһиссәлам таягы белән диңгезгә суккач, халык каршындагы диңгез чигенә. Муса галәйһиссәлам халкы каршында унике юл ачыла. Диңгез төбе буйлап үткән бу аралыкка Аллаһы Тәгалә кояш һәм җил җибәрә, алар үтәр юлны тулысынча киптерәләр. Шулай итеп Исраил угылларының һәр кабиләсе үз юлы буйлап китә. Аралыкның ике ягында тау кебек биек булып диңгез суы тора, һәм ул судан эшләнгән дивар кебек түгел, ә бетоннан эшләнгән кебек хәрәкәтсез була.

Кабиләләрнең һәрберсе үз юлы буенча бара һәм башка кабиләләрне күрми. Шуңа алар тагын Муса галәйһиссәламгә мөрәҗәгать итәләр:

– Нишләп без башкаларны күрмибез? Бәлки алар инде батканнардыр һәм һәлак булганнардыр?

Муса галәйһиссәлам аларга:

– Алга барыгыз! Алар сезнең кебек үк үз юллары белән баралар, – дип әйтә.

Аңа җавап итеп Исраил угыллары:

– Без дусларыбызны күрми торып канәгать була алмыйбыз, – диләр.

Шунда Муса галәйһиссәлам Аллаһыга мөрәҗәгать итеп сорый:

– Ий Аллаһы! Миңа боларның юньсез холыкларына каршы ярдәм күрсәтсәңче!

Шуннан соң Аллаһы Тәгалә: «Таягың белән уң якка сук!» – дип аңа вәхи иңдерә. Муса галәйһиссәлам шуны эшләгәч, унике юлны бер-берсеннән аерып торган су массивларында тәрәзәләр барлыкка килә һәм кешеләр бер-берсен күрә һәм ишетә алу мөмкинлегенә ия булалар. Шулай итеп, Муса галәйһиссәлам халкы диңгез төбе аша үтеп, аның икенче ярына барып чыга.

Бу вакытта фиргавен үз гаскәре белән диңгез төбендә ачылган юлга килеп җитә. Икегә аерылган диңгезне күреп, фиргавен үз халкына:

– Минем бөеклекне күреп һәм мин үз колларымны куып тотар өчен диңгез икегә аерылды, – дип әйтә.

Ләкин аның бер генә кешесе дә диңгез төбенә керергә теләми. Фиргавен кешеләре куркып:

– Әгәр дә син Раббы икәнсең, Муса анда кергән кебек, син дә бу юлга кер, – дип әйтәләр.

Ләкин фиргавен дә диңгез төбенә керергә кыймый. Бу көнне ул үзе дә, гаскәре дә айгырларга атланган була. Шунда Җәбраил галәйһиссәлам биягә атланып алар каршына килеп баса һәм, аның биясе артыннан фиргавен айгырлары да иярсен өчен, беренче булып диңгез төбендәге юлга керә. Фиргавеннең аты бия исенә ияреп диңгез төбендәге шул юлга атлый. Әлбәттә, алар Җәбраил галәйһиссәламне күрмиләр, тик фиргавен үз айгырын туктата алмый. Аның артыннан бу юлга аның бар гаскәре дә кереп китә.

Шул ук вакытта Микаил галәйһиссәлам атка атланып гаскәрләрнең артына баса һәм гаскәрләрне алга таба куалый башлый. Ул коры җирдә бер генә кеше дә калмавын, барысының да су төбендәге юлга кереп беткәнен күзәтеп тора.

Фиргавен халкыннан соңгы кеше диңгезгә кергәч, ә Муса галәйһиссәлам халкының соңгы кешесе диңгездән чыккач, Аллаһы Тәгалә диңгезгә аларны йотарга әмер бирә. Һәм чамадан тыш зур дулкынна-

ры шау килеп фиргавен гаскәрләре өстендә ябылалар. Тау кебек зур бу дулкыннар кушылгач, фиргавеннең бар гаскәре суга батып үлә.

Риваятьләрнең берсендә Җәбраил галәйһиссәламнең шушы вакыйгаларга кадәр үк кеше кыяфәтендә фиргавенгә килүе тапшырыла. Ул фиргавеннән:

– Әгәр дә синең берәр колың синнән баш тартып үзенең Раббылыгы турында игълан итсә, син аны нишләтер идең? – дип сорый.

Аңа җавап итеп фиргавен:

– Мин аны суда батырып үтерер идем, – дип җавап бирә.

Шунда Җәбраил галәйһиссәлам аңа, кул куйсын өчен, аның шул сүзләре язылган кәгазь бирә. Ул имзасын куя. Фиргавен суда батырып үтерелгәч, Җәбраил галәйһиссәлам бу кәгазьне алып килеп аның каршына куя. Ягъни, чынлыкта фиргавен үзе үк үзенә үлем карары чыгарган булып чыга.

Фиргавен батып үлгән вакытта аның күз алдындагы пәрдәләр алып ташлана һәм аңа Ахирәттә булачак урыны күрсәтелә. Һәм шунда ул:

آمَنتُ أَنَّهُ لَا إِلَـٰهَ إِلَّا الَّذِي آمَنَتْ بِهِ بَنُو إِسْرَائِيلَ وَأَنَا مِنَ الْمُسْلِمِينَ ﴿٩٠﴾

**«Һичшиксез, мин Исраил угыллары ышанган Заттан башка һичбер илаһ булмаганына иман китердем. Мин дә – [үзләрен Аллаһыга тапшырган] мөселманнарданмын!»** – дип әйтә.

«Юныс», 10:90

Мондый иман кабул ителәме соң? Бөтен чикләрне узып, үзен илаһ дип игълан иткән, һәм үзенә Аллаһының ике илчесе җибәрелгән, күпме могҗизалар күргән фиргавен Аллаһыга ышанудан баш тарта, әмма рухы тәнен бушаткан мәлдә җәһәннәмдә үз урынын күргәч, Мин Раббыга иман китерәм, мин – мөселманнардан», – дип әйтә. Аллаһы Тәгалә гомеренең соңгы мизгелендә китергән иманын кабул итми:

ﺁﻟْﺂﻥَ ﻭَﻗَﺪْ ﻋَﺼَﻴْﺖَ ﻗَﺒْﻞُ ﻭَﻛُﻨﺖَ ﻣِﻦَ ﺍﻟْﻤُﻔْﺴِﺪِﻳﻦَ ﴿٩١﴾

**«[Шулвакыт аңа әйтелде] «Хәзерме? Моңарчы [Аллаһы Тәгаләгә] каршы торган һәм [кешеләрнең иманына комачау иткән] бозыклык таратучылардан идең бит».**

«Юныс», 10:91

Башкаларның да гомерләре өзелгән чакта китергән тәүбәләре әнә шулай кабул ителмичә кала, чөнки алар фиргавен шикелле бөтен тормышын итагатьсезлектә үткәрә. Раббыбыз болай дип әйтә:

وَلَيْسَتِ التَّوْبَةُ لِلَّذِينَ يَعْمَلُونَ السَّيِّئَاتِ حَتَّىٰ إِذَا حَضَرَ أَحَدَهُمُ الْمَوْتُ قَالَ إِنِّي تُبْتُ الْآنَ وَلَا الَّذِينَ يَمُوتُونَ وَهُمْ كُفَّارٌ ۚ أُولَٰئِكَ أَعْتَدْنَا لَهُمْ عَذَابًا أَلِيمًا ﴿١٨﴾

**«[Дәвамлы рәвештә] Явызлык кылган, үлем килгәч [кенә]: «Мин хәзер тәүбә иттем», – дип әйткәннәргә ул [кабул ителә торган] тәүбә юк. Һәм кяфер булып үлгән кешеләргә дә [Ахирәттә кылган тәүбәләре кабул ителмәс]. Әнә шулар өчен Без тилмерткеч бер газап әзерләдек».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:18

Исраил угыллары исә, фиргавен һәм аның гаскәре батып үлүгә карамастан: «Алар безне куып җитәрләр дә, үтерерләр», – дип курку һәм борчылуларын дәвам итәләр. Шулвакытта диңгез фиргавеннең хәрби киемнәре белән бар гаскәрен һәм аның үзен ярга чыгарып ташлый. Бу вакыйгадан соң диңгез батып үлгән кешеләрнең гәүдәләрен кабул итми, аларны читкә бәреп чыгара башлый.

Алдагы буыннарга гыйбрәт булсын өчен, фиргавеннең гәүдәсе череп таркалмый, ул яр буена сәҗдә кылган халәттә чыгарып ташланган була.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

فَالْيَوْمَ نُنَجِّيكَ بِبَدَنِكَ لِتَكُونَ لِمَنْ خَلْفَكَ آيَةً ۚ وَإِنَّ كَثِيرًا مِّنَ النَّاسِ عَنْ آيَاتِنَا لَغَافِلُونَ ﴿٩٢﴾

**«Бүген Без синнән соң киләчәк кешеләр өчен бер аять [һәм гыйбрәт] булсын дип, сине [җансыз бер хәлдә, ләкин бөтен] бәдәнең белән коткарачакбыз». [Менә бу кыйссада нинди зур гыйбрәтләр бар] Әмма, һичшиксез, кешеләрнең күбесе Безнең аятьләребездән [алар турында фикер йөртүдән] гафилләр».**

«Юныс», 10:92

Зәмәхшәри бу аятькә шундый тәфсир бирә: «Без синең гәүдәңне диңгез ярына чыгарып ташларбыз. Без синең шәрә тәнеңне күп гасырлардан соң киләчәк алдагы буыннарга нәсыйхәт булсын өчен череп таркалудан саклап калырбыз».

Фиргавеннең гәүдәсе, инглиз галимнәре тарафыннан, Кызыл диңгез ярындагы комнарда табыла һәм Лондонга китерелә. Фиргавеннең үлеменә өч мең елдан артык вакыт үтсә дә, аның тәне бозылмаган, таркалмаган, хәтта чәчләре дә коелмаган. Аның гәүдәсе сәҗдә кылу халәтендә, ул бүгенге көндә Британия музеена куелган.

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*

*Татарстан Республикасы мөфтие*

# Коръән сүрәләре

## 79.Ән-Нәәзигәәт (Йолкып алучылар) сүрәсе

Мәккә чоры, 46 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. [Кяферләрнең рухларын] **Көч белән йолкып алучылар** [фәрештәләр] **белән ант итәмен.**
2. [Мөэминнәрнең рухларын] **Җиңел итеп чыгаручылар белән дә.**
3. **Йөзеп йөрүчеләр** [фәрештәләр] **белән дә.**
4. **Ярыша-ярыша** [бер-берсен] **узышканнар** [фәрештәләр] **белән дә.**
5. **Һәм** [колларга бәйле] **эшне үтәүчеләр** [фәрештәләр] **белән дә!** [Һичшиксез, терелтеләчәксез!] [1]
6. **Тетрәгәннең** [беренче мәртәбә сурга өрүдән соң, һәрнәрсә] **хәрәкәткә киләсе көнендә** [барыгыз бергә үтереләчәксез]**.**
7. **Артыннан килгән һәрнәрсә дә аңа иярәчәк** [сурга икенче мәртәбә өрелгәннән соң барыгыз бергә терелтеләчәксез]**.**
8. **Ул көнне йөрәкләр тетрәячәк.**
9. **Аларның карашлары түбән төшкән хәлдә.**
10. [Болар көләр өчен] **Әйтәләр** [иде]**: «Чыннан да, без** [үлемебездән соң терелтелеп] **элекке хәлгә кайтарылачакбызмы?**
11. **Без черегән сөякләр булганнан соң** [терелтеләчәкбезмени]**?»**
12. **Алар** [мыскыл итеп] **әйттеләр: «Алай булгач, бу – бик зарарлы бер кайту!»**
13. **Ул –** [сурга икенче кат өрү белән, мәйданга киләчәк] **бер көчле тавыш кына.**
14. **Менә алар – тип-тигез җир өстендә** [хисапка тартылуны көтеп торган тере кешеләр]**!**
15. [Расүлем!] **Мусаның** [галәйһиссәлам] **хәбәре сиңа ирештеме?**
16. **Менә Раббысы аңа мөкатдәс үзәнлек булган Тубада мөрәҗәгать итте.**

---

1 Аяте кәримәдә телгә алынган антлар Аллаһының дуслары булган әүлияләрнең рухлары кебек фазыйләтле рухлар белән бәйле була ала. Бәдәннәреннән тәмам аерылган бу изге рухлар фәрештәләр галәменә сөенечле бер шәкелдә ирешәләр, анда йөзеп йөргән шикелле бер урыннан икенче урынга бик тиз күчәләр, шәрәфләре һәм рухи көчләре сәбәпле, мәхлүкъларның эшләре белән идарә иткән рухани затларга кушылалар. Шуңа күрә: «Эшләрегездә аптырашка калган чагыгызда кабер әһелләреннән ярдәм сорагыз!» – дип әйтелгән (Бәйдави, Фәхруррази, Шиһаб).

17. **«Фиргавенгә бар** [да Миңа коллыкка дәгъват ит]**! Һичшиксез, ул азынды.**
18. **Әйт: «Сиңа** [ширектән һәм гөнаһтан] **арынырга кирәк түгелме?**
19. **Сине Раббыңа һидаять итим дә, шул сәбәпле,** [Аңардан] **хөрмәт белән куркырсың».**
20. **Ул аңа** [таягының аждаһага әверелүе кебек] **бөек бер аять** [һәм могҗиза] **күрсәтте.**
21. **Әмма ул** [бу могҗиза Аллаһыдан булганын] **ялган дип санады һәм каршы төште.**
22. **Шуннан соң** [курку белән] **качып,** [Мусага [галәйһиссәлам] **аркасы белән борылды.**
23. **Ул** [бөтен сихерчеләрне һәм гаскәрен] **туплады һәм мөрәҗәгать итте.**
24. **Һәм әйтте: «Сезнең бөек Раббыгыз – мин!»**
25. **Аллаһы аны Ахирәттә дә, дөньяда да гыйбрәт бирерлек бер җәзаландыру белән тотты.**
26. **Һичшиксез, монда** [Аллаһыдан] **курыккан кешеләр өчен гыйбрәт бар.**
27. [Ий терелүне инкяр итүчеләр!] **Яратылу өчен сезме кыенрак, күкме? Аны Ул бина кылды.**
28. **Гөмбәзен биек итте һәм аны** [ярыксыз] **корды.**
29. **Төнен караңгы итте, көндезен дә** [уртага] **чыгарды.**
30. **Җирне Ул моннан** [күкнең яратылышыннан] **соң** [Мәккәдән башлап] **түшәде.**
31. **Шуннан соң суын һәм утлавын чыгарды.**
32. **Тауларны да. Ул аларны какшамас итте.**
33. [Менә болар] **Сезнең һәм терлек-туарыгызның файдасына** [эшләнде]**.**
34. **Бөек бәла** [булган Кыямәт сәгате] **җиткәч.**
35. **Кешенең** [чамасыз гафләте сәбәпле оныткан гамәлләре күрсәтелеп, дөньяда] **нәрсә өчен көч куйганы исенә төшәчәк көнне.**
36. **Ут, күрә алганнар өчен,** [һич яшерен калдырылмыйча] **күренәчәк.**
37. **Кем чиктән ашса.**
38. **Һәм** [шәһвәтләренә ияреп] **дөнья тормышын** [Ахирәтнекеннән өстен тотып] **сайласа...**
39. **Һичшиксез,** [мондый кяфер өчен] **сыеныр урын** [дөрләп янган] **Ут** [булыр]**.**
40. **Кем исә Раббысының хозурында басып торудан курка һәм** [бертук-

таусыз начарлыкка әмер иткән] **нәфесен начар теләкләрдән тыя.**

41. **Һичшиксез,** [мондый кеше өчен] **сыеныр урын җәннәт** [булыр].
42. [Расүлем!] **Синнән Сәгать турында сорыйлар: «Ул кайчан җитәчәк?»**
43. **Нигә аны сиңа искә алырга?**
44. **Аның** [белән бәйле белемнең] **ахыры – синең Раббыңда.**
45. **Син бит** [кешеләргә Кыямәтнең вакытын әйтер өчен җибәрелмәдең] **фәкать аңардан курыкканнар өчен кисәтүче генә.**
46. **Алар аны күрәсе көнне** [газапның катылыгына һәм вакытның озынлыгына шаһит булгач] **үзләрен бер төштән соң яки төшкә кадәр генә** [дөньяда] **торган дип санарлар.**

# Фән

# Тәэмин итү

**Сорау:** Өйләнгән кеше кемне тәэмин итәргә тиеш?

**Җавап:** Үзенең хатыннарын һәм балаларын, шулай ук аерган хатыннарын (гыйддә вакыты үткәнче), әти-әнисен һәм туганнарын тәэмин итәргә тиеш.

## Хатыннарны тәэмин итү

**С**.: Хатыннарны тәэмин итү белән бәйләнгән халәтне аңлатыгыз әле.

**Җ**.: Менә ул халәтләр:

1. Ирнең хатыны мөселман яки кяфер булуына карамастан, ул аны тору урыны һәм киемнәр белән тәэмин итәргә тиеш;

2. Әгәр хатын мәһәр түләнгәнче ире белән торудан баш тартса, ир аны тәэмин итәргә тиеш.

3. Әгәр хатын балигъ булмаса һәм ир аның белән якынлык кылмаса, ире аны тәэмин итәргә тиеш түгел.

4. Әгәр балигъ булмаган ир балигълыкка ирешкән хатыны белән җимагъ кыла алмаса, ире аны тәэмин итәргә тиеш;

5. Әгәр хатынны бурычлары өчен кулга алсалар яки мәҗбүриләп алып китсәләр, иренә аны тәэмин итү вәҗиб түгел;

6. Әгәр хатын иреннән башка хаҗ юлында булса, аны тәэмин итү вәҗиб түгел;

7. Әгәр хатын ире өендә авырса, ире аны тәэмин итәргә тиеш;

8. Әгәр ир кәнизәккә өйләнсә һәм хуҗа аларны бер йортта тотса, ир хатынын тәэмин итәргә тиеш.

9. Әгәр кол хуҗа рөхсәте белән азат хатынга өйләнсә, һәм колның хуҗасы бу хатынны тәэмин итмәсә, хатынын тәэмин итү бурычы ирдә була. Әгәр кол сатылса, әлеге акча хатынын тәэмин итү өчен түләнә.

**С.**: Кияүгә чыкканчы әти-әнисе йортында кызның хезмәтчесе булса, бу хатынның ире аның өчен хезмәтче ялларга тиешме?

**Җ.**: Әгәр мөмкинлеге булса, бер хезмәтче ялларга тиеш була.

**С.**: Иргә хатынын тәэмин итү мөмкин булмаса, алар аерылырга тиешме?

**Җ.**: Юк, хатын үзен тәэмин итү өчен, иренә бурыч итеп үз малын бирә, ире соңыннан бурычын хатынына кайтара.

**С.**: Ир хатынын күпмедер вакыт тәэмин итмәсә, соңыннан хатын бу вакыт эчендә үзе өчен тоткан сумманы иреннән таләп итсә, ире бу сумманы түләргә тиешме?

**Җ.**: Юк, әгәр алар алдан түләргә дип килешенмәгән булсалар, түләргә тиеш түгел.

**С.**: Суд ирне хатынын тәэмин итүгә хөкем итә, ә ир хатынын берничә ай тәэмин итмичә, үлеп китсә, хатынга үзен тәэмин иткән сумманы кем түләргә тиеш?

**Җ.**: Ире үлгәннән соң хатынга беркем дә түләргә тиеш түгел.

**С.**: Ир хатынына бер еллык чыгымнары өчен билгеле сумма биргәннән соң, бу сумманы чыгарып бетергәнче икесенең берсе үлсә, хатын калган сумманы кайтарырга яки ир кире алырга тиешме?

**Җ.**: Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи ир үлгән очракта, сумма тулысынча хатын кулында кала, ди, ә Мөхәммәд рахимәһуллаһи хатыны үлгән очракта, сумманың калган өлеше иргә кайтарылырга тиеш, дип саный.

## Йорт белән тәэмин итү

**С.**: Хатынның тору урыны нинди булырга тиеш?

**Җ.**: Тору урыны аерым булырга тиеш, әгәр хатын бу йортта иренең гаиләсе белән яшәргә теләмәсә, иренең гаиләсеннән беркем дә яшәргә тиеш түгел.

**С.**: Ир хатынның туганнарын бу өйгә керүдән тыя аламы?

**Җ.**: Әйе, тыя ала, ләкин хатынның туганнарының аны күрергә һәм аның белән кайда теләсәләр, шунда сөйләшергә хаклары бар.

### Аерылган хатынны гыйддә вакытында тәэмин итү

**С.**: Гыйддә вакытында аерылган хатынны кем тәэмин итәргә тиеш?

**Җ.**: Ир талак әйткәннән соң, нинди талак әйтүенә карамастан, хатынның гыйддә вакыты үткәнче, аны тәэмин итәргә тиеш.

Әгәр ир үлсә, хатыны ире хисабына тора алмый, ул үзен иреннән калган мирас белән тәэмин итәргә тиеш.

**С.**: Аерылганнан соң ир хатынын тәэмин итәргә тиеш булмаган очраклар бармы?

**Җ.**: Әйе, әгәр хатыны исламнан чыгу, яки хатынның зур гөнаһы булу сәбәпле аерылышсалар, яки хатын талакка кадәр үги ул белән якынлык кылса, ир аны тәэмин итәргә тиеш түгел.

### Балаларны тәэмин итү

Гаилә башлыгы балигъ булмаган балаларын тәэмин итәргә тиеш. Кыз балигъ булгач, кияүгә чыкканчы, чыгымнар әтисе белән әнисе арасында бүленә: чыгымның $^2/_3$ өлешен – әтисе, $^1/_6$ өлешен – әнисе тәэмин итәргә тиеш.

**Искәрмә.** Әгәр балигъ булмаган балаларның нинди дә булса мөлкәтләре булса (мәсәлән, бүләк ителгән мөлкәт), бу очракта балаларны шул мал белән тәэмин итәргә була.

### Ата-ананы тәэмин итү

**С.**: Кайчан әти-әнине тәэмин итү вәҗиб?

**Җ.**: Әгәр кемнең дә булса мөлкәте булса, бу мөлкәте белән ул үзен тәэмин итәргә тиеш. Искәрмә булып хатыннар тора, алар хәтта ирләреннән байрак булсалар да, ирләре аларны тәэмин итәргә тиеш.

Әгәр ата-ана мохтаҗ булсалар, аларны балалары тәэмин итәргә тиеш. Әгәр әби-бабайлары булса, аларны да карарга кирәк.

**С.**: Улларының мөлкәте ата-ана кулында булса, һәм алар бу мөлкәтне уллары булмаганда үзләре өчен тотсалар, алар аның милкен кайтарып бирергә тиешме?

**Җ.**: Юк, тиеш түгел, ләкин балаларының күчемсез мөлкәтен аның рөхсәтеннән башка сата алмыйлар.

**С.**: Әгәр ата-ана улларының тәэмин итүенә мохтаҗ булсалар, суд аны әти-әнисен тәэмин итәргә мәҗбүр итә аламы?

**Җ.**: Әйе.

**С.**: Баланың мөлкәте чит кеше кулында булып, бу кеше мөлкәт хуҗасының әти-әнисен әлеге мөлкәт белән тәэмин итсә, хуҗага бу мөлкәтне кайтарырга тиешме?

**Җ.**: Әгәр казый ризалыгы белән мөлкәт хуҗасының ата-анасын тәэмин иткән булса, милекне хуҗасына түләргә тиеш түгел. Әмма казый рөхсәт итмәсә, түләргә тиеш.

**С.**: Дин тотуда ихтиләф булганда, акча белән тәэмин итү вазифасы ничек була?

**Җ.**: Төрле диндә булсалар да, хатынын, ата-анасын, әби-бабасын, балаларын һәм оныкларын тәэмин итү вәҗиб булып кала.

**С.**: Баланың дине әтисенең диненнән ничек аерыла?

**Җ.**: Мәсәлән, кяфер ир кяфер хатынга өйләнеп, балалары булгач, хатын ислам кабул итеп, ире кабул итмәсә, бала әнисенең динендә булып санала һәм бала мөселман була. Ләкин ата кеше хатынын да, баласын да тәэмин итәргә тиеш.

**Искәрмә.** Әгәр гаилә башлыгы булмаганда, гаилә тәэмин итүгә мохтаҗ булса, һәм билгеле бер кешедә гаилә башлыгы биргән малы булса, казый бу кешегә саклanyрга бирелгән мал хисабыннан гаиләне тәэмин итүне йөкли.

# Туганнарны тәэмин итү

**С.**: Туганнардан кемне тәэмин итәргә кирәк?

**Җ.**: Мирас чиратында туганнар әһәмияткә карап билгеләнә: мәсәлән, әгәр бер кешенең бабасы һәм оныгы булса, һәм алар тәэмин итүчеләрдән булсалар, ягъни онык балигъ булмаса һәм тәэмин итүгә мохтаҗ булса, яки кыз-онык балигъ һәм мохтаҗ булса, тәэмин итүнең $^1/_6$ өлешен бабай ала, ә калганы оныкка була. Сукыр яки хроник авыру белән авыручы олы кеше тәэмин итүгә дәгъвачы була ала.

**Искәрмә.** Әгәр суд ир кеше ата-анасын, балаларын һәм туганнарын тәэмин итәргә тиеш, дигән хөкем чыгарса, ләкин күпмедер вакыт эчендә ул моны эшләмәсә, һәм аңа башкалар тәэмин итү өчен бурычка мал бирмәгән очрактан башка вакытта, бу хөкем кире кагыла.

## Сабый балаларны ашату

Ана үз балаларын үзе ашатса, әйбәт, ләкин ул баш тартса, ата сөт анасын яллаpга тиеш.

**С.**: Бала анасы баласын ашаткан өчен иреннән түләүне таләп итә аламы?

**Җ.**: Баланың әтисе аерганнан соң, гыйддә вакытында, хатын үз баласын ашаткан өчен түләүне таләп итә алмый, чөнки ире аны болай да тәэмин итә. Ләкин аерылганнан соң, гыйддә вакыты үткәч, бала анасы атасыннан ашаткан өчен түләүне таләп итә ала.

**С.**: Аерылганнан соң һәм гыйддә вакыты үткәч, баланың атасы сөт анасын яллаcа, ә баланың әнисе шул ук суммага үзе ашатырга ризалашса, баланы ашатуга кемнең хакы күбрәк?

**Җ.**: Баланың әнисенең хакы күбрәк.

**С.**: Аерылышканнан соң ир белән хатынның яки туганнары арасыннан балага кемнең хокукы күбрәк?

**Җ.**: Ананың хакы күбрәк. Әмма анасы булмаса, баланың әнисенең әнисе, әгәр ул булмаса, әтисенең әнисе, аннан соң баланың апалары (башта әтисе ягыннан һәм әнисе ягыннан туган апалары, аннан соң әнисе ягыннан гына туган апалары, соңыннан әтисе ягыннан туган апалары), соңра әнисе ягыннан туган әнисенең апа-сеңелләре, соңра әтисе ягыннан туган булган әтисенең апа-сеңелләре баланы алырга хаклары бар.

**С.**: Нинди очракларда баланы ашату хокукы югала?

**Җ.**: Әүвәлдә санап үтелгән хатыннар кияүгә чыксалар, әнисеннән башкалары баланы ашату хокукын югалталар.

**С.**: Әгәр ана баласын тәрбияләргә теләмәсә һәм туганнарыннан берсе дә баланы алырга ризалашмасалар, нишләргә?

**Җ.**: Ана баласын тәрбияләргә мәҗбүр ителә.

**С.**: Әгәр баланы тәрбиягә алырга кыз туганнары булмаса, ир туганнарыннан кайсының баланы тәрбиягә алырга хокукы күбрәк?

**Җ.**: Башта баланы әтисенеке, аннан соң бабасыныкы, аннан соң абыйсыныкы, аннан соң әти-әнисенең абый-энесе, соңыннан туганнан туган абыйсыныкы.

**С.**: Баланы күпмегә кадәр кыз туганнары тәрбияләргә тиеш?

**Җ.**: Апасы яки әбисе бала үзе ашарга, эчәргә, киенергә, юынырга өйрәнгәнче тәрбияләргә тиеш. Әгәр бала кәнизәк булса, бу очракта аның хәезе булганчы тәрбияләргә кирәк.

**С.**: Әгәр кяфер хатын мөселман ирдән бала тапса, ана баланы күпмегә кадәр тәрбияли ала?

**Җ.**: Бала диннәрне аера башлаганчыга кадәр, әнисе тәрбияли.

**С.**: Кәнизәкнең бала тәрбияләргә хакы бармы?

**Җ.**: Хакы юк, чөнки ул хуҗасына хезмәт итү белән мәшгуль. Әгәр азат ителсә, ул бала тәрбияләү хокукын ала.

**С.**: Хатын аерылганнан соң баланы тәрбиягә алса, ире белән яшәгән шәһәрне калдырып, читтә яши аламы?

**Җ.**: Юк, әгәр ул туган, үскән җиренә һәм аерылган иренә кияүгә чыккан җиргә күчеп китмәсә, башка җирдә яши алмый.

*Мөхәммәд Гашыйк Иләһи Әл-Бәрни*
*«Әт-тәсһил әд-дарури ли мәсәил Әл-Кудури» китабыннан*

# Мәүлид

## Пәйгамбәрләрнең хуҗасы Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең туу кыйссасы

«Әгәр син булмасаң, әй, Мөхәммәд, күкләрне бар кылмас идем», – дип мәртәбәле булган; Хак Тәгаләдән:

وَلَسَوْفَ يُعْطِيكَ رَبُّكَ فَتَرْضَىٰٓ ﴿٥﴾

**«Тиздән синең Раббың морадыңны бирер, риза булырсың»,** – дип сөенеч ишеткән;

«Әд-Духә / Иртә», 93:5

Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә:

فَوَلِّ وَجْهَكَ شَطْرَ الْمَسْجِدِ الْحَرَامِ ۚ ﴿١٤٩﴾

**«Йөзеңне мәчет тарафына юнәлдер»,** – дип Кәгъбәтуллаһны кыйбла иткән;

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:149

Хак Тәгаләдән:

لَمْ نَشْرَحْ لَكَ صَدْرَكَ ﴿١﴾

**«Әй, Мөхәммәд, күкрәгеңне раушан нурлы кылмадыкмы»,** – дип нигъмәтләнгән;

«Әл-Инширах / Ачылу», 94:1

وَوَضَعْنَا عَنكَ وِزْرَكَ ﴿٢﴾ الَّذِي أَنقَضَ ظَهْرَكَ ﴿٣﴾

**«Әй, Мөхәммәд, синең аркаңа авыр булган киемне куйдык, ягъни аркаңнан төшердек»,** – дию белән җиңеллек тапкан;

«Әл-Инширах / Ачылу», 94:2-3

Хак Тәгаләдән:

وَرَفَعْنَا لَكَ ذِكْرَكَ ﴿٤﴾

**«Сине зикер итүне күтәрдек»,** – дип кәрамәт бирелгән.

«Әл-Инширах / Ачылу», 94:4

Аллаһы Тәгаләнең хәбибе (яратканы), гөнаһлы өммәтләрнең гөнаһысының табибы, пәйгамбәрләр хуҗасы, Кыямәт көненең шәфәгатьчесе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмдер.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе: «Хак Тәгалә галәмне, ягъни оҗмах, тәмугны, җир һәм күкне, Гареш һәм Көрсине һәм башкаларны яратырга, бар кылырга теләгән заманда, Үз нурыннан бераз нур алып, нурга: «Хәбибем Мөхәммәд бул», – диде». Икенче риваятьтә: Хак Тәгалә җир һәм күкне бар кылырга теләгән заманда, Үзенең нурыннан бераз нур алып, нурга әйтте: «Әй, нур, син хәбиб, ягъни дустым Мөхәммәд бул». Ул нур Адәм галәйһиссәлам яратылудан әүвәл биш йөз ел элек Гарештә: «Әлхәмдүлилләһ», – дип тәваф кылыр иде. Хак Тәгаләгә бу хәмедне әйткәне өчен Мөхәммәд дип исем кушты. Аннан соң Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм нурыннан Адәм галәйһиссәламне бар кылды. Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тәнен Адәм галәйһиссәлам балчыгыннан яратты. Моннан соң Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нурын Адәм галәйһиссәлам аркасына куйды. Ул нур Адәм галәйһиссәламнән Хавва анага күчте. Шулай атадан анага күчеп, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә иреште.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм нәселенең бәяне. Сәедебез пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең атасы Габдулла, аның атасы Габделмотталиб иде. Габделмотталибның дөрес исеме – Шибәтүл-хәмед, чөнки Габделмотталибның туган вакытында башында ак төкләре бар иде. Габделмотталибның атасы Һашим, чын исеме Гамру, аның атасы Габдемәнәф, чын исеме Могыйра, аның ата-

сы Кусай, чын исеме Мөҗәммигъ, аның атасы Киләб, чын исеме Хәким, Мөрра Кәгъб улы, Кәгъб Ләәй улы, Ләәй Галиб улы, Галиб Фәхернең улы, Фәхернең чын исеме Кораеш, Кораеш Мәлик улы, Мәлик Надыйр улы, Надыйр Кинан улы, Кинан Хөзәймә улы, Хөзәймә Мөдрикә улы, Мөдрикә Ильяс улы, Ильяс Мөдәр улы, Мөдәр Нәзар улы, Нәзар Мәгадь улы, Мәгадь Гадьнән улы, Гадьнән Исмәгыйль галәйһиссәлам нәселеннән. Әмма Гадьнәннән Исмәгыйль галәйһиссәламгә кадәр фәлән фәләннең улы, дип билгеләүдән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм тыйды. «Кәзбүн-нисәбүн» дип, ягъни нәсеп итүчеләр ялганлыйлар, дип баш тартып, мәкруһ күрә иде. Шуның өчен Рабгузый риваятенчә зекер итмәдек.

Безгә пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмне Исмәгыйль галәйһиссәлам нәселеннән дип белү дә җитәдер.

Риваятьләрдә әйтелгәнчә, Шам вилаятендә яһүдләрнең галимнәре үзләренең китапларында күрделәр: Яхъя галәйһиссәлам җөббәсеннән кан тамса, шулвакыт Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең атасы дөньяга килер, дип язылган иде. Шул сәбәпле тикшереп, сорашып, Габделмотталибның улы дөньяга килгәнен белделәр. Габдулла үскәч, аны үтерергә ниятләделәр. Аллаһы Тәгалә аларга фәрештәләр җибәрде, ниятләүчеләрнең барчасын үтерделәр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең анасы Әминәнең атасы Вәһеб тау башында Яхъя галәйһиссәламнең җөббәсеннән кан тамганын күреп, Габдулла бине Габделмотталибны тәмам белде. Көннәрдән бер көнне Вәһеб үзенең хатыны Бәррагә: «Әминәне Габдуллага хатынлыкка бирәсеңме?» – диде. Бәрра: «Әйе, бирермен», – диде. Бу заманда Аллаһының хикмәте Габделмотталиб улы Габдулла өчен Вәһебкә яучы җибәрде. Вәһеб мең шөкер белән кабул итте. Раҗәб аенда җомга кичне туй иттеләр. Зөфаф шул ук кичтә булып, Әминә йөкле булды. Ибне Габбас радыяллаһу ганһе әйтте: «Бу кичә Кораеш кабиләсендә булган һәр җанвар сөйләшеп, бер-берсенә: «Мөхәммәд бу көнне ана карынына төште», – дип сөенеч бирделәр».

«Кәгъбәнең Раббысы белән ант итеп әйтәбез, ул Мөхәммәд дөньяның иминлегедер, ата-бабасының нурыдыр», – диделәр. Иблис мәлгунь Әбү Кәбис тавына менеп кычкырды. Шәйтаннар: «Ни булды сиңа, әй, хуҗабыз?» – дип янына җыелдылар. Иблис: «Аһ, минем ничә еллар чиккән мәшәкатем, бу көнне Мөхәммәд ана карынына төште, Аллаһы Тәгалә аны үткен кылыч белән җибәрер, диннәрне үзгәртер, потларны сындырыр», – диде. Хисәб бине Сәбит радыяллаһу ганһе әйтте: «Мин җиде яшемдә идем, Мәдинә урамында бер яһүди: «Әй, яһүдиләр, бу кичтә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең йолдызы туды», – дип кычкырды. Әминә әйтте: «Улым Мөхәммәд белән йөкле булганда, башка хатыннар кебек авырлык күрмәдем, ләкин хәез күрүем тукталды. Улым Мөхәммәдкә йөкле булгач, бер нур күрдем, мәшрикъ һәм мәгъриб яктырды, хәтта Шам вилаятендә Басра шәһәренең сарайларын күрдем. Йөкле булуымның беренче аенда төшемдә озын буйлы бер кешене күрдем: «Сөенеч сиңа, пәйгамбәрләр хуҗасы белән йөкле булдың», – диде. «Син кем?» – дип сорадым. «Атасы Адәм пәйгамбәр», – диде. Икенче айда янә бер кешене күрдем: «Сөенеч сиңа, әүвәлге һәм ахыргы кавемнең хуҗасы белән йөкле булдың», – диде. Ул Шис галәйһиссәлам иде. Өченче айда янә бер кешене күрдем: «Сөенеч сиңа, хөрмәтле пәйгамбәр белән йөкле булдың», – диде. Ул Нух галәйһиссәлам иде. Дүртенче айда янә бер кеше күрдем: «Сөенеч сиңа, шәрифле хуҗа белән йөкле булдың», – диде. Ул Идрис галәйһиссәлам иде. Бишенче айда янә бер кешене күрдем: «Сөенеч сиңа, адәмнәрнең хуҗасы белән йөкле булдың», – диде. Ул Һуд галәйһиссәлам иде. Алтынчы айда янә бер кешене күрдем: «Сөенеч сиңа, Һашим ыруыннан килүче пәйгамбәр белән йөкле булдың», – диде. Ул Ибраһим галәйһиссәлам иде. Җиденче айда бер кешене күрдем: «Сөенеч сиңа, галәмне тәрбия кылучы Аллаһы Тәгаләнең дусты белән йөкле булдың», – диде. Ул Исмәгыйль галәйһиссәлам иде. Бу җиденче айда Багдад шәһәрендә Кесәри патшаның сарае түбәсендә манараларының ундүрт гөмбәзе төште. Сигезенче айда

янә бер кешене күрдем: «Сөенеч синә, тәхкыйк, ахырзаманның соңгы пәйгамбәренә йөкле булдың», – диде. Ул Муса галәйһиссәлам иде. Бу сигезенче айда мәҗүсиләрнең гыйбадәт кыла торган утлары сүнде. Яхъя Сәрәри радыяллаһу ганһе әйтте: «Мәҗүсиләрнең бу утлары мең елдан бирле сүнмичә яна иде». Тугызынчы айда янә бер кешене күрдем: «Сөенеч сиңа, Мөхәммәдкә йөкле булдың», – диде. Ул Гайсә галәйһиссәлам иде», – диде.

Мәшһүр риваятькә нигезләнеп әйтелгәнчә, Әминә радыяллаһу ганһә пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән йөкле булганның икенче аенда Габдулла атасы Габделмотталибның йомышы белән барган иде, шунда вафат булып, Мәдинәдә күмелде. Атасы үлгәч, фәрештәләр әйтте: «Йә, Раббым, пәйгамбәрең ятим булып калды». Аллаһы Тәгалә әйтте: «Мин аның саклаучы Хуҗасы һәм җиңү бирүчедер». Әминә радыяллаһу ганһә әйтте: «Улымның туу киче җиткәч, дүшәмбе кич таң алды иде. Күктән бер төркем җәмәгать төште. Аларның өч әләме бар иде: берсен Кәгъбәтуллаһның өстенә, икенчесен үз йортымның түбәсенә, өченчесен Бәйт Әл-Мөкаддәскә кададылар. Йолдызлар шулкадәр якын килде, хәтта үземә төшәр, дип уйладым. Күк ишекләрен тәмам ачык күрдем. Моннан соң өемнең эче зөбәрҗәт борынлы кошлар белән тулды. Дөнья яп-якты булды. Күк белән җир арасында ефәк палас түшәлгән итеп, шулай ук һавада кулларына алтын тоткалы көмеш комганнар тоткан ир кешеләрне күрдем. Шул заман сусадым, шул комганнарның берсеннән су эчтем. Үзем уйлап ятамын, ялгызлыктан күңелем зарыкты, шулчак яныма бер төркем хатын-кыз керде. Шулкадәр матурлар, берсе Асия иде, ул да ярдәм итте. Тулгаклап эчем авыртты, бер кош килеп, канаты белән корсагымны сыйпады, шулчак улым Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне тудырдым, мөбарәк ике аягы белән туды, ягъни йөзтүбән тумады. Бу аның Аллаһы Тәгалә хөкемендә туры булуына ишарә иде. Мөхәммәд Мостафа

салләллаһу галәйһи вә сәлләм тугач, теле белән: «Аллаһү әкбәр, Аллаһү әкбәр кәбиран, әлхәмдү лилләһи раббил-гааләмиин», – диде.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе атасы Габбас радыяллаһу ганһедән, ул үз атасы Габделмотталибтан риваять кылып әйтте: «Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм анасыннан сөннәтле һәм кендеге киселгән булып туды». Риваятьләрдә әйтелгәнчә, пәйгамбәрләрдән сөннәтле булып дөньяга килгән пәйгамбәрләр: Адәм галәйһиссәлам, Шис галәйһиссәлам, Идрис галәйһиссәлам, Нух галәйһиссәлам, Лут галәйһиссәлам, Йосыф галәйһиссәлам, Муса галәйһиссәлам, Шөгаеб галәйһиссәлам, Сөләйман галәйһиссәлам, Яхъя галәйһиссәлам, Гайсә галәйһиссәлам, Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм иде».

Әминә радыяллаһу ганһә әйтте: «Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне тудыргач, айга охшаган бер кеше улымны алып китеп, бер сәгать юк булып торды. Моннан соң яныма китереп: «Улыңны ал, бер сәгать мәшрикъ һәм мәгърибкә тәваф кылды, Адәм галәйһиссәлам янына барды, Адәм галәйһиссәлам ике күзе арасыннан үбеп: «Сөенеч сиңа, әй, минем дустым, син әүвәлге һәм ахыргы балаларымның хуҗасы», – диде. Моннан соң янә бер кешене күрдем, ул: «Әй, дөньяның хөрмәтлесе, Ахирәтнең шәрифлесе, беркем синең сүзеңне сөйләсә, синең шәһадәтең белән шәһадәт бирсә, Кыямәт көнне синең гыйлемең астында булыр», – диде. Ибне Габбас радыяллаһу ганһе әйтте: «Ул оҗмах сакчысы Ридван иде. Аллаһының әмере белән Расүлуллаһның аркасына пәйгамбәрлек мөһерен ул басты». Габделмотталиб әйтте: «Мин ул кичтә Кәгъбәтуллада идем. Кәгъбә авышып, мәкам Ибраһим тарафына сәҗдә кылды. Потлар куйган урыннарыннан егылып төштеләр. Кәгъбәтулладан тавыш ишеттем: «Аллаһү әкбәр, Аллаһү әкбәр, гөнаһлардан пакь булучы туды. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм мине Раббым мөшрикләрнең нәҗесеннән пакь кылды», – дип ишеттем. Әминә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне тудыргач, аның хозурына рәхмәт болытлары түгелде, дип

сөйлиләр. Әминәнең өенә килдем, аның өен болыт каплаганын күрдем. Йокымы, уяулыкмы, дип күземне сөртәмен. Ишектән: «Әминә, ишекне ач», – дип кычкырдым. Ишекне ачу белән җофар исе борыныма тулды. «Йә, Әминә, ни хәлең бар?» – дидем. Әминә: «Мөхәммәдне тудырдым», – диде. «Кайда ул, күрим», – дип бүлмәгә керергә теләдем. Шулчак бер адәм чыкты, кулында ялангач кылыч иде: «Сабыр ит, кермә, фәрештәләр күрешсеннәр», – диде» («Нәзһәтүл-мәҗәлис»).

Әминә радыяллаһу ганһә әйтте: «Мөхәммәдне тудыру кичендә өйнең түбәсе күтәрелде, һавада шулкадәр матур кызлар күрдем, матурлыкта тиңдәшләре юк. Габдемәнәф кызларына охшаганнар. Гаҗәпсенеп карап торганда, берсе әйтте: «Кайчанга кадәр гаҗәпсенеп карарсың? Без барчабыз да синең хезмәтчеләрең. Гаден җәннәтеннән сиңа хезмәт итәргә килдек», – диделәр. Акылымнан яздым, һушыма килгәч, баламны тудырган идем. Улымның бер кулын күзенә, икенче кулын ят әгъзасына куйганын күрдем, шул хәлдә сәҗдә кылды. Колагымны салып тыңладым. «Өммәтем, өммәтем», – дип әйтә иде. Шулвакыт күземнән югалды. Кая киттең улым, дип торганда, бер ак болыт улымны китереп, яныма куйды. Улымны юганнар, күзенә сөрмә тартылган, хушбуй сипкәннәр һәм ефәккә чорнаганнар. Шулвакыт Гатикә кереп: «Әй, Әминә, ни хәлең бар?» – диде». Әминә булган хәлләрне баштан аяк сөйләп бирде. Гатикә әйтте: «Сөйгәнемнән сикереп тордым, кайда ул Мөхәммәд дип, кулыма алып кочакладым. Шулкадәр хушбуйлы, андый ләззәтле хушбуй күргәнем юк иде. Йөзен ачып карадым, әйтерсең, тулган ай иде. Ул төн шундый төн иде, дөньяның әүвәленнән ахырынача андый төн булмады. Кәгъбәдә өч йөз алтмыш пот бар иде, барчасы җиргә төштеләр».

Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм дөньяга килгәнче, шәйтаннар һәм җеннәр күккә менеп, фәрештәләрнең сүзләрен тыңлап, ишетеп, багучыларга, сихерчеләргә хәбәр бирделәр. Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм туган кичәдә, гадәттәгечә, күккә

менәргә теләгән вакытларында, Хак Тәгалә шәйтаннарны, җеннәрне йолдызлар белән атарга әмер итте. Күккә менә алмадылар, кайгырып иблис мәлгунь янына җыелып: «Ни булды икән, бу кич безне күккә җибәрмәделәр?» – дип сорадылар. Иблис мәлгунь: «Бүген Аллаһының якын фәрештәләренең күктән иңгәннәрен күрдем, барыгыз, бер хәбәр китерегез», – диде. Шәйтаннар Мәккә тарафында бер нур күрделәр, яктылыгы һавага күтәрелгән. Якын килделәр исә, Мәккәи-Мөкәррәмә турысында фәрештәләр һавада сафка тезелеп торалар, шулкадәр күп, хәтта энә чәнчер урын юк. Шәйтаннар нинди хәбәр икән, дип якын килсәләр, фәрештәләр утлы чукмарлар белән кудылар. Иблискә килеп, күргәннәрен сөйләделәр. Иблис мәлгунь: «Аһ», – дип кычкырды. Шәйтаннар: «Йә, Хуҗабыз, ни өчен бу кадәр кайгырасың?» – диделәр. Иблис әйтте: «Минем өчен бу төннән каты төн юк, минем мең еллык мәшәкатемне аның сәясәте югалтыр, күккә чыга алмавыгызның һәм Мәккә өстендә фәрештәләрнең тору сәбәбе – ул ахырзаман пәйгамбәре дөньяга килү сәбәбедер. Аның шәригате барча пәйгамбәрләрнең шәригатен үзгәртер. Бер адәм мең яисә ун мең ел азгынлыкта йөреп, мөшрик булса, бер сәгать ул пәйгамбәрнең диненә кереп, тәүбә-истигъфар кылса, барча гөнаһысы гафу ителер. Аның өммәтеннән бер адәм гомере буенча азгынлыкта, бозыклыкта булса, берзаман моңа үкенеп салават әйтсә, барча явызлыклары урынына изгелек язылыр, бөтен гөнаһысы ярлыканыр. Рәхмәткә лаек булыр. Бу шундый пәйгамбәрдер. Кыямәттә гөнаһлы өммәтләренә шәфәгать кылып, тәмугтан коткарыр».

Габделмотталиб Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына кергәннән соң, чын пәйгамбәрне күрде. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бабасын күреп, имән бармагын күтәреп, кәлимәи шәһадәт әйткән кебек ишарәләде. Габделмотталиб бу кәрамәтләрне күреп бик шатланды. Кулына күтәреп, Кәгъбә шәрифкә алып керде. Ихлас нияте белән Аллаһы Тәгаләгә мондый бала биргәне өчен шөкер итеп, дога кылды.

Җиде көннән соң Мөхәммәд дип исем куштырып, Мәккә халкын җыеп сыйлады, кадер-хөрмәт кылды.

Мөхәммәд дип исем бирүенең сәбәбе бу иде: Әминә радыяллаһу ганһәгә төшендә бер фәрештә килеп: «Әй, Әминә, син барча мәхлүкъларның хуҗасына йөкле булдың, аны тудырсаң, Мөхәммәд дип исем куш, чөнки ул галәмнәрнең хуҗасы бик макталган булыр. Әй, Әминә, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне тудырганда күп гаҗәп эшләр күрерсең. Күргән гаҗәпләрне адәмнәргә сөйләмә һәм бу бөтине Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә так», – диде. Шул заман уянып киттем, баш астында бер алтын кәгазь таптым, анда болай дип язылган иде:

«Үгиӟүһү бил-вәхиди мин шәрри күлли хәсиди вә күлли халькин раиди мин каими вә кагиди ганис-сәбили хәиди гамәл-фәсәди җәһиди мин нәфиҫи әү гакиди вә күллә халькин мәриди йәәхүӟү бил-мәрасиди мин турукинил-мәуәриди». Әминә төшендә күргән фәрештәнең «Мөхәммәд исемен куегыз» дигән сүзен Габделмотталибка әйтте. Габделмотталиб балага Мөхәммәд дип исем бирде.

*«Кыйсасел-әнбия.*

*Пәйгамбәрләр тарихы» китабыннан*


# Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәселе Казанда яшәгәне дөресме?



X гасырда, болгарлар Ислам динен кабул иткәннән соң, алар аны бөтен Идел буена тарата башлый. Алтын Урда чорында, Хәрәзмиләр мәдәнияте йогынтысы белән, бу тагын да көчәя төшә. Чама белән якынча XIV гасырда Болгар вилаяте, ә аның белән берлектә Казан һәм төньяк территорияләр ислам таратуның үзәкләренә әйләнә.

Әлеге чорда бирегә сәидләр – Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәселеннән булган кешеләр күченеп килгән дип санала. Алар яңа урыннар – ханигаһлар, мәктәп-мәдрәсәләр ачуда үз өлешләрен керткәннәр. Яңа мәчет-мәдрәсәләр, Болгар һәм Казан мунчалары, Алтын Урдадагы кебек сарайлар – Хәрәзмиләр мөселман мәдәниятенең көчле йогынтысы астында булганнар. Алга таба Казан ханлыгында, Кырым аша, Госманлы солтаннар дәүләтенең тәэсире сизелә башлый. Шиһабетдин Мәрҗани үзенең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр») исемле хезмәтендә түбәндәге мәгълүматны калдырган:

«961 ел азагында (Григориан календаре буенча 1552 ел) Рәсәй Казан шәһәрен һәм аның җирләрен яулап алып, татарларны җиңде. Биредә сигез манаралы җәмигъ мәчете бар иде. Моннан тыш, «Таҗик чокыры» дип аталган урын янында тагын бер мәчет һәм мәдрәсә була. Анда галимнәр,



بسم الله الرحمن الرحيم

القسم الثانی من کتاب مستفاد الاخبار فی احوال قزان وبلغار روسیه طائفه سی
سنهٔ احدی وستین وتسعمائة حدودنده تاتار طائفه سینه غلبه قلب بلدهٔ قزان نی
نواحی بیله ضبط ایتدکلرنده قلعه داخلنده سکز منارهلی بر مسجد جامع وتاجیك
جرماغی دیمکله معروف محلده بنه بر مسجد ومدرسه اولب علماء واشراف
عباسیه وسادات علویه دن ونچه اشخاص وآنلرننك رئیسی نقیب الاشراف
عنواننده ملا شریف قل نام بر ذات بولوب اسلام خانلری واهالی بلاد نظرنده
زیاده معزز ومحترم ایدی روسیه کنازلری قزان خانلرینه ایلچی یباروب

габбасилар нәселеннән булган вәкилләр (габбасиларның шәрифләре) һәм мулла Шәриф Кол (сүз Кол Шәриф турында бара) җитәкчелегендә, Гали нәселеннән булган сәидләр бар иде. Мөселман ханнары һәм шәһәр халкы арасында бу шәхес зур хөрмәткә һәм абруйга ия булган» (Ш. Мәрҗани «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар». Казан, 1900. 2 б.).

Кызганычка, сакланып калган тарихи чыганакларның бик аз булуы сәбәпле күп әйберләр сер булып кала. Без сәйид (сәййид) дип хөрмәтләп, Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәселеннән булган кешеләргә мөрәҗәгать иткәннәрен беләбез. Ул гарәп теленнән әфәнде, җитәкче, мөкатдәс, күркәм дигән сүзләрне белдерә.



Шәриф (шериф) сүзе намуслы, гадел, күренекле дигәнне аңлата. Бүгенге көндә бу сүзләрнең икесе дә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең кызы Фатыйма радыяллаһу ганһә һәм кияве Гали радыяллаһу ганһе нәселеннән булган кешеләргә эндәшкәндә кулланыла. Исламга кадәр сәид һәм шәриф дип, гарәпләр данлыклы кешеләргә дәшә иделәр. Ислам килү белән бу сүзләр Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Фатыйма радыяллаһу ганһә һәм Гали радыяллаһу ганһедән булган оныклары һәм оныкчыкларына карата кулланыла башлады.

Сәидләргә кайвакыт Габделмотталибның башка улларының: Габбас, Хәмзәнең нәселеннән булган кешеләрне дә кертәләр иде. Ә әшраф (шәриф сүзенең күплек санында кулланылышы) сүзе, күп очракта, сәдат (сәид сүзенең күплек санында кулланылышы) сүзенең синонимы буларак кулланылып, аерым бер төр сәидләрне билгеләр өчен алынган.

Шул рәвешле, Казанда пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәселеннән булучылар – сәидләр яшәгән һәм алар Казан ханлыгында зур абруйга ия булган. Моннан тыш, Казан

сәидләренең һәм шәрифләренең башлыгында нәкиб әл-әшраф торган. Билгеләп үтәргә кирәк, накыйб әл-әшраф вазифасы Габбасилар хәлифәте вакытында барлыкка килгән. Бу вазифа илдәге сәидләр һәм шәрифләр санын тикшереп торудан гыйбарәт булган.

Әлеге институт Сафәви Иранлыгында һәм Госманлы солтаннар империясендә дә булган. Казан ханлыгының соңгы накыйб әл-әшрафы – 1552 елда үзенең шәкертләре белән Казанны саклап, батырларча һәлак булган танылган мулла Кол Шәриф иде. Казан ханлыгында сәидләргә карата булган хөрмәт хакында, Мәскәү дәүләтендә Рим мәмләкәте (империясе) илчесе Сигизмунд фон Герберштейн (1486-1566) сүзләреннән беләбез:

«Ул (сәйид) аларда (татарларда) шундый хөрмәт казанган ки, алар якынлаша башлагач, хәтта патшалар (ханнар) аны каршыларга чыга, аягүрә халәтендә атта утыручыга кул бирә һәм башын иеп, иреннәрен аның кулына тидерә. Моны эшләү бары тик патшаларга гына рөхсәт ителә, чөнки кенәзләр аның кулына түгел, ә тез буынына, мәшһүр кешеләр исә аякларына, ә инде гади халык аның күлмәгенә яки атына гына тотына» (Сигизмунд фон Герберштейн. Мәскәү эшләре турында язулар. СПб. 1908. 153 б.).

Шуның өчен, Татарстан җирләрендә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәселеннән булучыларның яшәүләре (ә бәлки хәзерге көндә дә яшиләрдер) белән без горурланырга тиеш. Ә Казанның, Кремльдә урнашкан, иң матур мәчете Казан ханлыгы сәидләре һәм шәрифләренең башлыгы, Казанның данлыклы яклаучысы, шагыйрь, галим, дәүләт эшлеклесе – сәид Кол Шәриф исемен йөртә.

*Мөхсин Нурулла язмасы,*

*islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә*

# Нәсыйхәт

# Олы гөнаһлар

## Кеше малын үзләштерү

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйткән:

وَلَا تَأْكُلُوا أَمْوَالَكُم بَيْنَكُم بِالْبَاطِلِ وَتُدْلُوا بِهَا إِلَى الْحُكَّامِ لِتَأْكُلُوا
فَرِيقًا مِّنْ أَمْوَالِ النَّاسِ بِالْإِثْمِ وَأَنتُمْ تَعْلَمُونَ ﴿١٨٨﴾

**«Бер-берегезнең малларын [риба, талау кебек һәм, гомумән, Аллаһы кушмаган] нахак [юллар] белән ашамагыз. [Ялгышлыгын һәм гөнаһлылыгын] Үзегез белә торып, кешеләрнең бер өлеш малларын гөнаһ белән ашавыгыз өчен хакимнәргә бирмәгез»;**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:188

وَلَوْ شَاءَ اللَّهُ لَجَعَلَهُمْ أُمَّةً وَاحِدَةً وَلَـٰكِن يُدْخِلُ مَن يَشَاءُ فِي
رَحْمَتِهِ ۚ وَالظَّالِمُونَ مَا لَهُم مِّن وَلِيٍّ وَلَا نَصِيرٍ ﴿٨﴾

**«Залимнәрнең исә дуслары да, ярдәмчеләре дә булмас»;**

«Әш-Шура / Киңәш», 42:8

إِنَّمَا السَّبِيلُ عَلَى الَّذِينَ يَظْلِمُونَ النَّاسَ وَيَبْغُونَ فِي الْأَرْضِ بِغَيْرِ الْحَقِّ ۚ
أُولَـٰئِكَ لَهُمْ عَذَابٌ أَلِيمٌ ﴿٤٢﴾

**«Шелтәле юл тик кешеләргә золым кылган һәм җирдә хаклары булмыйча, бозыклык эшләгәннәргә генә. Алар өчен тилмерткеч бер газап [әзерләнгән]».**

«Әш-Шура / Киңәш», 42:42

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән:

«Золым Кыямәт көнендә караңгылык булып килеп басар»;

«Кем дә кем күршесенең биш карыш булса да җирен басып алса, Кыямәт көнендә аның муенына басып алган җиреннән җиде тапкыр зуррак булган боҗра кидерерләр».

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

إِنَّ اللَّهَ لَا يَظْلِمُ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ ۖ وَإِن تَكُ حَسَنَةً يُضَاعِفْهَا وَيُؤْتِ مِن لَّدُنْهُ أَجْرًا عَظِيمًا ﴿٤٠﴾

**«Һичшиксез, Аллаһы бер [кешенең казанган савабын киметеп яки тиешеннән артык газап биреп] зәррә авырлыгы кадәр дә золым итмәс».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:40

Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең хәдисләрендә болай дип әйткән:

«Аллаһы кешеләрнең бер-берләренә карата булган гаделсез мөнәсәбәтләрен игътибарсыз калдырмас»;

«Бай кешенең әҗәтен кайтаруда тоткарлык күрсәтүе гаделсезлек булып санала».

Иң зур гаделсезлек булып, тиешсез керемне алыр өчен әйтелгән ант тора. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән:

«Ант итеп, мөселманның малын үзләштергән кешегә Аллаһы Тәгалә җәһәннәмне тиешле һәм җәннәтне харам итәр». Сәхабәләр: «Йә Расүлуллаһ! Әгәр бу әһәмияткә ия булмаган әйбер булса?» – дип сораганнар. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Хәтта мисвәк ботакчыгы булса да», – дип җавап биргән.

Икенче бер хәдистә Расүлебезнең түбәндәге сүзләре тапшырыла:

«Әгәр без арагыздан берегезне хезмәтче итеп билгеләп, ул бездән хәтта энә яки аннан зуррак әйберне яшерсә, бу хыянәт булачак һәм ул Кыямәт көнендә шуның белән киләчәк».

Расүлебез: «Хакыйкатьтә, аның өстендә япма яначак», – дип әйткән. Шулвакыт араларында булган бер кеше ганимәтләрне бүлгәнче үзенә алган каешны китереп бирде. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Каеш уттан», – дип әйткән.

Сәхабәләрнең берсе: «Ий Аллаһының Расүле! Әгәр мин ихлас рәвештә сабырлык күрсәтсәм һәм яу кырында үтерелсәм, минем гөнаһларым ярлыканырмы?» – дип сораган. Аллаһының Расүле: «Әҗәтләреңнән калганы ярлыканыр», – дип җавап биргән.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

«Аллаһының милкен гаделсез рәвештә тартып алучыны Кыямәт көнендә ут көтә»;

«Харам ризыкта үсүче кеше җәннәткә кермәс. Ул Утка лаеклырак», – дигән.

Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе болай дип тапшырган:

«Харам белән тукланучы җәннәткә кермәс».

Бу кагыйдә залимгә, юлбасарга, каракка, хыянәтчегә, ялганчыга, үзенең әҗәтен кире кагучыга; алдап, ким итеп үлчәүче кешегә; иясен белмичә, югалган милекне җирдән алучыга; яшереп, килеп чыгышы шикле булган милекне сатучыга; комарлы уеннар уйнаучыга, бәяләрне арттырып сатучыга кагыла.

## Караклык

وَالسَّارِقُ وَالسَّارِقَةُ فَاقْطَعُوا أَيْدِيَهُمَا جَزَاءً بِمَا كَسَبَا نَكَالًا مِّنَ اللَّهِ ۗ وَاللَّهُ
عَزِيزٌ حَكِيمٌ ﴿٣٨﴾

**«Карак ир белән карак хатынның [урлап] алган нәрсәләре өчен җәза итеп, Аллаһыдан газап буларак, икесенең дә [беләзектән уң] кулларын кисегез. Аллаһы – Бөек [Җиңелмәс], Хикмәт иясе».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:38

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән:

«Аллаһы Тәгалә йомырка, җеп урлаган өчен куллары киселгән каракны ләгънәт кылсын»;

«Әгәр Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм кызы Фатыйма караклык кылса, аның куллары киселер иде»;

«Кеше зина кылганда мөэмин халәтендә булмый. Урлаганда да мөэмин халәтендә булмый. Һәм шәраб эчкәндә дә мөэмин халәтендә булмый. Әмма тәүбә ишекләре һәрвакытта да ачык».

Сәламә бине Кай Расүлебезнең мондый сүзләрен риваять итә: «Әлеге дүрт пунктка игътибар итегез: Аллаһыга ширек кушмагыз, Аллаһы үтерергә кушмаган кешене хаксызга үтермәгез, зина кылмагыз, урламагыз».

Автор фикеренчә, урланган әйберне иясенә кайтармый торып, каракка тәүбә итүе файда китермәс. Әгәр урланган әйбер булмыйча яки аны кайтарырга мөмкинлек юк икән, карак милекнең иясеннән гафу үтенергә тиеш.

### Талау

Коръәни Кәримдә болай дип әйтелгән:

إِنَّمَا جَزَاءُ الَّذِينَ يُحَارِبُونَ اللَّهَ إِنَّمَا جَزَاءُ الَّذِينَ يُحَارِبُونَ اللَّهَ وَرَسُولَهُ
وَيَسْعَوْنَ فِي الْأَرْضِ فَسَادًا أَن يُقَتَّلُوا أَوْ يُصَلَّبُوا أَوْ تُقَطَّعَ أَيْدِيهِمْ وَأَرْجُلُهُم

مِّنْ خِلَافٍ أَوْ يُنفَوْا مِنَ الْأَرْضِ ۚ ذَٰلِكَ لَهُمْ خِزْيٌ فِي الدُّنْيَا ۖ وَلَهُمْ فِي الْآخِرَةِ عَذَابٌ عَظِيمٌ ﴿٣٣﴾

**«Һичшиксез, Аллаһыга һәм Аның Расүленә сугыш ачкан [һәм кешеләрнең юлларын кисеп, малларын талаган имансыз] кешеләрнең һәм [мөселман була торып та] җирдә бозыклык [чыгару] өчен йөргән кешеләрнең җәзасы – [үтерү белән генә канәгатьләнмичә, кыйсас юлы белән] үтерелүләре яки [җинаять белән бергә мал да талап алган булсалар] асылулары яки [җинаять кылмыйча мал гына талаган булсалар] куллары һәм аяклары чалышлап киселү яки [куркытудан тыш берни эшләмәгән булсалар, яшәгән] җирдән сөрелүләре. Бу [җәзалар] дөньяда алар өчен бер [рисвайлык, кимлек һәм] хурлык, [гөнаһларының зурлыгы сәбәпле] Ахирәттә исә алар өчен бик зур газап [булыр][1]».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:33

Җәберләү белән куркытып, кеше малларын тартып алучылар белән нәрсә булыр? Башкаларны яралаучы яки үтерүче яисә бүтән авыр гөнаһлар кылучы белән нәрсә булыр? Моннан тыш, әлеге төр кешеләр намаз укымый, ә талап алган акчаларын хәмергә һәм хатын-кызларга тота.

*Имам Әз-Зәһәбинең «Әл-Кәбаир» китабыннан*

---

1 Аллаһы Тәгалә белән сугышып булмаганга күрә, монда Аллаһы Тәгаләнең әмерләренә каршы торган һәм Аның Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хөкемнәренә каршы баш күтәргән кешеләрнең җәзасы турында сүз бара. Гукль һәм Гурайнә кабиләләреннән шактый гына кеше Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә барып, мөселман булганлыкларын белдерәләр. Ләкин Мәдинәнең һавасы үзләренә ярамагач, чирләп, хәлсезләнә башлыйлар һәм, яланга дөяләр янына барып, аларның сөтләрен эчеп, савыгыр өчен, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән рөхсәт сорыйлар. Рөхсәт алгач, Куба тирәсендәге зәкят дөяләре янында берникадәр вакыт торып, хәлләре әйбәтләнгәч, диннән чыгып, бер дөяне суялар. Көтүчеләрдән берсенең кулларын һәм аякларын кисеп, теленә һәм күзләренә чәнечкеләр кадап, үлгәнчегә кадәр кызу кояш астында калдыралар, калган дөяләрне куалап алып китәләр. Исән калган икенче көтүче хәбәр иткәнчә, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм алар артыннан егерме кешелек бер гаскәр җибәрә. Тотып китерелгәннәреннән соң, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм аларга кыйсас ителүен әмер итә. Шулай итеп ул җинаятьчеләрнең күзләре чокыла, куллары һәм аяклары киселә һәм үлгәнчегә кадәр Хәррәдә калдырылалар (Бохари Мәгази 34 № 3956 4/1535; Зәкят 67 №1430 2/546) .

# Әдәби сәхифә

# Олуг үкенеч

*(Әкият, әмма бик зур гыйбрәт)*

Элгәре заманда, зур булмаган салада яшәгән ди бер күркәм әтәч. Кып-кызыл кикриге, өч-дүрт төсле каурые, гаҗәеп матур купшы койрыгы аңа янындагы тавыклары арасында шактый зур абруй казанырга ярдәм итте: үз урманында чупай да купай дигәндәй, әтәч, ихатасында үзен олы, дәрәҗәле затка санап, көн дә кукраеп, шапырынып йөри иде. Ә инде һәр көнне иртән көр, көчле тавыш белән кычкыруы әтәчебезне бөтен әйләнә-тирәгә танытты: аның шома куначадан күкрәгән горур калкытып мәхәлләгә сөрән салуыннан шактый күп кеше уянды, гыйбадәт кылучылар исә күкрәк төпкеленнән чыккан шушы гайрәтле оранны иртәнге намазның азаны буларак кабул итте.

Тавыклар кавемендә бердәнбер ир заты булуыннан кайчак иләсләнеп китеп, әтәч көндезләрен дә кыт-кыт килеп ишегалдын вакыт-вакыт вәкарь аваз илә яңгырата, аннан кинәт томырылып, бер каурыйлы бикә белән аралашып алгач, канатларын җилфердәтеп биек читәнгә очып менә дә тирә-якка бик куәтле аваз салып, бу җирлектә үзенең гаять зур кадер-хөрмәткә ия шәхес булуын тагын бер кат раслап куя. Кылтаючан кошның менә шундый бар дөньяга үз барлыгымны хәбәр итәм дип укталып торган мәлендә, бер көтмәгәндә-уйламаганда, аның алдында йорт хуҗасы пәйда була. Ике учын чалбар кесәсенә тыгып, хуҗа әүвәл капыл сызгырып ала, соңыннан исә читән өстенә яңа гына кунаклаган әтәч янына басып, зәһәрлелек илә әйтә:

– Ызначыт тәк! Иртәгәдән башлап тавыш-тының чыкмасын! Иртән азан әйтсәң, гомумән, кычкырганыңны ишетсәм – йоныңны йолкыйм!

Шуннан соң кырыс ниятенең хаклыгын күрсәтергә теләптер, кытыршы зур учы белән әтәчебезнең артына тондырып, хуҗа аны читәннән бәреп төшерә. Шушындый сөмсез мөгамәләдән, тавыклары алдында шулай

рисвай ителүдән гарьләнсә дә, әтәч «исән-имин калу барыннан да хәерле» дигән җәһәт уйның йогынтысында каударланып абзар артына кача. Хуҗаның катгый таләбеннән һәм куркыныч вәгъдәсеннән хәйран калып, ул тирән хафага төшә. «Менә сиңа мә-ә! Ни гомер мәхәлләне яңгыратып, күпләрне сокландырып әйткән азанны әйтүдән тыйсыннар әле, йә... Әкәмә-әт!» – дип уйланды ул үзалдына аулакта посып. Әмма нишләмәк кирәк, «әддарурат түбихүл мәхзурат», ягъни мәсәлән, «заруriят тыелганны да рөхсәт итә» дигәнгә сылтап, әтәч шушы көннән башлап тирә-юньне яңгыратып кычкырудан туктый, үзенә ирешергә мөмкин җәзадан өркеп, азан әйтүдән дә баш тарта...

Көн артыннан көн узды. Шулай рәсмән кисәтелгәннән соң, әтәч, тавышын чыгармыйча, хуҗа йортына таба сагаюлы караштыргалап, үзенең барлыгын кеше күз-колагына белдермәскә тырышып йөрде. Бер атналап вакыт үткәч, кикриге шиңгән, койрыгы салынган, пошаманга төшүдән өне качкан әтәч тавыклар арасында сүлпән генә булашып йөргән бер арада, бар дөньяны хафаландырып, аның янына янә йорт хуҗасы килеп басты. Битенә ыштыр капланган затсыз бәндәнең кыяфәтеннән сискәнеп, мескен «кикрик» куркуыннан тәмам коелып төште. «Тавыш-тыным... чыкмады бугай... Әллә... ялгыш онытылып... берәр аваз чыгардыммы, Ходаем...» – дигән кот чыккыч уйдан калтыранган әтәч гомере белән хушлашырга әзерләнде. Әмма хуҗа, янында торган буш чиләкне тибеп очырды да, учларын чалбар кесәләреннән чыгармыйча, авызын усал бөрештереп болай диде:

– Тәк... Болай дәшмичә йөрүең дә бераз ялыктырды... Әмерфәрманымны бераз үзгәртмичә булмас! Димәк, шулай: әгәр бүгеннән башлап тавыклар кебек кытакламасаң, бөтен йоннарыңны йолкып атам!

Чын ир затына хас горурлыгын, «әтәчлеген» гаять кимсетә торган шушы яңа таләптән ачуы кабарса да, хуҗаның «матри аны!» дип бармагы белән явызларча янап алуыннан соң, әтәч вәгъдә ителгән җәзаның ая-

ныч нәтиҗәсен күз алдына китереп, шунда ук тавыкларча кытаклап куйды. Шуннан китте инде: көн тудымы, ишегалдына чыгып, элекке тавыклар «нәчәлниге», йортның ачык тәрәзәсенә шомлы карашын ташлый-ташлый, янындагы «ханымнарга» кушылып кытаклап йөрде. Баштарак бик гарьләнсә дә, тора-бара ничектер ияләште дә кебек: кикриге белән койрыгын яшеребрәк йөрергә тырышып, тавыкларча кыткылдавын дәвам итте.

Кая гына атлавына карамастан купшы койрыгы артыннан калмаса да, янаган җитди хәвеф хакында хәбәрдар булу әтәчкәйне хатын-кыз җенесендәге кавемдәшләреннән әллә ни аерылмаска мәҗбүр итте. Дөнья, шулай итеп, тынычланды кебек, әмма... бу ишегалдында бәла аяк өстендә йөри шул: бер ай тирәсе узгач, бераз онытылгангадыр, тавыкларча кытаклый-кытаклый азык чүпләп гамьсез йөргән әтәч янында кояш яктысын каплап, хәвефле шәүлә пәйда булды. Ул йорт хуҗасы иде...

– Тәк... – диде шәүлә, алдан кабул ителгән карарны катгый фәрман рәвешендә игълан итәргә ниятләп. – Әгәр... иртәгәдән башлап... башка тавыклар шикелле йомырка сала башламасаң... башыңны чабып сине чалачакмын!

Шуннан соң шәүлә юкка чыкты, кинәт мәнҗерәп киткән әтәч исә күзен йомып җиргә сеңде. Хуҗаның пәрие кагылган чагында ишегалдына чыкканын шәйләмичә яшеренергә өлгерми калган өчен бик тә, бик тә битәрләде үзен мескен кошкай. Ләкин инде соң иде: үзенә белдерелгән таләпне берничек тә үти алмаячагын уйлап куюдан, ул, өмете өзелеп, ирексездән елап җибәрде. Бу вакытта якты дөнья белән хушлашу котылгысызлыгыннан битәр, аның җаны башка сәбәп илә өтелде. Шуны уйлаудан бичара мәхлукны олуг үкенеч хисе биләп алды, һәм өстенә төшкән зур хәсрәттән өзгәләнеп, ул үз-үзенә әйтте:

– Ий, Аллам! Әгәр азан әйтүемне туктатмаган булсам, ӘТӘЧ булып үләр идем...

* * *

**Кыскача нәсыйхәт:**

Кызганыч, ләкин безнең арабызда да шушы әкияттәге әтәч шикелле горуррак холыклы, гыйбадәтне гадәткә әйләндереп, аны үзен башкаларга белдерү нияте белән кылучы кешеләр бар. Ниндидер сынау-авырлык килгәндә, шундый мин-минлек сыйфатына ия булучыларга Аллаһы Тәгаләнең ярдәм итмәве гаҗәп хәл түгел. Ул ярдәмне тоймагач, алар еш кына шәйтанның куркытуына каршы көрәшергә талпынып та карамыйча, ул кушканны шундук үтәргә әзер тора. Әмма барыбызга мәгълүм: әгәр Аллаһка ихлас сыенсаң, дога белән мөрәҗәгать итсәң, бу куркытуның нигезендә бернинди хәтәр-хәвеф юк икәнен тоеп, аңлап була. Ә иң мөһиме – нәрсә генә булуга карамастан, иманыңа, динеңә тугры булып калу. Бу тормыш – сынау, һәм һәрвакытта да безнең өчен әзерләнгән һәрбер сынауда «ӘТӘЧ», ягъни МӨСЕЛМАН булып калу – бик җаваплы, әһәмиятле бурычыбыз (гомеребез тәмамлануга яки дәвам итүгә карамастан). Ахырчиктә һәр кешенең олуг максаты, җир йөзендәге вөҗүднең асыл-мәгънәсе – Аллаһ разый булырлык итеп яшәп, мәңгелек ахирәт тормышына чын МӨСЕЛМАН булып, ягъни ихлас иманлы хәлдә күчү...

# Ә син ышанасыңмы?

*(Әкият, әмма бик зур гыйбрәт)*

Бер бака елга суы астыннан калкып чыгып, ярдан ерак булмаган зур таш өстенә менә дә, хәрәкәтсез калып, тирән уйга чума. «Нишләтергә инде шушы үҗәт балыкларны? «Сез яшәгән әлеге су асты дөньясыннан башка елгабыз өстендә тагын бер дөнья – җир өстендәге тормыш та бар… Андагы яктылык! Андагы матурлык! Ул искиткеч киң, гаҗәеп манзара!» – дип ничек кенә сокланып аңлатып карамадым, юк – ышанмыйлар әйткән сүземә! Сафсата имеш! И-и, мәхлуклар… Инде тагын ничек аңлатыйм? Шул хакта сүз кузгатуга, шундук тарткалаша башлыйлар, «әйдә, бар, үз юлыңда бул, без үзебез беләбез ничек яшәргә!» – дия-дия, күзләрен акайтып, ачуларын белдерергә тотыналар. Шулай да, колак салганнары да юк түгел анысы, ләкин күпчелеге ышанмый бит әйткән сүземә, һич ышанмый…

Бака шулай үзалдына уйланып яткан арада яр буена бер Кеше килә дә, әйберләрен урнаштырганнан соң, кармак җебенә җим эләктереп, шуны суга ыргыта. Күп вакыт та үтми – ялтырап торган зур балык биек чиләк төбенә олактырыла. Шушы күренештән йөрәге кысылып куйган бака «аһ!» дип әйтергә өлгерми, җимле җеп икенче тапкыр суга төшерелә һәм ымсындыргыч «күчтәнәчкә» алданган чираттагы балык та иптәше янына чиләк төбенә атыла. Шулай итеп, Кешенең зур, тирән савыты шактый тиз арада матур, таза балыклар белән тула.

Эше тәмам булгач, балыкчы кирәк-яракларын җыеп ала да кузгалып китә. Бака исә, кызыксынуын тыя алмыйча, әле бая гына елга төбендә тыныч, ваемсыз гомер кичергән, ә хәзер инде тимер чиләк эченә дыңгычлап тутырылган иптәш балыкларны кая алып китүләрен белергә теләп, сикергәли-сикергәли, гаять куркыныч тоелган Кеше артыннан иярә.

Үз йортына кайтып җиткәч, Кеше, бакчасының аулак бер урынында махсус тимер таякчыклар көйләп, шулар өстенә зур түгәрәк таба урнаш-

тыра да нәкъ шуның астында учак кабызып җибәрә, бака исә, агачлар артында посып, аның нәрсә эшләгәнен карап тора. Учак ярыйсы кызу янып киткәч, Кеше, балыкларны чиләктән берәм-берәм чыгарып, табага тезә башлый. Әллә чыш-пыш килгән май тавышыннан, әллә күркәм балык кавемдәшләренең әле күптән түгел генә ялтырап торган матур гәүдәләре, коточкыч кызу табада кыздырганда, шәлперәеп, төсен кискен үзгәртүдән, бака кинәт хәлсезләнеп китә, соңыннан исә, күз алдындагы караңгылык бераз таралганнан соң һушына килгәч, ул шушы куркыныч урыннан тизрәк китү ягын карый.

Яшәгән елгасына көч-хәл белән кайтып җиткәч, бака җәһәт кенә су астына чума һәм бөтен әйләнә-тирәгә сөрән салып, балыкларга үз күзләре белән күргән тетрәндергеч хәлне кабалана-кабалана сөйләргә тотына:

– Җәмәгать!!! Шушы елганы һәм монда булган бөтен нәрсәләрне бар кылган бөек илаһи Зат хакы өчен сорыйм: тыңлагыз әле мине зур игътибар белән! Шушы сулык өстендә тагын бер дөнья – җир тормышы барлыгын сезгә инде сөйләгән идем! Белеп торыгыз: кайвакыт елгабызда пәйда була торган тәмле, бөтенебезне кызыктырып ымсындырган җимнәр – ул теге мин әйткән дөньяда яшәүче Кеше дигән затның мәкерле хәйләсе! Берүк якын килмәгез шул ымсындыргыч җимнәргә! Юкса шул зат сезне эләктереп алып, утлы табага салып кыздырачак! Алдана күрмәгез, сак булыгыз, Аллаһы Тәгалә биргәннәренә риза булып, булганына шөкер итеп яшәгез!

Әмма үзе шаһит булган бу имәнеч күренештән каушап, калтыранып торган бака, шулай ихластан борчылуын белдерсә дә, балыкларның күбесе аңа ышанмый һәм янә: «Әйдә, үз юлыңда бул!» – дип мыгырдашып, еракта әйләнгәләп, ялтырап-җемелдәп торган аппетитлы җимгә таба бер-берсен җитез узарга тырышып юнәлә. Аяныч нәтиҗәсе исә озак көттерми: чиләк, учак, кызган утлы таба…

* * *

**Кыскача нәсыйхәт:**

Бу әкият булса да, аның эчтәлегендә – зур гыйбрәт. Дөрестән дә, Адәм балаларының шактые бу кыйссадагы балыклардан әллә ни ары китмәгән. Кайсы берәүгә: «Бу дөнья тормышыннан соң безне ахирәт тормышы көтә! Әгәр нәфесләнеп, оялу хисен онытып хәрам булган нәрсәләргә үрелсәң, төрле «җим» рәвешендәге алдавыч ләззәтләрне татып карыйм дип Яратучыбыз Аллаһы Тәгалә билгеләп куйган чикләрне бозсаң, бу дөнья тормышыннан соң киләчәк ахирәт тормышында кызу утлы табада куырылып пешәчәгеңне белеп тор!» – дисәң, ул чыраен сытып: «Әйдә, бар, үз юлыңда бул, мин үзем беләм ничек яшәргә!» – дип җавап кайтара, яисә сүзне читкә борып, шушы сөйләшүне туктатырга тырыша.

Менә шулай... Бик татлы тоелган җимгә алданып, балыклар ниндидер күзгә күренмәгән көч илә кинәт өскә чөелеп билгесезлектә юк булып барган кебек, Адәм балалары да бер көнне җаннары белән хушлашып, «ахирәт» дигән билгесезлектә югала, ә аларны шунда озатканнар тиешле нәтиҗә ясамый һәм: «Болар кая китте икән?» – дигән сорауга җавап табуны кирәккә санамый. Чөнки җир йөзендәге вакытлыча тормыштан соң мәңгелек ахирәт тормышы булачагына ышанмый.

Ә син ышанасыңмы соң? Юк? Алайса, бу гыйбрәтле кыйссаны яңадан укы!

# Кем бәхетле?

Зур, куе урманда, мәһабәт имән башында яшәгән ди бер кара карга. Бернигә борчылмыйча, тыныч кына шулай яшәгәндә, көннәрдән бер көнне урман читендәге күлдә ул аккошны күрә. Аның матурлыгына исе китеп, карга хөсетләнеп уйлап куя: «Ул шундый ап-ак, ә мин... шыксыз капкара... Бу гаҗәеп аккош дөньядагы иң бәхетле коштыр». Шушы фикерләрен ул аккошның үзенә дә ирештерә. Ләкин аның җавабы карганы аптыраушта калдыра.

– Дөрестән дә, моңарчы мин үземне дөньядагы кошларның иң матуры, иң бәхетлесе дип тойган идем, ләкин... тутый кошны  күргәч, моның шулай түгеллеген аңладым: мин бит, мескен, бер төсле генә, ә тутый кош – ике-өч төсен ялтыратып горур утыра! Менә кем бәхетле!..

Бу сүзләрне ишеткән карга тутый кошны эзләп очып китә. Эзләп тапкач, мәсьәләне аңлата да:

– Димәк, кошлар арасында иң матуры, иң бәхетлесе син? – дип сорый.

Әмма тутый кошның җавабы да көтелмәгәнчә була:

– Байтак вакыт мин дә шундый фикердә идем, ләкин... тавис кошын күргәч, шаккаттым: менә ул чын матурлык! Миндә бит беткәнче ике-өч төс кенә, ә тавис кошында... Юк, иң матур һәм иң бәхетле кош – ул, һичшиксез, тавис...

Шушы дөньядагы иң бәхетле кошны кайда күреп була икән, дип кызыксынгач, тутый кош зоопаркка очарга кушты. Шунда килеп җиткәч, карга тавис читлеге янындагы дистәләгән кешене күреп, хәйран кала. Кешеләрнең һәммәсе дә соклану белдереп, тел шартлата-шартлата, купшы койрыклы тависның матурлыгын мактый иде. Зоопаркның эш вакыты чыгып, кешеләр таралышып беткәч, карга тависка эндәшә:

– Кадерле, хөрмәтле тавис! Син шундый матур! Көн саен йөзләгән, ә ай дәвамында, бәлки, меңләгән кеше сине карарга дип килә, мактый, хо-

зурлана, соклана... Ә менә алар мине күрсәләр, бер дә сокланмыйлар, әле куып та җибәрәләр. Миңа калса, син – дөньядагы кошларның иң бәхетлесе!

Канатлы кардәшенең аны олылап шундый сүзләр әйткәненә карамастан, тавис моңсу иде. Ул, нәфис таҗлы горур башын түбән иеп, боек һәм кызганыч тавыш белән әйтә:

– И, карга-карга... Читтән караганда гына бу шулай. Чынбарлыкта исә шушы матурлыгым аркасында мин читлектә гомер кичерергә мәҗбүр. Әле кичә генә, беләсеңме, нәрсә уйлап куйдым? Шушы зоопаркның читлекләрендә нинди генә кошлар юк, ләкин берсендә дә каргалар күренми. Мин, беләсең килсә, шундый нәтиҗәгә килдем: бу дөньядагы кошларның иң бәхетлесе – ул, әлбәттә, карга. Минем бик тә, бик тә карга буласым килә! Карга булсам, кайда телим – шунда очар идем, нәрсә телим – шуны эшләр идем... Бәхетлеләрнең бәхетлесе – ул син, сөекле карга!

* * *

## Кыскача нәсыйхәт:

Чыннан да, үзләрен башкалар белән чагыштырып, күпләр гаять ялгыша. Тирә-юньдәге матур кешеләргә, телевизордагы артистларга сокланып шулардан көнләшү – әлбәттә, дөрес түгел. Кем белгән, бәлки, алар да читлектәге кошлар кебек бәхетсездер? Нинди генә кыяфәткә, нинди генә мөмкинлекләргә ия булуга карамастан, Аллаһ биргәненә риза булып, ихластан шөкер итеп яшәргә кирәк. Тормыш моны инде кат-кат раслады: матур кеше бәхетсез, ә әллә ни күркәм кыяфәткә ия булмаучылар исә бик бәхетле булу очраклары шактый күп. Әлбәттә, киресенчә дә була, әмма шунысы мөһим: сәләтебез, матди хәлебез, сәламәтлек белән төс-кыяфәтебез нинди булуга карамастан, шушы сынау дөньясында Аллаһы Тәгаләнең тугры бәндәсе – чын мөэмин-мөселман булып яшәү һәркем өчен дә төп максат булып торсын иде.

*Ришат хәзрәт Курамшин,*

*Кукмара мәдрәсәсе мөдире*